# 2018 ЕЛДА
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
# БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ
# ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
# БАЛА ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ ЗАКОНЛЫ
# МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН ҮТӘҮ ТУРЫНДА

# Д О К Л А Д

КАЗАН – 2019

# ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ .......... 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ ҺӘМ АНЫҢ АППАРАТЫНЫҢ 2018 ЕЛДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ**

1.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшчәнлеге .......... 8

1.2. Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге .......... 16

1.3. Балалар мәнфәгатьләрендә законнарны камилләштерүдә катнашу .......... 22

1.4. Балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашу .......... 29

1.5. Аналитик эшчәнлек .......... 31

1.6. Эш визитлары .......... 34

1.7. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координацион комитет эшчәнлеге .......... 37

1.8. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Гаиләдән балаларны алу практикасын анализлау буенча эшче төркем эшчәнлеге .......... 40

1.9. Проект эшчәнлеге .......... 42

1.10. Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү эшчәнлеге .......... 53

1.11. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре институты эшчәнлеге .......... 61

**2018 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛАЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕ ҮТӘЛЕШЕНЕҢ ГОМУМИ МОНИТОРИНГЫ**

2.1. 2018 елда Татарстан Республикасында төп демографик тенденцияләр .......... 68

2.2. 2018 елда Татарстан Республикасында бала хокукларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән төп гамәлләр һәм чаралар .......... 72

2.3. 2018 елда халыкара, федераль һәм республика законнарындагы бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсенә караган яңалыкларга күзәтү .......... 78

**2018 ЕЛДА ТӨП ТОРМЫШ ЭШЧӘНЛЕГЕ ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ БАЛА ХОКУКЛАРЫН ҮТӘҮ**

3.1. 2018 елда гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауга нигезләнгән Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләрнең гомуми мониторингы .......... 88

3.2. Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү .......... 98

*3.2.1. Балаларның тышкы сәбәпләр аркасында үлүен анализлау* ................................ 99
*3.2.2. Рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклану хокукын тәэмин итү* ................. 111
*3.2.3. Тискәре мәгълүматтан яклау хокукын тәэмин итү* ........................................ 116
3.3. Баланың сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешкә хокукын тәэмин итү ............ 118
*3.3.1. Балалар үлеменә гомуми анализ* ..................................................................... 119
*3.3.2.Балалар сәламәтлеге торышына гомуми анализ* .............................................. 121
*3.3.3. Балаларның сәламәтлеккә хокукларын тәэмин итүнең проблемалы аерым мәсьәләләре* ......................................................................................... 130
*3.3.4. Балаларның ялы һәм аларны савыктыру* ......................................................... 135
3.4. Баланың яшәү һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукын үтәү ............................................ 139
*3.4.1. Гаиләдә иминлек булмау проблемалары* ......................................................... 139
*3.4.2. Ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру* ......................................................................................... 148
*3.4.3. Баланың гаиләгә хокукын гамәлгә ашыру проблемалары һәм, гаиләдә каршылыклар булганда, гаилә эчендәге бәйләнешләр* ........................................ 155
3.5. Баланың белем алу өлкәсендә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү ................................................................................... 159
*3.5.1. Мәктәпкәчә белем* .............................................................................................. 159
*3.5.2. Гомуми белем бирү* ............................................................................................ 162
*3.5.3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларга белем бирү* .................... 177
3.6. Баланың торак һәм башка мөлкәти хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү ........................................................................................................... 186
*3.6.1. Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын үтәү* ............................................................................................. 186
*3.6.2. Күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын тәэмин итү* ................................. 189
*3.6.3. Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокукларын үтәү* ...................... 191
*3.6.4. Балигъ булмаганнарның башка мөлкәти хокукларын яклау* ............................ 193

ЙОМГАКЛАУ ....................................................................................................... 197

# КЕРЕШ

***«Безнең бурыч – республиканың һәр кешесенә, үзенең көченә карап, үсү мөмкинлеген бирү, балага үз юлын табарга ярдәм итү. Яшь буынның сәләтләрен һәм конкуренция өстенлекләрен ачыклау һәм үстерү буенча тулы система булдырырга кирәк».***

Татарстан Республикасы
Президенты
Р. Н. Миңнехановның
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советына
юлламасыннан,
2018 елның 24 сентябре

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында еллык доклады «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – Закон) 13 статьясы нигезендә әзерләнде.

Докладта узган елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил) һәм аның Аппараты эшчәнлегенең төп юнәлешләре тасвирлана, шулай ук БМОның Бала хокуклары турында конвенциясендә һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турында гамәлдәге законнарында гарантияләнгән бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү эшләренең торышына бәйсез анализ ясала һәм бәя бирелә.

Әлеге доклад Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан әзерләнгән еллык докладларның тугызынчысы, ул 2018 ел йомгакларына багышлана.

Доклад, гадәттәгечә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнарыннан, республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарыннан Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан соратып алынган рәсми дәүләт статистикасы белешмәләрен, мәгълүмати-аналитика материалларны, гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен, республиканың төрле балалар учреждениеләрендә үткәрелгән тикшерүләр һәм аларга барып кайтулар нәтиҗәләрен, балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында аерым мәсьәләләр каралган төрле координацион һәм киңәшмә органнары эше барышында, киңәшмәләрдә, очрашуларда, конференцияләрдә, «түгәрәк өстәлләр»дә катнашканда Вәкаләтле вәкил алган мәгълүматларны өйрәнүгә, анализлауга һәм гомумиләштерүгә нигезләнде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил

һәм аның Аппараты эшчәнлегендә аның үзе катнашында тикшерелгән һәм анализланган мәгълүматлар күрсәтелә.

Доклад структурасы буенча керештән, өч бүлектән һәм йомгаклау өлешеннән тора.

Беренче бүлектә 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең төп юнәлешләре турында мәгълүмат бирелә.

Икенче бүлектә Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешенә гомуми мониторинг ясала. Бу бүлектә Татарстан Республикасы территориясендә 2018 елда бала хокукларының үтәлешенә гомуми бәя бирелә, анда балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүне яхшырту максатларында республикада күрелгән чаралар, ясалган адымнар, башлангычлар, төп демографик тенденцияләр күрсәтелә, федераль һәм республика законнарындагы балалар яшәешенә турыдан-туры кагылышлы төрле аспектларга йогынты ясый торган яңалыклар анализлана.

Өченче бүлектә Татарстан Республикасында балалар тормышының төп өлкәләрендә аларның хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешенә кагылышлы вәзгыятькә анализ ясала. Биредә төп игътибар республикада балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруның Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә үз эшчәнлеге барышында мәгълүм булган проблемалы мәсьәләләрне тасвирлауга бирелә. Мондый тасвирлама Бала хокуклары турында БМО Конвенциясендә беркетелгән төп хокукларның түбәндәге төрләре буенча бирелә:

баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга хокукын тәэмин итү;

баланың сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешкә хокукларын тәэмин итү;

баланың гаиләдә яшәүгә һәм тәрбияләнүгә хокукларын тәэмин итү;

баланың белем өлкәсендә хокукларын тәэмин итү;

баланың торакка һәм мөлкәткә хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү.

Докладта хокуклары бозылу ихтималы булган төркемнәргә кергән балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә аерым игътибар бирелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дөрес мәгълүмати-аналитик белешмәләр биргән һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үзенә йөкләнгән бурычларын үтәүдә ярдәм иткән өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, республика муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә үзенең рәхмәтен белдерә.

Һәр бүлектә Бала хокуклары буенча вәкаләтле Татарстан Республикасы яшь гражданнарының психологик, әхлакый, физик сәламәтлеген яклау өлкәсендәге хәлләрне, шулай ук балаларның шәхси үсешен, белем һәм иҗат үсешен сыйфатлы яхшыртуга юнәлдерелгән үз тәкъдимнәрен бирә.

Доклад Законның 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына җибәрелә.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ ҺӘМ АНЫҢ АППАРАТЫНЫҢ 2018 ЕЛДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ

1

БҮЛЕК

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм аның Аппаратының эшчәнлеге Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан яклауны, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, Татарстан Республикасы территориясендәге барлык оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары тарафынннан бу хокукларның һәм мәнфәгатьләрнең танылуын һәм үтәлүен тәэмин итүдән гыйбарәт.

Билгеләнгән вәкаләтләр кысларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең төп хезмәт эшчәнлеге юнәлешләренә контроль-күзәтчелек, эксперт-аналитик, агарту эшләре керә.

*1 нче схема*





## 1.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшчәнлеге

2018 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 1998 мөрәҗәгать керде, шулардан чыгып, 2100дән артык проблема билгеләнде. Бу 2017 елга караганда 60 мөрәҗәгатькә (3%ка) күбрәк.

*1 нче диаграмма*

***2014-2018 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы***




Моннан тыш, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Җәмәгать ярдәмчеләре тарафыннан гражданнардан кергән 309 мөрәҗәгать каралды. Шулай итеп, 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты адесына гражданнардан барысы 2 307 мөрәҗәгать керде.

2018 ел дәвамында гражданнарның ***мөрәҗәгать итү динамикасын*** анализлаудан күренгәнчә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравына гражданнардан ай саен уртача 166 мөрәҗәгать кергән (2017 елда – 158). Шул ук вакытта шикаятьләр белән эшләгәндә Аппаратның бер хезмәткәренә һәр айда уртача 55 мөрәҗәгать туры килә.

*2 нче диаграмма*

***2018 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнар мөрәҗәгатьләре динамикасы***




Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратта халык белән эшләүнең төрле рәвешләре һәм ысуллары гамәлгә ашырыла.

Язмача мөрәҗәгатьләр теләсә нинди җайлы ысул белән кәгазьдә йә электрон юл белән тапшырыла:

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының электрон почтасына;

Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының интернет-кабул итүенә;

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең рәсми сайты аша.

2018 елдан Вәкаләтле вәкилгә түбәндәге социаль челтәрләр аша мөрәҗәгать итү мөмкинлеге барлыкка килде:

Instagram (https://www.instagram.com/upr_v_rt?r=nametag),

ВКонтакте (https://vk.com/id515533518);

Одноклассники (https://ok.ru/profile/589380569655).

Телдән түбәндәгечә мөрәҗәгать итәргә мөмкин:

атна саен **һәр сишәмбе** көнне Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил кабул иткәндә;

атна саен **һәр чәршәмбе** көнне гражданнарны Аппарат хезмәткәрләре кабул иткәндә;

телефон элемтәсе аша;

уздырыла торган «Балалар соравы» Хокукый ярдәм көннәре кысаларында;


«кайнар линия» телефонына;

Республика муниципалитетларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре кабул иткәндә.

***Гражданнардан мөрәҗәгатьләр керү*** мониторингы буенча, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә һәм аның Аппаратына телдән мөрәҗәгатьләр күбрәк булды. Мәсәлән, 2018 елда язма мөрәҗәгатьләр 803 (42%) булды, телдән – 1168 (58%).

*3 нче диаграмма*


***2014-2018 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы*** *(керү рәвеше буенча)*




***Язма мөрәҗәгатьләрнең керү ысулына килгәндә,*** 2018 елда да 2017 елдагы кебек үк хатларны электрон элемтә чаралары аша алуга өстенлек бирелде. Мәсәлән, узган чорда 830 язма мөрәҗәгатьтән бары тик 282 (34%) мөрәҗәгать кәгазьдә алынды, калган 548 мөрәҗәгать (66 %) – электрон элемтә чаралары аркылы.

*4 нче диаграмма*


***2014-2018 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы*** *(керү ысулы буенча)*




***Телдән мөрәҗәгатьләрнең керү ысулына*** килгәндә, монда 580 мөрәҗәгать (50 %), гадәттәгечә, шәхси кабул итүләр барышында һәм «Балалар соравы» Хокукый ярдәм көннәре уздырганда керде, калган 588 мөрәҗәгать (50 %) телефон аша (шул исәптән “кайнар линия” телефоны аша) алынды.

*5 нче диаграмма*

***2014-2018 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә телдән кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы*** *(керү ысулы буенча)*





2018 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәте тарафыннан 109 граждан кабул ителде, шуннан 55е Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан шәхсән кабул ителде, 54е – Аппарат хезмәткәрләре тарафыннан.

Шәхсән кабул итү кысаларында барысы 580 граждан кабул ителде: 253 кеше (44%) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итте, тагын 327 кеше (56%) Аппарат белгечләреннән ярдәм һәм консультация алды.

*6 нчы диаграмма*

***2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Аппарат хезмәткәрләре тарафыннан шәхсән кабул ителгән гражданнар саны***




Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан шәхсән кабул ителгән 55 гражданнан:

23 гражданны ул Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында үзе генә кабул итте;

25 – республиканың муниципаль районнарына, шәһәр округларына чыкканда кабул ителде;

32 – федераль һәм республика дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре һәм вәкилләре тарафыннан бергә кабул ителде;


3 – учреждениеләрдә;

2 – «Балалар соравы» Хокукый ярдәм көннәре уздырганда;

2 – Россия Федерациясе президентының Иҗтимагый кабул итү урынында булды.

*7 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан шәхсән кабул итү***





2018 елда гражданнарны республиканың муниципаль районнарына һәм шәһәр округларына ***чыгып кабул итүләр*** дәвам итте. Мондый күчмә кабул итүләр ел саен раслана торган график буенча планлы тәртиптә башкарылды.

2018 елда республиканың 25 муниципаль районында (шәһәр округында) 25 25 күчмә кабул итүләр булды, болар: Әгерҗе, Алексеевск, Аксубай, Арча, Апас, Әтнә, Югары Ослан, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Кайбыч, Кукмара, Мамадыш, Менделеевск, Яңа Чишмә, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Спас, Тукай, Теләче, Чирмешән, Ютазы муниципаль районнарында, Казан шәһәренең Мәскәү һәм Киров районнарында, Чаллы шәһәрендә оештырылды.

*Карта*

***2011 – 2018 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең муниципаль районнарда (шәһәр округларында) күчмә кабул итүләре***



Шулай итеп, 2018 ел дәвамында гражданнарны күчмә кабул итүләр республика муниципаль районарының (шәһәр округларының) яртысыннан күбрәгендә (45тән 25ендә) һәм шәһәр округларында оештырылды, шундый очрашуларда 176 граждан кабул ителде.

2018 ел гражданнарны ***уртак кабул итүгә*** ихтыяҗ булулын раслады. 2018 елда 32 уртак кабул итү очрагы булды:



Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе әгъзасы Р.А.Ратникова белән Кукмара муниципаль районында, (23.10.2018);



Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе Т.П.Ларионова белән Алабуга муниципаль районында (20.03.2018);



Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе С.М.Захарова, «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе әгъзасы Т.В.Воропаева белән Чаллы шәһәрендә (31.10.2018);



Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе урынбасары, «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе әгъзасы Т.В.Воропаева белән Алексеевск муниципаль районында (26.06.2018);



Татарстан Республикасы прокуроры урынбасары О.А.Даминов белән Югары Ослан (24.04.2018), Алексеевск (26.06.2018), Менделеевск (25.09.2018) муниципаль районнарында;



Татарстан Республикасы прокуроры урынбасары Ю.И.Наумова белән Арча (13.03.2018), Питрәч муниципаль районнарында (08.05.2018);



Татарстан Республикасы Прокуратурасының балигъ булмаганнарга һәм яшьләргә карата законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү бүлеге башлыгы З.Х.Ибраһимов белән Саба муниципаль районында; (22.05.2018);



Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы Тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасары В.Н.Циома белән Алабуга (20.03.2018) һәм Әгерҗе муниципаль районнарында (19.06.2018);



Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.М.Безуевский белән Арча муниципаль районында (13.03.2018);



Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе урынбасары Е.Ю.Степанова белән Югары Ослан (24.04.2018), Алексеевск (26.06.2018) муниципаль районнарында;



Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе урынбасары Э.Р.Лабашова белән Балык Бистәсе муниципаль районында (26.06.2018);



Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе урынбасары А.В.Михайлов белән Саба муниципаль районында (22.05.2018);



«Татарстан Республикасы буенча Баш медико-социаль экспертиза» Федераль казна учреждениесе җитәкчесе Р.Х.Низамов белән Яңа Чишмә (10.07.2018), Кайбыч (05.06.2018) муниципаль районнарында;



Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары А.М.Асадуллина белән Тукай (23.11.2018), Ютазы (27.11.2018), Чирмешән (04.12.2018) муниципаль районнарында;



Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминләштерү фондының Татарстан Республикасы идарәсе төбәк бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары К.Ш.Фатыйхов белән Саба муниципаль районында (22.05.2018);



Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре И.Х.Гарифуллина белән Республикасының 24 муниципаль районында һәм Казан шәһәре округында;



Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминләштерүенең Территориаль фонды директоры урынбасары М.В.Мөхәммәтҗанова белән Зәй муниципаль районында (11.09.2018).

Шул ук вакытта гражданнарны уртак кабул итүләрнең күпчелеге (32дән 25) республиканың муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында оештырылды. 2018 елда халыкны уртак кабул итүләрдә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә барысы 130 кеше мөрәҗәгать итте.





2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан ***“Балалар мәсьәләсе” хокукый ярдәм көннәрен*** үткәрү дәвам итте, ул чарага балалар хокукларын тәэмин итү өлкәсендә аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы тармак министрлыклары һәм ведомстволары, хокук саклау органнары, прокуратура вәкилләре җәлеп ителде. Хокукый ярдәм көннәре 2018 елның 1 июнендә Казан шәһәрендә һәм 30 октябрьдә Чаллы шәһәрендә үткәрелде. Бу чаралар кысаларында гражданнардан 143 мәсьәлә буенча 93 мөрәҗәгать керде.

2018 елда шулай ук дүрт ***кайнар телефон линиясе*** эше оештырылды, алар аша гражданнардан 261 мөрәҗәгать алынды. Тематика түбәндәге мәсьәләләргә кагылышлы иде:

балаларның гомуми белем бирү оешмаларының 1 сыйныфына укырга керүе турында (19 февраль, 2018 ел);

Татарстан Республикасында балаларның җәйге ялын оештыру турында (11 май, 2018 ел);

Татарстан Республикасында балаларга медицина хезмәте күрсәтүне оештыру турында (28 май, 2018 ел);

Татарстан Республикасының белем бирү оешмаларында балаларны ашатуны оештыру турында (18 октябрь, 2018 ел).







2018 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнардан кергән барлык язма һәм телдән мөрәҗәгатьләр законнарда билгеләнгән тәртиптә каралды һәм алар буенча балаларның бозылган хокукларын торгызу максатларында тиешле чаралар күрелде.

## 1.2. Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлегенә билгеләнгән компетенция чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешу-хокукый рәвешләре һәм милек рәвешләре нинди булуга карамастан, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан теләсә кайсы оешманың, аларның вазыйфаи затларының эшчәнлеген, алар тарафыннан бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тану һәм үтәү күзлегеннән чыгып, билгеләнгән компетенция чикләрендә тикшерү керә.

Түбәндәгеләр тикшерү чараларын уздыруга нигез була:

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ***гражданнардан кергән шикаятьләр*** буенча;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ***үз инициативасы белән;***

бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу фактлары турында башка теләсә нинди чыганаклардан кергән хәбәрләр һәм ***мәгълүмат керү буенча.***

Тикшерү эшчәнлеге, гадәттәгечә, урыннарга чыгып, тиешле документларны анализлау һәм өйрәнү (документар тикшерү) нигезендә башкарыла. 2018 елда, урыннарга чыгып, барысы 195 тикшерү оештырылды һәм уздырылды.

Ел дәвамында тикшерү эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 86 бәяләмә чыгарылды һәм аларны бетерү һәм тагын булдырмас өчен чаралар күрелде.

***Гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча*** 2018 елда 556 шикаять тикшерелде. Тикшерүләр тиешле хакимият органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына, шулай ук башка гражданнарга карата булган шикаятьләр буенча үткәрелде. 501 шикаять буенча тикшерүләр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан башка компетентлы органнар белән берлектә оештырылды:

172 тикшерү – федераль дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары белән берлектә (Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсе белән, Суд приставлары Федераль хезмәтенең Татарстан Ре-

спубликасы идарәсе белән, Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы территориаль органы белән, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән, Россия Федерациясе Тикшерү идарәсенең Татарстан Республикасы буенча Тикшерү комитеты белән берлектә);

40 тикшерү – Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары белән берлектә;

135 тикшерү – ведомство контроле тәртибендә республика дәүләт хакимияте органнары белән берлектә (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясебелән берлектә);

154 тикшерү – җирле үзидарә органнары белән берлектә (опека һәм попечительлек органнары, мәгариф бүлекләре (идарәләре), балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре, торак сәясәте һәм коммуналь хуҗалык бүлекләре белән).

Гражданнар шикаятьләрен карау нәтиҗәләре буенча 52% очракта (287 шикаять буенча) хокуклар бозылу фактлары расланды, балаларның бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызу буенча чаралар күрелде, мәсьәләләрне уңай хәл итүгә ирешеп булды.

Мөрәҗәгатьләрдә күрсәтелгән фактларны күпьяклы һәм объектив өйрәнү максатларында шикаятьләр 44 очракта учреждениеләргә йә гражданнар гаиләләренә чыгып тикшерелде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен тикшерүләр нәтиҗәләре буенча тиешле органнарга һәм вазыйфаи затларга бала хокуклары бозылу турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 47 бәяләмә җибәрелде, шулардан:

5 – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына;

1 – Дәүләт учреждениеләренә – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсенә;

1 – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына;

1 – Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына;

1 – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына;

1 – белем бирү учреждениеләре директорларына;

37 – республика муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, шул исәптән:

Әгерже муниципаль районы (1 бәяләмә),

Азнакай муниципаль районы (1 бәяләмә),

Әлмәт муниципаль районы (3 бәяләмә),

Баулы муниципаль районы (1 бәяләмә),

Алабуга муниципаль районы (1 бәяләмә),

Бөгелмә муниципаль районы (2 бәяләмә);

Биектау муниципаль районы (1 бәяләмә),

Зеленодольск муниципаль районы (2 бәяләмә),

Кама Тамагы муниципаль районы (1 бәяләмә);

Кукмара муниципаль районы (1 бәяләмә),

Лениногорск муниципаль районы (1 бәяләмә);

Түбән Кама муниципаль районы (3 бәяләмә),
Мөслим муниципального района (1 бәяләмә),
Тәтеш муниципаль районы (1 бәяләмә);
Ютазы муниципаль районы (1 бәяләмә);
Чистай муниципаль районы (2 бәяләмә),
Чаллы шәһәр округы (3 бәяләмә),
Казан шәһәр округы (10 бәяләмә).

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ***үз инициативасы белән*** түбәндәгеләрнең эшчәнлегенә күчмә тикшерүләр уздырылды:

республиканың төрле тәрдәге һәм ведомство буйсынуындагы балалар учреждениеләренең;

гавами хакимият (дәүләт, муниципаль) органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының.

Ел дәвамында балигъ булмаганнар өчен 103 учреждение тикшерелде. Тикшерүдә түбәндәгеләрнең эшчәнлеген оештыру аерым игътибарда булды:

*беренчедән, авыр тормыш шартларында калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрнең эшчәнлеге.*

2018 елда түбәндәгеләр тикшерелде:



балалар һәм яшүсмерләр өчен алты социаль приют (Аксубай, Әгерже, Чүпрәле, Менделеевск, Саба, Минзәлә муниципаль районнарында);

ике «ятим балалар» учреждениесе (Алабуга муниципаль районында сабыйлар йорты, акылга зәгыйфь балалар өчен Дәрвишләр интернат-йорты).

Бу оешмаларны тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган балигъ булмаганнарның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу буенча тәэсир итү чаралары күрелде һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына мөрәҗәгатьләр җибәрелде;



*икенчедән*, интернат учреждениеләргә (балалар тәүлек буе тора торган) – дәүләт *кадет интернат-мәктәпләренә аерым игътибар бирде.* 2018 ел дәвамында 3 дәүләт кадет интернат-мәктәбе тикшерелде (Казан шәһәрендә, Чирмешән, Спас муниципаль районнарында).

Тикшерү йомгаклары буенча балигъ булмаганнарның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында гамәлгә куючы адресына – Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына 2 бәяләмә җибәрелде;

*өченчедән,* җәйге чорда җәйге савыктыру кампанияләрен әзерләү һәм уздыру



мәсьәләләре, гадәттәгечә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым контролендә була. 2018 елда балалар савыктыру лагерьларында (алга таба – БСЛ) балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре тәэмин ителешен һәм үтәлешен тикшерү максатында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 13 муниципаль берәмлектә 50 БСЛда, шул исәптән 8 шәһәр чите стационар лагеренда, 30



мәктәп лагеренда, 4 палата лагеренда, 2 хезмәт һәм ял лагеренда тикшерү уздырылды.

Тикшерүләр барышында ачыкланган хокук бозулар, аларга карата искәрмәләр, аларны төзәтү буенча күрсәтмәләр лагерьлар җитәкчеләренә, аларны гамәлгә куючыларга җиткерелде, аларның күпчелеге тикшерү барышында яисә кыска вакытларда төзәтелде.

Шул ук вакытта, ике лагерьда (Әгерҗе муниципаль районының «Алмалы» БСЛда һәм Апас муниципаль районының «Йолдызлы десант» палата лагеренда) балалар өчен ял итү һәм аларны савыктыру буенча стационар оешмаларны оештыруга, тотуга һәм аларның эшләвен оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләренең җитди бозылуы ачыкланды. Шуңа бәйле рәвештә, гамәлгә куючылар адресына – Әгерҗе һәм Апас муниципаль районнары башлыкларына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ачыкланган хокук бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрүне таләп иткән бәяләмәләре җибәрелде.

Һәр хокук бозу факты буенча Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча республика ведомствоара комиссиясенә хәбәр ителде;

*дүртенчедән*, балалар өчен ябык типтагы махсус учреждениеләрдә торучы, закон белән конфликтка кергән балигъ булмаган балаларны тоту шартлары, укыту процессын оештыру, медицина ярдәме күрсәтү күзәтчелек итүнең төп предметы булып кала. 2018 ел дәвамында түбәндәгеләр тикшерелде:

«Н.А.Галлямов ис. республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» ябык типтагы дәүләт казна махсус укыту-тәрбияләү учреждениесе;

“Җәзалар үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсенең (УФСИН по РТ) 1 нче тикшерү изоляторы” федераль казна учреждениесе;



*бишенчедән*, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларның ата-аналарыннан кергән шикаятьләрне исәпкә алып, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балалар өчен махсуслаштырылган гомуми белем бирү учреждениеләре эшчәнлеге дә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибар үзәгендә булды (Казан шәһәре, Арча, Мамадыш, Питрәч, Зәй, Кукмара, Тукай, Спас, Менделеевск, Ютазы муниципаль районнарында). Тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында гамәлгә куючы адресына – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына биш бәяләмә җибәрелде;

*алтынчыдан*, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан түбәндәге түбәндәге *сәламәтлек саклау оешмалары* тикшерелде:

«Әтнә район үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (ГАУЗ) балалар поликлиникасы бүлекчәсе;

«Теләче район үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (ГАУЗ);

*җиденчедән, сәламәтлек мөкинлекләре чикле балалар өчен түбәндәге реабилитация үзәкләре тикшерелде:*

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Лаеш муниципаль районындагы мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен «Астра» реабилитация үзәге” ДАСХУ (ГАУСО);

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау



министрлыгының Мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен «Здравушка» реабилитация үзәге" ДАСХУ (ГАУСО);

сигезенчедән, республиканың аерым районнары һәм шәһәрләренең (Әгерже, Алексеевск, Әтнә, Апас, Югары Ослан, Зәй, Кайбыч, Питрәч, Саба, Кукмара, Балык Бистәсе, Спас, Менделеевск, Тукай, Чирмешән, Ютазы муниципаль







районнары, Казан шәһәре) гомуми белем бирү оешмалары, өстәмә белем бирү оешмалары, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тикшерелде.

Тикшерү чаралары барышында 13 гомуми белем бирү оешмасында хокук бозулар ачыкланды, шуңа бәйле рәвештә, түбәндәге муниципаль районнар башлыклары адресына балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу һәм аларны төзәтү буенча чаралар күрелергә кирәклеге турында 11 бәяләмә җибәрелде:

Әгерже муниципаль районы;

Алексеевск муниципального района;

Әтнә муниципаль районы;

Югары Ослан муниципаль районы;

Зәй муниципаль районы;

Питрәч муниципаль районы;

Саба муниципаль районы;

Балык Бистәсе муниципаль районы;

Менделеевск муниципаль районы;

Спас муниципаль районы;

Чирмешән муниципаль районы.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең күзәтчелек эшчәнлегендә *тиешле хакимият органнары эшчәнлеген* тикшерү дәвам итте.

Республика районнарына һәм шәһәрләренә эшлекле визитлар кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәтләр (опека һәм попечительлек органнары, мәгариф идарәсе органнары, сәламәтлек саклау, социаль яклау идарәләре, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча муниципаль комиссияләр) эшчәнлеге дә анализланды.



Шулай итеп, 2018 елда күрсәтелгән хезмәтләр эшчәнлеге 23 муниципаль районда, Казан шәһәренең Мәскәү һәм Киров районнарында анализланды.

Эш сәфәре кысаларында түбәндәге мәсьәләләр һәм эшчәнлек юнәлешләре өйрәнелде:

тәрбиягә бала алган ата-аналар тарафыннан опекун вазыйфаларының һәм хокукларының үтәлүен,



ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, гаиләтәрбиясенә алынган гражданнарның хокуклары һәм мәнфәгатьләре тәрбиягә алган ата-аналары ягыннан үтәлүен опека һәм попечительлек органы тарафыннан тикшереп тору вәкаләтләренең үтәлеше;

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар белән һәм аларның гаиләләре белән эшләү эшчәнлеге Татарстан Республикасының бердәм белешмәләр банкы нигезендә өйрәнелде;

шулай ук гаиләләрдән балаларны аерып алу практикасы өйрәнелде.

Күрсәтелгән эшчәнлекне өйрәнү нәтиҗәләре буенча ачыкланган хокук бозулар һәм мондый эштәге төгәлсезлекләр турында түбәндәге 20 муниципаль район (шәһәр округлары) адресына 28 бәяләмә җибәрелде:

Арча муниципаль районына (1 бәяләмә);

Алабуга муниципаль районына (3 бәяләмә);

Мамадыш муниципаль районына (2 з бәяләмә);

Югары Ослан муниципаль районына (1 бәяләмә);

Әтнә муниципаль районына (1 бәяләмә);

Саба муниципаль районына (2 бәяләмә);

Теләче муниципаль районына (1 бәяләмә);

Алексеевск муниципаль районына (2 бәяләмә);

Чистай муниципаль районына (1 бәяләмә);

Чүпрәле муниципаль районына (1 бәяләмә);

Яңа Чишмә муниципаль районына (1 бәяләмә);

Аксубай муниципаль районына (1 бәяләмә);

Балык Бистәсе муниципаль районына (2 бәяләмә);

Апас муниципаль районына (1 бәяләмә);

Зәй муниципаль районына (1 бәяләмә);

Менделеевск муниципаль районына (2 бәяләмә);

Спас муниципаль районына (1 бәяләмә);

Кукмара муниципаль районына (1 бәяләмә);

Тукай муниципаль районына (1 бәяләмә);

Ютазы муниципаль районына (1 бәяләмә).

Бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу фактлары, шул исәптән аерым җәмәгатьчелек резонансын алган фактлар турындагы ***хәбәрләр һәм мәгълүмат буенча*** да Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан берничә тикшерү уздырылды.

2018 ел дәвамында барлыгы 35 шундый вәзгыять анализланды.

Күрсәтелгән фактлар буенча уздырылган тикшерү чаралары йомгаклары буенча балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу һәм тиешле чаралар күрелергә кирәклеге турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 9 бәяләмә җибәрелде, шул исәптән: Алексеевск, Әлмәт, Зеленодольск, Ютазы муниципаль районнары башлыкларына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (2 бәяләмә), Татарстан Республикасы Прокуратурасына (3 мөрәҗәгать), шулай ук Татарстан Республикасында Эчке эшләр министрлыгына, Күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча элемтә, мәгълүмати технологияләр идарәсенә.


## 1.3. Балалар мәнфәгатьләрендә законнарны камилләштерүдә катнашу

Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын һәм муниципаль хокукый актларны камилләштерүгә ярдәм итү бурычларын гамәлгә ашыру максатларында 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил законнар, норматив хокукый актлар чыгару процессында катнашуын дәвам итте.

2018 елда елда балигъ булмаганнарның законнар белән гарантияләнгән хокукларына, шулай ук аларның мәнфәгатьләренә туры килүен алдан тикшерүгә 56 федераль һәм республика норматив хокукый акты (2017 елда – 36) керде.

*8 нче диаграмма*

***2014-2018 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан каралган федераль һәм республика норматив хокукый актлары саны***




Карауга кертелгән норматив хокукый актлар проектларына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан аларның халыкара хокук нормалары, федераль һәм республика законнары белән гарантияләнгән бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә туры килүе буенча бәйсез экспертиза үткәрелә һәм тиешле бәяләмәләр бирелә.

2018 елда каралган норматив-хокукый актлар арасында 26сы федераль җайга салу мәсьәләләренә кагылышлы иде. Болар – ***24 федераль закон проекты һәм 2 проект Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары буенча.*** Федераль законнар проектлары буенча үз фикереңне белдерү мөмкинлеге Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы тарафыннан балалар хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы федераль законнар проектларын Татарстан Республикасы Президентына килештерүгә җибәрү процедурасы кысаларында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.4 статьясы тәртибендә тәэмин ителә.

Аерым алганда, болар түбәндәге закон проектлары:

1. «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясына һәм «Граждан хәле актлары турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү турында (баланы аноним калдыру өчен махсуслаштырылган урыннар булдыру өлешендә);

2. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 33 статьясына үзгәрешләр кертү турында (инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре оешмаларын кече һәм урта эшкуарлык субъектларының ярдәм реестрына кертүдән баш тарту өчен нигезләрне төшереп калдыру өлешендә);

3. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү турында» (балигъ булмаганнарны комарлы уеннарга җәлеп итүдә, шулай ук комарлы уеннарны законсыз үткәрү турындагы белешмәләрне бирмәгән өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә);

4. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» (эзләү игълан ителгән бала табылган очракта, аны суд карары буенча кичекмәстән тапшырылырга тиешле затка кайтару һәм (яисә) аннан алу мөмкин булмаган очракта, приставлар-үтәүчеләр тарафыннан баланы опека һәм попечительлек органнарына тапшыру өлешендә);

5. «Россия Федерациясе Граждан кодексының 36 статьясына үзгәреш кертү турында» (балигъ булмаган гражданның опека һәм попечительлек органы рөхсәте белән ул попечительдән аерым торырга мөмкин дигән яшькә җитүен төгәлләштерү максатында);

6. «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» (уллыкка (кызлыкка) алу вакытына үги малай яки үги кыз булган балалар өчен ана (гаилә) капиталын алуга хокуклар барлыкка килгәндә уллыкка алынган балаларны исәпкә алу турында);

7. «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль законга һәм «Китапханә эше турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында (балалар өчен тыелган мәгълүмат продукциясен тарату өлешендә);

8. «Инвалид балаларны һәм бала чактан 1 төркем инвалидларны караучы затларга айлык түләүләр турында»;

9. «Вакытны исәпләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» (Россия Федерациясе территориясендә вакытны исәпләүне үзгәртү турында);

10. «Россия Федерациясе Гаилә кодексының 66 статьясына һәм «Опека һәм попечительлек турында» Федераль законның 15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» (ирегеннән мәхрүм ителгән урыннардагы ата-ананың баласы белән аралашуга, аны тәрбияләүдә һәм баланың белем алу мәсьәләләрен хәл итүдә катнашуга хокукы турындагы мәсьәлә буенча);

11. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» (хезмәт шартнамәсен үзгәрткәндә, йөкле хатынга һәм өч яшькә кадәрге баласы булган хатынга өстәмә гарантияләр өлешендә);

12. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәреш кертү турында» (балигъ булмаганнар затны санкцияләнмәгән гавами чарада катнашуга җәлеп иткән өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә);

13. «Граждан хәле актлары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» (бала тууны дәүләт теркәвенә алганда балалы гаиләләргә бирелә торган социаль яклау (ярдәм) чаралары, социаль хезмәт күрсәтүләр өлешендә);

14. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» (яшь ярымнан өч яшькә кадәрге баланы караган өчен айлык пособие срогын арттыру өлешендә);

15. «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 22 статьясына үзгәреш кертү хакында» (балигъ булмаганнарның сәламәтлеге турында мәгълүмат алу өлешендә);

16. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» (ярдәмчел репродуктив технологияләр куллану нәтиҗәсендә туган баланы дәүләт теркәвенә алу өлешендә);

17. «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» (ана (гаилә) капталы акчаларыннан бакча алу (төзү) яисә бакча җир кишәрлегендә урнашкан торак йортны алу максатларында файдалану юнәлешләрен өстәү өлешендә);

18. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына пенсияләр билгеләү һәм түләү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» (норматив пенсия яшен арттыру өлешендә);

19. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына балалар хокукларын яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында»;

20. «Балалы гаиләләргә айлык түләүләр турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» (беренче бала туууга (уллыкка алуга) бәйле айлык түләү акчаларыннан банк хезмәтләре күрсәткән өчен түләүләр алмау турында);

21. «Россия Федерациясендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында»;

22. «Россия Федерациясендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»;

23. «Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясына үзгәреш кертү турында» (күпбалалы гаиләләрдәге ата-аналарны физик затлар мөлкәтенә салымнан азат итү өлешендә);

24. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» (эзләү игълан ителгән бала табылган очракта, аны суд карары буенча кичекмәстән тапшырылырга тиешле затка кайтару һәм (яисә) аннан алу мөмкин булмаган очракта, приставлар-үтәүчеләр тарафыннан баланы опека һәм попечительлек органнарына тапшыру өлешендә).

Закон проектларына ясалган экспертизалар нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тиешле бәяләмәләр әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде, шуларның алтысы тискәре бәяләмә алып, карала торган закон проектын республика исеменнән хупламаска тәкъдим ителде.

Моннан тыш, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә карау һәм килештерү өчен «23 яшькә җитеп, торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кертелгән затлар исемлеген булдыру тәртибен раслау турында» һәм «23 яшькә җитеп, Россия Федерациясе субъектында элеккеге яшәү урынында торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кертелгән затларны исемлектән төшереп, аларны Россия Федерациясе субъектында элеккеге яңа яшәү урынында исемлекә кертү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары проекты һәм «2018-2021 елларга ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, алар арасыннан булган затларга торак урыннар бирү буенча чаралар комплексын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсе проекты керде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән алдан килештерү өчен кергән ***төбәк норматив хокукый актлар проектларының гомуми*** саны 2017 ел белән чагыштырганда ике мәртәбә артты һәм нәтиҗәдә 30 акт булды.

Республика норматив хокукый актлары проектларын (Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре проектларын) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан рәсми килештерү аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү стадиясендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты нигезендә башкарыла (әлеге Регламент белән 2013 елдан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив хокукый актлар проектларын килештерүдә катгый катнашырга тиешле вазыйфаи затлар исемлегенә кертелә). Республика законнары проектларын карауда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашуының тагын бер мөмкин формасы – закон проектлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары тарафыннан алдан карау стадиясендә Вәкаләтле вәкилгә кергән рәсми гарызнамәләр буенча бәяләмәләр бирү юлы белән һәм закон проектлары буенча эшләү өчен төзелә торган эшче төркемнәр утырышында комитетлар инициативасы белән катнашу.

Узган ел Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бала һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы түбәндәге 10 Татарстан Республикасы законы проектын карауда катнашты:

1. «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында;

2. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 статьясына үзгәрешләр кертү турында»;

3. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында;

4. «Татарстан Республикасында беренче бала туугa (уллыкка алуга) бәйле рәвештә айлык түләү билгеләүне һәм аны түләүне оештыру турында»;

5. «Татарстан Республикасында җан башына һәм төп социаль-демографик төркемнәр буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында;

6. «Татарстан Республикасында кулланучылар кәрзине турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында;

7. «Ихтыярыйчылык (волонтерлык) өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»;

8. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 14 статьялыра үзгәрешләр кертү хакында;

9. «Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында;

10. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында.


Шул ук вакытта 2018 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ризалыгыннан башка «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар

эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Закон кабул ителде.

Шулай итеп, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балигъ булмаганнарның һәм балалы гаиләләрнең мәнфәгатьләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарының күпчелек проектларын карауда катнашты.

*9 нчы диаграмма*

***2014 – 2018 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы законнары проектларын алдан килештерүдә катнашуын тәэмин итү***




Шулай итеп, 2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең кабул ителгән 7 республика законының 5сенә карата (71%) рәсми килештерү кысаларында үз фикерен әйтү мөмкинлеге булган иде, ә 2018 елда году Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына рәсми бәяләмә бирү һәм килештерү өчен балигъ булмаганнарның һәм балалы гаиләләрнең мәнфәгатьләренә кагылышлы республикасы законнары проектларының 90%ы керде. Шуны әйтергә кирәк, балигъ булмаганнарның һәм балалы гаиләләрнең мәнфәгатьләренә кагылышлы законнар чыгару процессына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне җәлеп итү практикасында уңай үсеш күзәтелә.

Төбәк законасты норматив хокукый актлар өлешендә 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18 карар һәм күрсәтмә проектлары һәм Татарстан Республикасы Президентының 2 указы проекты каралды, болар:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары (учреждениеләре) тарафыннан сатып алына торган азык-төлек товарларына максималь бәяләр булдыру турында» 2017 елның 25 сентябрендәге 715 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында;

3. «Әлки муниципаль районында «Березка» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют» дәүләт казна учреждениесен бетерү турында;

4. «Лениногорск муниципаль районында Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» реабилитация үзәге» социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт автоном учреждениесен бетерү турында;

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дини оешмалар тарафыннан төзелә торган мәгариф учреждениеләре эшчәнлеге турында» 1999 елның 30 июнендәге 401 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында;

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының, башка дәүләт органнарының һәм оешмаларының эшчәнлеге мониторингын оештыру һәм уздыру турында» 2011 елның 10 июнендәге 463 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында;

7. «Аерым социаль ярдәм чаралары күрсәткәндә мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категориясенә акчалата түләүләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хаыкда» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында;

8. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»;

9. «Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт автоном учреждениеләренең (акылга зәгыйфь балалар өчен интернат йортлар) тибын үзгәртү юлы белән Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт казна учреждениеләрен төзү турында»;

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хәлен яхшырту буенча беренче чират чаралар турында» 2003 елның 16 маендагы 266 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында;

11. «Татарстан Республикасында 2018 елның III кварталына җан башына һәм төп социаль-демографик төркемнәр буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында»;

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2018 елларга Татарстан Республикасында Кеше хокуклары стратегиясен раслау турында» 2014 елның 2 августындагы 569 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында;

13. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»;

14. «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру буенча Координация советын төзү турында»;

15. «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара комиссиясен раслау турында»;

16. «Сәләт» Халыкара яшьләр мәгариф форумын алты саенада уздыру турында»;

17. «2018 – 2022 елларга гаиләне алыштыручыларда тәрбияләнүче, шулай ук ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда торучы ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын яклауны көчәйтүгә юнәлдерелгән өстәмә чаралар комплексын раслау турында»;

18. «Алимент түләүләре буенча бурычларны алуны тәэмин итү буенча ведомствоара эшче төркем булдыру турында»;

19. «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссияләре әгъзалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында»;

20. «Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының,

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының, башка дәүләт органнарының һәм оешмаларының эшчәнлеге мониторингын оештыру һәм уздыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында».

Шулай да, 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән килештермичә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан теге яисә бу яктан балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына кагылышлы түбәндәге каралар кабул ителде:

«2019 – 2021 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга ярдәм итү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында» (29.10.2018 № 961);

«Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында сәләтле балаларны ачу һәм аларга ярдәм итү буенча төбәк үзәген төзү турында» (29.10.2018 № 963);


«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан интернат тибындагы сәләтле балалар өчен махсуслаштырылган оешмаларга ярдәм» грантларын бирү тәртибен раслау турында» (20.11.2018 № 1015);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында сәләтле балаларны ачу һәм аларга ярдәм итү буенча төбәк үзәген төзү турында» 2018 елның 29 ноябрендәге 963 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында» (26.11.2018 № 1048).

Балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү күзлегеннән караганда, мондый практиканы булдырмаска кирәк дип саныйбыз.

*10 нчы диаграмма*

***2014 – 2018 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары проектларын алдан килештерүдә катнашуын тәэмин итү***




Шуны билгеләп үтәргә кирәк, 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы актлары (карарлары һәм күрсәтмәләре) проектларын алдан килештерүдә катнашуын тәэмин итү эше башка еллардагыга караганда беркадәр яхшырды. Әгәр 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил республикада кабул ителгән карарларның һәм күрсәтмәләрнең 29% (ягъни 17 проекттан 5) буенча рәсми килештерү кысаларында үз фикерен белдерә алган булса, 2017 елда 50% (20дән 10) Татарстан Республикасының норматив хокукый акты Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән ал-

дан килештерелде, ә 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы карарларының һәм күрсәтмәләренең 82%ы (22дән 18) керде.

Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары 2019 елда үзләренең норма чыгару эшчәнлеген, балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы барлык төбәк норматив хокукый актлар проектларын Вәкаләтле вәкил белән алдан килештерүне һичшиксез тәэмин итүне истә тотып, дәвам итәргә тиешләр, дип саныйбыз.


## 1.4. Балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашу

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашуы гамәлдәге федераль граждан-процессуаль һәм җинаять-процессуаль законнар кысаларында гамәлгә ашырылды. Вәкаләтле вәкилгә әлегә кадәр мөстәкыйль рәвештә процессуаль хокук бирелмәгән һәм шуңа күрә ул хокук суд процессында бәхәснең асылы буенча (эштә катнашучы затлар үтенечнамәсе буенча) мөстәкыйль таләпләр куя алмый торган өченче зат буларак, йә Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Граждан-процессуаль кодексының 47 статьясындагы 2 өлеше нигезендә (суд инициативасы белән) бала хокукларының һәм мәнфәгатьләренең яклануына дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән дәүләт вазыйфаи заты буларак кына катнаша.

Бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законда билгеләнгән тәртиптә суд яклавында катнашу белән бергә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлегендә киңәш бирү, процессуаль документлар төзүдә һәм кирәкле материаллар туплауда ярдәм рәвешендә судта граждан эшен карауга әзерлек кысаларында юридик ярдәм күрсәтү (алга таба – юридик ярдәм) актив башкарыла.

*11 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан яисә юридик яктан ярдәм күрсәткән суд процесслары саны***




Узган хисап чорында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 28 суд эшендә катнашты (2015 елда – 8 эш, 2016 елда – 25 эш, 2017 елда – 31 эш). Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында булган суд эшләренең гомуми санынннан 25 очракта – эш буенча якларның берсе инициативасы белән, 5 очракта суд инициативасы белән Россия Федерациясе Граждан-процессуаль кодексының 47 статьясындагы 2 өлешендә каралган тәртиптә дәүләт вазыйфаи заты буларак суд эшен карауга җәлеп ителде.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең суд практикасын, юридик хезмәт күрсәтүне дә кертеп, түбәндәгеләргә бәйле бәхәсләр тәшкил итте:

балаларның яшәү урынын билгеләүгә;

ата-ананың берсе белән генә яисә туганнары белән яшәүче баланың аралашу тәртибен билгеләүгә;

балигъ булмаганнарның, шул исәптән ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын яклауга. Болар – торактан чынару һәм теркәлү исәбеннән төшереп калдыру, торак алу-сату алыш-бирешен гамәлгә яраксыз дип тану, торакка мохтаж дип танудан һәм тиешле исемлеккә кертүдән баш тарту турындагы бәхәсләр;

ата-ана хокукларын чикләүгә (мәхрүм итүгә);

сыйфатсыз медицина ярдәме аркасында китерелгән мораль зыянны түләтүгә;

балигъ булмаган балаларны алып, аларны опекунга тапшыруга;

бурычлы мирас алганда, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга;

намус һәм абруйны яклауга бәйле.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең суд практикасында яңалык – түбәндәгеләр турында таләпләрне (гаризаларны) карауга бәйле суд процессларында катнашу булды:

оешманы бетерүгә, юридик затларны Бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыруга һәм оешманы бетерү вазыйфаларын йөкләүгә бәйле;

ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның элек биләгән Татарстан Республикасы торак урыннарында яшәү мөмкин булмау шартларын билгеләү буенча ведомствоара комиссиясе карарын законсыз дип тануга бәйле.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан суд бәхәсләренең асылыннан күренгәнчә, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өчен дәлилле бәяләмәләр китерелде һәм граждан эшләре судларының карау нәтиҗәләре буенча барлык карарлар ел дәвамында аның фикерен исәпкә алып чыгарылды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне суд эшләрендә катнашуга җәлеп итү практикасының артуы республика судларының балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга бәйле бәхәсләрне бала мәнфәгатьләрендә законлы һәм гадел хәл итәргә омтылулары белән аңлатыла.

2018 елның 27 декабрендә «Россия Федерациясендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Федераль закон кабул ителгәч, Россия Федерациясе субъектларында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр дәүләт хакимите органнарының, җирле үзидарә органнарының, аерым дәүләт яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгәгә органнарның һәм оешмаларның, вазыйфаи затларның, дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрләрнең карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип тану турындагы административ дәгъва гаризалары белән, әгәр дәгъвалана торган карарлар гамәлләр (гамәл кылмаулар) Россия Федерациясенең норматив хокукый актына туры килми, балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен боза, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга тоткарлык тудыра дип уйланылса яки аларга законсыз рәвештә нинидидер вазыйфалар йөкләнгән булса, балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап, судка мөрәҗәгать итү өчен өстәмә хокук алдылар.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә шундый хокук бирү тиешле дәүләт хакимияте органнары, муниципаль органнар һәм оешмалар ачыкланган бала хокуклары бозылу турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бәяләмәләрендәге таләпләрне үтәмәгән йә тиешенчә үтәмәгән очракта аеруча әһәмиятле. Мондый хәлдә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең тәэсир итү чаралары хәлиткеч була һәм аның ягыннан балалар

хокукларын алга таба яклау бары тик башка күзәтчелек органнарына, иң элек, прокуратура органнарына мөрәҗәгать итү юлы белән генә мөмкин була. Федераль законнардагы яңалыклар, һичшиксез, балалар омбудсменнарының хокук яклау вәкаләтләрен көчәйтте һәм бала хокуклары бозылу вәзгыятьләрен балалар мәнфәгатьләрендә ахырга кадәр хәл итү өчен күбрәк мөмкинлекләр бирде.

## 1.5. Аналитик эшчәнлек

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эксперт-аналитик эшчәнлегенең әһәмиятле юнәлеше Татарстан Республикасында бала хокуклары һәм аларның законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү вәзгыятен бәяләү буенча да, шулай ук аерым мәсьәләләр һәм муниципаль берәмлекләр буенча да аналитик материаллар әзерләүдән гыйбарәт.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 2017 елда Татарстан Республикасында ***балалар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында чираттагы сигезенче еллык нотык әзерләнде.***






2018 елның 17 мартында «2017 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында» нотык (алга таба – нотык) Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка тапшырылган иде. Рәсми очрашу кысаларында Татарстан Республикасы Президентына 2018 елда Татарстан Республикасында балалар хокукларын гамәлгә ашыру буенча төп проблемалы мәсьәләләр турында һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлеге нәтиҗәләре хакында хәбәр ителде.

2018 елның 22 мартында Нотык Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында тыңланды.

Законның 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Нотык шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Прокурорына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына җибәрелде.

Нотыктагы төп тәкъдимнәрне карау йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан беренче мәртәбә ***Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәләре исемлеге*** (***28.03.2018 № ПР-110)*** расланды, аның белән Республикасы министрлыкларына һәм ведомстволарына, Татарстан муниципаль берәмлекләре башлыкларына Нотыктагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын күрергә, шулай ук балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү чаралары комплексын эшләргә тәкъдим итте.



2018 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең төп юнәлеше югарыда күрсәтелгән Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәләре исемлеген үтәүне контрольдә тотуга юнәлгән иде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аның каршындагы Координация комитеты әгъзалары белән берлектә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның 2018 елгы Нотык йомгаклары буенча йөкләмәләрен үтәүнең барышын анализлады. Координация комитетының өч утырышында тиешле хакимият органнарының җитәкчеләре тыңланды.

2018 елгы Нотык тәкъдимнәрен үтәүгә анализ әлеге Нотыкның тиешле бүлекләрендә бирелде.

Бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү мәсьәләләре буенча ***тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Президентына кертү хокукыннан файдаланып,*** 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка түбәндәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итте:

Татарстан Республикасында 8 һәм аннан күбрәк балалар тәрбияләүче күпбалалы гаиләләр турында;

Татарстан Республикасы мәктәпләрендә конфликтларны профилактикалау чаралары күрү турында;

Татарстан Республикасы мәгариф системасында гаиләдә белем бирү формасы турында;

Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының 1 һәм 10 сыйныфларына балаларны алганда хокук бозуларны профилактикалау чаралары күрү турында;

балаларны дәүләт йомгаклау аттестациясе бирүгә кертмәүне профилактикалау чаралары күрү турында;

Татарстан Республикасында балаларга наркологик ярдәм күрсәтү системасын үстерү чараларын кабул итү турында;

Татарстан Республикасында Балалар онкологиясе үзәген төзү турында;

балигъ булмаган Е.не «Руксолитиниб» («Джакави») дару препараты белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча;

«Лаеш муниципаль районының Ташкирмән төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ бердәм комплексы базасында аны капиталь ремонтлау кысаларында спорт залы төзү турында;

балалар һәм яшьләр арасында «Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» бишенче республика видеороликлар конкурсын уздыруга ярдәм итү турында;

бала өчен аның туган гаиләсен саклап калуга һәм социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлдерелгән «Точка трезвости» (“Аек акыл”) проектын гамәлгә ашыруда ярдәм итү турында;



ятим балаларны гаиләгә урнаштыруда һәм «ВИДЕОПАСПОРТ ребенка» (“Баланың ВИДЕОПАСПОРТЫ”) проектын гамәлгә ашыруда ярдәм итү турында.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан ***бала хокукларын яклауның аерым мәсьәләләре буенча түбәндәге махсус нотыклар*** әзерләнде:

«Интернет челтәрендә балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чаралар күрү турында», ул видеоконфернцэлемтә режимында Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгында мәгариф идарәсенең муниципаль органнары киңәшмәсендә тәкъдим ителде (25.01.2018 ел);



«Балигъ булмаган балаларның интернет-иминлеге турында», ул «Клуб Сторонников» (“Тарафдарлар клубы”) федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында «БЕРДӘМ РОССИЯ» сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлекчәсе тарафдарлары тарафыннан «Интернет» челтәрендә балалар һәм яшүсмерләр иминлеге» темасына оештырылган дискуссия мәйданчыгында тәкъдим ителде (31.01.2018 ел);



«Татарстан Республикасында балалар хәвефсезлеген профилактикалау турында», ул «Татарстан Республикасында гражданнар активистлар эшчәнлегендә балигъ булмаганнар арасында сукбайчылыкны һәм хокук бозуларны профилактикалауның гамәлдәге дәүләт дәүләт-иҗтимагый моделен камилләштерү» республика конференциясендә тәкъдим ителде (19.04. 2018 ел);

«Балалар мәнфәгатьләрендә суд практикасы турында», ул «Граждан эшләрен караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр турында» темасына Татарстан Республикасының район (шәһәр) судлары судьялары һәм җәмәгать судьялары семнар-киңәшмәсендә тәкъдим ителде (25. 04. 2018 ел);

«О проблемных вопросах деятельности органов опеки и попечительства в Республике Татарстан», заслушанный на заседании Республиканской комиссии по делам несовершеннолетних и защите их прав (19 сентября 2018 г.).



«Россия Федерациясе ндә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институтының балалар һәм хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү эшчәнлеге турында», ул Россия Федерациясе Прокуратура университетының Казан юридик институтында (филиалында) «Балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау турындагы законнарны үтәүнең актуаль мәсьәләләре» темасына “түгәрәк өстәл” утырышында тәкъдим ителде (21.06. 2018 ел);

«Балигъ булмаган балалар өчен алимент алу буенча өстәмә чаралар күрү турында», «Ныклы гаилә» сәяси проектын Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру буенча Иҗтимагый совет утырышында тәкъдим ителде (22.10.2019);

Республикада балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга тәэсир итү мөмкинлегеннән чыгып караганда, Татарстанның конкрет муниципаль районнары дәрәҗәсендә балалар хокукларын үтәүнекң торышы анализланды. 2018 ел дәвамында республиканың 24 районы буенча шундый анализ ясалды (районнар исемлекләре «Эш визитлары» бүлегендә бирелде). Тиешле районнарда яшәүче балаларның хокукларын тәэмин итүгә комплекслы анализ аларның барлык тормыш эшчәнлеген үз эченә ала. Бу анализ Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил таләбе буенча районнар бирә торган мәгълүмати-аналитик материалларны өйрәнүгә һәм шул территорияләргә эш сәфәрләре йомгакларына нигезләнә. Конкрет муниципалитетларда балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәүнең актуаль мәсьәләләренә анализ Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан эш сәфәрләре кысаларында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль районнар комиссияләре утырышларында ясала.



## 1.6. Эш визитлары

Республиканың муниципаль берәмлекләре дәрәҗәсендә балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү дәрәҗәсенә реаль тәэсир итү күзлегеннән чыгып, 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең системалы нигездә республиканың муниципаль районнарына һәм шәһәр округларына эш визитларын оештыру һәм уздыру практикасы дәвам итте.

Ел дәвамында 24 эш визиты оештырылды. Мондый эш рәвеше республиканың 23 район (шәһәр) муниципаль берәмлегендә оештырылды, болар:

Арча муниципаль районы,
Алабуга муниципаль районы,
Мамадыш муниципаль районы,
Югары Ослан муниципаль районы,
Питрәч муниципаль районы,
Әтнә муниципаль районы,
Саба муниципаль районы,
Кайбыч муниципаль районы,
Теләче муниципаль районы,
Әгерҗе муниципаль районы,
Алексеевск муниципаль районы,
Чүпрәле муниципаль районы,
Яңа Чишмә муниципаль районы,
Аксубай муниципаль районы,
Балык Бистәсе муниципаль районы,
Апас муниципаль районы,
Зәй муниципаль районы,
Менделеевск муниципаль районы,
Спас муниципаль районы,
Кукмара муниципаль районы,
Тукай муниципаль районы,
Ютазы муниципаль районы,
Чирмешән муниципаль районы,
Казан шәһәренең Киров һәм Мәскәү районнары.

Эш визитлары форматы түбәндәге мәсьәләләргә комплекслы һәм системалы караш тудыра:

һәр муниципаль районда (шәһәр округында) бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлешенә анализ ясау;

ачыкланган хокук бозуларны торгызуга тәэсир итү буенча чаралар күрү;

районның (шәһәрнең) яшьләрен яклау мәнфәгатьләрендә җирле хакимият органнарының эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.





Вәкаләтле вәкилнең һәр эш визиты аны әзерләүнең һәм уздыруның стандарт тәртибен күздә тота.

Һәр визит җитди ***әзерлек эшеннән*** башлана, аның кысаларында Бала хокуклары буенча

вәкаләтле вәкил таләбе буенча муниципаль хезмәтләр тапшырган түбәндәге мәгълүмати материаллар анализлана:

«Муниципаль районда (шәһәр округында) балалар хокукларын саклауның торышына анализ» буенча тутырылган еллык форма;

гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исемлеге, балаларның мөлкәте турындагы белешмәләр, (торак, акчалата түләүләр), аларның сәламәтлеге торышы, балаларның җәйге ялы һәм аларны савыктыру, өстәмә белем бирү, балигъ булмаганнарның торак хокукларын гамәлгә ашыру;

социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр исемлеге, аларга күрсәтелә торган ярдәм (реабилитация) чаралары;

соңгы өч елда төрле сәбәпләр буенча гаиләләрдән алынган балалар исемлеге.

Вәкләтле вәкилнең һәр визиты ***муниципаль район башлыгы белән очрашуны күздә тота***, һәр конкрет муниципаль берәмлектә (шәһәр округында) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре буенча фикер алышына.





***Гражданнарны*** – район (шәһәр) кешеләрен кабул итүне оештыру да эш визитлары программасының катгый пункты булып санала. Республика районнарында һәм шәһәрләрендә гражданнарны урыннарда кабул итүләр вакытында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә барысы 118 кеше мөрәҗәгать итте.





Балалар ***учреждениеләре эшчәнлеген, шулай ук муниципаль хезмәтләр эшчәнлеген*** тикшерүгә дә зур игътибар бирелә.

Районнарның *аерым балалар учреждениеләрен тикшерүгә* теләсә кайсы мәгариф учреждениесе, ведомство буйсынуына һәм милек рәвешенә бәйсез рәвештә, район (шәһәр) территориясендә урнашкан ял итү, сәламәтлек саклау, спорт оешмалары эләгергә мөмкин. Визитлар кысаларында барысы 53 учреждение тикшерелде.





Эш тәртибендә, балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин буенча аерым вәкаләтләрне башкаручы ***муниципаль хезмәтләрнең*** (опека һәм попечительлек органнары, җирле үзидарә органнары, мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль яклау органнары, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре) тиешле белгечләрен һәм җитәкчеләрен чакырып, аларның эшчәнлегенә анализ ясала. Барлыкка килә торган проблемаларны эш тәртибендә “җанлы” сөйләшеп хәл итү, катлаулы мәсьәләләр буенча аңлатмалар, консультацияләр бирү форматы балалар өлкәсендә эшләүче белгечләрнең һөнәри компетенцияләрен күтәрергә ярдәм итә. Моннан тыш, тикшерү эшчәнлегенең мондый рәвеше нәтиҗәлерәк. Шул ук вакытта, өстәмә төбәк яисә федераль җайга салуны таләп итә торган проблемаларны ачыкларга мөмкинлек бирә.

2018 елда түбәндәгеләр тикшереп анализланды:

гаилә һәм балаларның имин булуын профилактикалау субъектлары органнарының социаль куркыныч хәлдәге балаларны һәм гаиләләрне реабилитацияләү һәм аларга ярдәм итү эшчәнлеге;

республиканың социаль приютларында торучы балигъ булмаганнар белән индивидуаль профилактик эш оештыру;

ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның тәрбиягә алган гаиләләрдә хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше, бу категория балаларны диспансеризацияләү мәсьәләләрен дә кертеп, инвалид балаларны реабилитацияләү чараларын гамәлгә ашыру, ятим балаларны торак алу исәбенә кую;

опека һәм попечительлек органнарының алыштыручы гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау эшчәнлеге, шул исәптән опекадагы балаларның җәйге ялын, өстәмә белем системасында аларның мәшгульлеген оештыруны тикшереп тору;

балаларны гаиләдән алу практикасын анализлау;

муниципаль районда гаиләдә һәм инклюзив белем бирүне оештыру мәсьәләләре;

балигъ булмаганнарны тотуга алимент түләүләре буенча бурычларны алу эшенең торышы;

балигъ булмаганнарның җинаять кылу һәм балигъ булмаганнарга карата җинаять кылу торышы;

балигъ булмаганнарның суицидаль халәтен профилактикалау мәсьәләләре;

профилактик прививкалардан һәм туберкулезны диагностикалаудан баш тарту мәсьәләләре;

балаларның башлангыч инвалидлыгы дәрәҗәсе.





Эш визиты һәр районда балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча ***муниципаль комиссиянең киңәйтелгән утырышында башлангыч йомгаклар ясау белән тәмамалана***. Утырышта, кагыйдә буларак, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән тыш, район башлыгы, район прокуроры катнаша, шулай ук аңа муниципаль хакимитнең тиешле органнары җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципа-

литет территориясендә үз эшчәнлеген башкаручы барлык балалар учреждениеләренең җитәкчеләре һәм белгечләре чакырыла.





Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең киңәйтелгән утырышлары конкрет районның, шәһәрнең аеруча мөһим мәсьәләләре буенча ачыктан-ачык фикер алышу өчен иң шәп мәйданчык булып санала.





Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визиты җирле массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртылып барыла, бу исә районның киң җәмәгатьчелеге игътибарын балалар хокукларын яхшырак тәэмин итү зарурлыгына юнәлтергә мөмкинлек бирә.



Эш визиты йомгаклары буенча бала хокуклары һәм мәнфәгатьләренең системалы рәвештә бозылу очраклары ачыкланганда, район башлыгы адресына тиешле бәяләмәләр җибәрелә. 2018 елда визитлар йомгаклары буенча барысы 32 бәяләмә җибәрелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең берничә еллар дәвамында шундый форматтагы эшчәнлеге республика территориясендә балаларның хәлен яхшыртуда нәтиҗәле механизм булуын күрсәтте.

2019 елда да әлеге эшчәнлек юнәлеше расланган план кысаларында дәвам итәчәк.

## 1.7. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координацион комитет эшчәнлеге

Бала хокукларын яклауның нәтиҗәле системасы бары тик республиканың балалар өлкәсендә ведомствоара тыгыз хезмәттәшлеккә һәм эшләүче барлык органнарның һәм структураларның үзара мөнәсәбәтенә корыла. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлегенә ярдәм итү вәкаләтләренә таянып, республикада 2016 елдан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Координацион комитет (алга таба – Координацион комитет) төзелде.

Координацион комитеты ведомствоара даими эшләүче, җайга салучы һәм консультатив-киңәшләшү органы буларак, балигъ булмаган баланың хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә дәүләт гарантияләрен көчәйтүне тәэмин итү максатларында төзелгән иде.

**Координацион комитетның төп бурычлары**




Координацион комитет утырышларында бала хокукларын бозуның системалы, шулай ук шәхси характердагы вәзгыятьләр, шул исәптән катлаулы һәм резонанс очраклары карала. Әлеге органның төп бурычы балалар мәнфәгатьләрендәге вәзгыятьләрне хәл итү буенча системалы, перспектив, килештерелгән карарлар эшләүдән һәм кабул итүдән гыйбарәт.

Координацион комитет составына Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы идарәсе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләре керә. Утырышларда барлык мәсьәләләр Татарстан Республикасы прокуратурасы вәкилләре катнашында карала. Координацион комитет утырышына шулай ук конкрет карала торган мәсьәләгә кагылышлы булган вазыйфаи затлар һәм гражданнар чакырыла.

2018 ел дәвамында Координацион комитетының 10 утырышы узды, аларда проблемалы 17 мәсьәлә каралды.

Каралган барлык мәсьәләләрнең 6сы бала хокукларын бозуның аерым очраклары буенча фикер алышуга һәм карарлар кабул итүгә кагылышлы иде.

***Мисал**: Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә фенилкетонуриядән зыян күрүче балаларның ата-аналары Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү оешмаларындагы балаларның туклануын*

*оештыру мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иттеләр. Бу ата-аналарга балалар бакчасына балаларын, махсус тукландыру булмаганга күрә, тулы булмаган көнгә йөртергә тәкъдим ителгән.*
*Барлыкка килгән вәзгыятьне төрле структуралар бергәләп хәл итәргә тиешлекне исәпкә алып, бу мәсьәлә Координацион комитет каравына чыгарылды.*
*Шундый фикер алышу йомгаклары буенча 17 майда «Казан шәһәренең Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» МУП, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе һәм Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә гамәлләрнең килештерелгән алгоритмы эшләнде. Координацион комитет карары белән тиешле йөкләмәләр бирелде.*
*Координацион комитетның 12 июлендә узган утырышында Мәгариф идарәсе мәгълүматы тыңла,нды, анда 2018 елның 1 сентябрендә Казан шәһәре Совет районының катнаш типтагы 135 нче балалар бакчасында махсус дәвалау-савыктыру чараларын уздыруга мохтаҗ балалар өчен аерым төркем ачуга әзерлек турында әйтелде. Бу төркемгә фенилкетонуриядән интегүче балалар йөри ала. 1 сентябрьдән мондый төркем эшли башлады. Балаларның мәктәпкәчә белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләсе хәл ителде.*

Координацион комитет утырышларында каралган башка мәсьәләләр чикләнмәгән сандагы балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы системалы характердагы проблемалар иде, шул исәптән:

Татарстан Республикасында мәктәпкәчә гаилә төркемнәре эшчәнлеген оештыру;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 июлендәге № 1739-р күрсәтмәсе белән расланган 2017 – 2019 елларга медиакиңлектә балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планын (“юл картасын”) үтәүнең барышы;

гомуми белем бирү оешмаларында мәгълүмати иминлекне оештыру һәм балалар оешмаларында куелган контент фильтрациясе һәм антивирус яклавы системасына ярдәм итү;

балаларны вакцинопрофилактикалу һәм туберкулинодиагностикалау буенча өстәмә чаралар күрү;

баланың атасын билгеләү буенча гаризаларны граждан хәле актларын теркәү органнарында караганда, балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше күзлегеннән чыгып, баланың атасын билгеләүнең гамәлдәге тәртибе һәм практикасы;

Россия Федерациясе президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 1992 елның 5 маендагы 431 номерлы Указы нигезендә гомуми белем бирү мәктәбендә балаларның уку чорына күпбалалы гаиләләрне билгеләнгән нормативлар нигезендә мәктәп формасы белән йә мәктәпкә йөрү өчен мәктәп формасын алыштыра торган балалар киеме комплекты белән, шулай ук спорт белән шөгыльләнү өчен форма белән укыту акчалары яисә бюджеттан тыш башка чыганаклардан бушлай тәэмин итү;

2018 елда тышкы сәбәпләрдән балалар үлемен анализлау.

Моннан тыш, 2018 елда Координацион комитет утырышлары кысаларында 2017 ел өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең нотыгы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның 2018 елның 28 мартындагы ПР-110 Йөкләмәләр исемлегенең дәүләт органнары тарафыннан үтәүнең барышы каралды.





Координацион комитетка фикер алышуга чыгарылган барлык мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча тиешле карарлар кабул ителде, алар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан расланган беркетмә белән рәсмиләштерелде. Алардагы йөкләмәләрнең күрсәтмә хакрактерында булуына карамастан, 2018 елда уртак ирешелгән килешүләрнең үтәлмәү очраклары булмады. Ихтыярый хезмәттәшлеккә һәм үзара аңлашуга нигезләнгән эш форматы Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итүдә һәм яклауда нәтиҗәле механизм булуын раслады.

## 1.8. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Гаиләдән балаларны алу практикасын анализлау буенча эшче төркем эшчәнлеге

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Гаиләдән балаларны алу практикасын анализлау буенча тагын бер даими җайга салучы ведомствоара органы (алга таба – Эшче төркем) эшли. Ул 2017 елда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның 2017 елның 30 гыйнварындагы 4606-МР номерлы боерыгын үтәү йөзеннән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиленең 2017 елның 3 февралендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Эшче төркем төзү турында»гы боерыгы белән төзелде.

Бу органның эшчәнлек максаты – тиешеннән артык чаралар кулланып яисә гаилә хокукын бозып, аңа тыкшыну юлы белән гаиләдән балигъ булмаган балаларны алуга һәрьяклы анализ ясаудан гыйбарәт.

**Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Эшче төркем бурычлары**




Эшче төркем составына кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре, шулай ук җәмәгатьчелек вәкилләре (Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләре) керә. Төркем эшендә даими рәвештә Татарстан Республикасы прокуратурасы вәкиле катнаша.

Республикаса буенча балаларны гаиләләрдән алу практикасын кварталлап мониторинглаудан тыш, 2018 ел дәвамында системалы рәвештә Татарстанның муниципаль районнары дәрәҗәсендә балаларны алу очракларына анализ ясалды. Шундый мониторинг Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визитлары кысаларында, урыннарга чыгып, 25 район һәм шәһәр муниципалитетларында уздырылды.

Бу эш йомгаклары буенча гаиләдән балаларны законсыз алу фактлары 4 муниципаль районда (Алексеевск, Мамадыш, Саба, Чистай) ачыкланды, шуңа бәйле рәвештә әлеге районнарга хоку бозулар һәм аларны бетерү чараларын күрү турында тиешле бәяләмәләр җибәрелде.

Татарстан Республикасында балаларны гаиләләрдән алу вәзгыятен Эшче төркем тарафыннан системалы рәвештә өйрәнүдән, анализлаудан, кирәк булса, тиешле чаралар күрүдән тыш, Эшче төркем гражданнардан кергән шикаятьләр буенча аерым очракларны да карады. Ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Эшче төркем адресына гражданнардан 14 мөрәҗәгать керде, шул исәптән:

Биектау, Кама Тамагы, Кукмара, Бөгелмә, Әлмәт (2), Актаныш, Балык Бистәсе районнарында, Казан шәһәрендә (3 очрак) гаиләләрдән балаларны алуның 11 факты буенча 13 хәбәр алынды;

Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан ата-аналарны балаларын социаль приютка урнаштыруга мәҗбүр итү факты буенча 1 хәбәр алынды.

Балаларны гаиләләрдән алу фактлары турындагы һәр хәбәр Эшче төркем әгъзалары тарафыннан оператив тәртиптә каралды, шул исәптән гаиләләрнең яшәү урыннарына барып та.





Тикшерү йомгаклары буенча Казан шәһәрендә (2), Әлмәт (2), Актаныш, Бөгелмә, Балык Бистәсе муниципаль районнарында гаиләләрдән балаларны алуның 11 фактыннан 8 факт буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең дәлилләре расланмады, балаларны алу буенча күрелгән чаралар законлы һәм балалар мәнфәгатьләрендә һәм аларны яклау өчен башкарылган дип танылды.

Казан шәһәрендә, Биектау, Кама Тамагы муниципаль районнарында гаиләләрдән балаларны алуның калган 3 факты буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең балалар законсыз алыну турындагы дәлилләре расланды – балаларны алу буенча күрелгән чаралар законга нигезләнмичә, гаиләдән балаларны алу аларның хокукларын бозып башкарылган дип танылды. Шуңа бәйле рәвештә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан район җитәкчелеге исеменә, балаларны социаль приютлардан алып, кичекмәстән гаиләләренә кире кайтару буенча тиешле таләпләр җибәрелде, нәтиҗәдә, алар канәгатьләндерелде.

Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан ата-аналарны балаларын социаль приютка урнаштыруга мәҗбүр итү факты буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Зеленодольск муниципаль районы башлыгы исеменә «аварийщиклар» гаиләләреннән балаларны алу белән янауларны бетерү буенча кичекмәстән чаралар күрү таләпләре белән бәяләмә җибәрелде, шул исәптән ата-аналарның мөрәҗәгате буенча, балаларны социаль приютларга урнаштыруга аларны мәҗбүр итүләрне туктату буенча да.

## 1.9. Проект эшчәнлеге

Бала хоукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү механизмын камилләштерүгә юнәлдерелгән эшчәнлек кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил төрле проектларны гамәлгә ашыруга актив кушылды.




Татарстан Республикасында 2011 елдан Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов тәкъдиме белән башланып киткән **«Баланың видеопаспорты»** проекты Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында системалы рәвештә гамәлгә ашырыла. Проектның максаты – ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру процессын активлаштыру, **«Баланың видеопаспорты»** Гомумроссия мәгълүмат системасы кысаларында уңай иҗтимагый фикер булдыру.

Гадәттәгечә, проектта Татарстан Республикасыннан гаилә тормышын җайга салуда кыенлыклар кичерүче ятим балалар катнаша. Болар – күпбалалы гаиләләрдән балалар (3 һәм аннан күбрәк), өлкән яшьтәге балалар (9 – 14 яшь), инвалид балалар һәм сәламәтлеге чикле булган балалар.

Сигез ел эчендә барлыгы 491 ятим балага видеопаспорт ясалды (2011 елда – 32 видеопаспорт, 2012 елда – 31, 2013 елда – 43, 2014 елда – 56, 2015 елда – 94, 2016 елда – 109, 2017 елда – 65, 2018 елда – 61). Болар 43,2 млн. сумга төште. 2019 елның 1 февраленә 336 бала үз гаиләләрен тапты.





2018 елда шулай ук Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил башлап җибәргән һәм Татарстан Республикасы Президенты ярдәме һәм аның кушуы белән 2015 елда гамәлгә кергән **«Аек акыл» пилот проекты** 2018 елда да дәвам итте, ул социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлдерелә.

Ата-аналарның алкогольгә бәйлелеге бүген гаиләдәге күңелсезлекләрнең төп сәбәбе, нәтиҗәдә социаль ятимлек, балигъ булмаганнар арасында һәм аларга карата җинаятьчелек.

«Аек акыл» проекты ата-аналарга, беренче чиратта, аналарга алкоголизмнан дәвалануда нәтиҗәле ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелә. Проектның максаты – бала өчен аның гаиләсен саклап калу. Проектның ведомствоара характерда гамәлгә ашырылуы да принципиаль санала. Программа, бер яктан, алкогольгә бәйлелеге булган авыруга республиканың наркологик хезмәтләре тарафыннан инновацион ысул белән күрсәтелә торган наркологик медицина ярдәме күрсәтүне күздә тота, икенче яктан – бер үк вакытта дәваланучыны һәм аның гаиләсен башка (медицинага карамаган) проблемаларны җиңеп чыгу өчен актив социаль-реабилитация процессына җәлеп итү дә карала. Соңгы чараны куллану балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә йөкләнә. Гаилә бәхетсезлеген профилактикалау субъектлары органнары шулай бергәләп эшләгәндә генә проектны гамәлгә ашырудан уңай нәтиҗәләр көтәргә була.

*13 нче диаграмма*

***2015-2018 елларда «Аек акыл» проектын гамәлгә ашыру йомгаклары***




Проектны өч ел дәвамында гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 167 кеше дәвалану узды, гомуми сумма 20,3 млн. сум тәшкил итте. Дәвалануның тулы курсын 140 кеше уңышлы узды (проектта катнашучыларның 85%), нәтиҗәдә 344 бала, "ятим" статусын алмыйча, үз гаиләләрендә калды. Бүгенге көндә "Аек акыл" проектын тулысынча үткән пациентларда программа буенча дәвалану фонында уңай күренеш күзәтелә.

Социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлдерелгән социаль әһмиятле проектның уңышлы гамәлгә ашырылуын исәпкә алып, 2019 елда проектны гамәлгә ашыруны дәвам итү турында һәм проектның яңа этабына 70 ата-ананы кертү кертү өчен 8,4 млн сум акча бүлеп бирү турында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан карар кабул ителде.

Проектның социаль әһәмиятен, аны 2015-2017 елларда гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен исәпкә алып, «Аек акыл» проекты «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең "Ныклы гаилә" сәяси партиясе проектына кертелде, ул проект ятимлекне киметүгә, ятим балаларга, ата-ана каравын югалту куркынычы булган тәрбиягә бала алган гаиләләргә ярдәм итүгә юнәлдерелә.

2018 елда проектны гамәлгә ашыруга "Гаилә канаты астында" дигән иҗтимагый оешма да кушылды, аның вәкилләре гаилә кыйммәтләрен популярлаштыруга, гаиләгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар системасы аша проектта катнашучы гаиләләрне социаль адаптацияләү процессына актив кереп киттеләр.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ярдәме белән 2018 елда Татарстан Республикасында "Игелекле футбол" ("Добрый футбол") проекты гамәлгә ашырылды. Аны "Балалар хыялы" хәйрия фонды оештырды. Проект Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ярдәмендә гамәлгә ашырылды.

"Игелекле футбол" проекты футбол уенына язмышлары "авыр" булган балаларны йә имин булмаган гаиләләрдән балаларны җәлеп итүгә, Татарстан Республикасы районнарында гомуми файдаланулы футбол секцияләрен булдыруга, алга таба аларның эшчәнлегенә ярдәм итүгә, шулай ук бизнес-бергәлекләр акчаларына ел дәвамында турнирлар үткәрүгә юнәлдерелә.



Проектның төп идеясы – авыр тормыш хәлендә калган яшүсмерләр белән эшләү өчен, аларны бүгенге җәмгыятьтә социальләштерү, уңышлы спортчылар, бизнес-

җәмгыятьләр белән хезмәттәшлек итү аша социаль лифт технологиясен гамәлгә кертү, өстәмә инструмент булдыру, уңышлы шәхси яшүсмер – проектта катнашучы булдыруга юнәлдерелгән.

2018 елның сентябрендә проект кысаларында “Игелекле футбол” турниры уздырылды. Турнирда республиканың 15 муниципаль районыннан футбол командалы әгъзалары – 138 малай катнашты.







I урынны Биектау муниципаль районы командасы алды, II урынны – Чүпрәле муниципаль районы командасы, III урынны – Мөслим районы командасы. Иң яхшы уенчы булып Минһаҗев Шамил Реналь улы (Мөслим районы) танылды, иң яхшы туп атучы – Юманов Сергей Валерьевич (Чүпрәле районы).




2018 елда ***«Остазлар: бергә түгел, әмма янәшәдә!»*** *проекты икенче ел гамәлгә ашырылды,* ул Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, «УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе” АНО ярдәмендә гамәлгә ашырыла. Проект балаларның һәм яшүсмерләрнең деструктив тотышын профилактикалау проблемаларын хәл итүгә, хокук бозган балигъ булмаганнарны реабилитацияләүгә һәм социальләштерүгә юнәлдерелә.

Проект идеясы республикада балигъ булмаганнарны иҗтимагый тәрбияләүчеләр институтына ярдәм итүдән гыйбарәт. Ел дәвамында 200дән артык иҗтимагый тәрбияләүче балигъ булмаган хокук бозучылар белән эшләүдә остазлык программасы буенча тиешле уку уздылар.




Хокукый агарту бурычларын гамәлгә ашыруда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан даими һәм системалы рәвештә берничә проект эшли. Бу проектлар, башлыча, балалар аудиториясенә карый.

2015 елдан башлап балаларны һәм яшүсмерләрне хокукый агарту һәм аларда актив гражданлык позициясен булдыру рәвеше – ***«Балалар җәмәгатьчелек кабул итүе» (ДОП) республика укыту проекты*** уңышлы эшләп килә. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» (алга таба – БОС) төбәк иҗтимагый оешмасы һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә гамәлгә ашырыла торган **«Балалар җәмәгатьчелек кабул итүе»** республика проекты түбәндәгеләргә юнәлдерелә:

балаларда һәм яшүсмерләрдә актив гражданлык позициясен булдыруга;

Татарстан Республикасы балаларын хокукый агартуга;

яшь гражданнарны үз тормышларына кагылышлы мәсьәләләргә җәлеп итүгә;

балалар муниципаль мәнфәгатьләрендә иделар һәм яңа проектлар генерацияләүгә;

Татарстан Республикасында яшәүче балаларның һәм яшүсмерләрнең хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга һәм яклауга ярдәм итүгә.





Проектта тиешле конкурсны узган, БОСта эшләүче балигъ булмаганнар балалар катнаша. «ДОП» әгъзалары булып ел саен һәр муниципаль районнан һәм шәһәр округыннан вәкилләр сайлана. Ел дәвамында барысы 53 яшүсмер эшли. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карары буенча проектта катнашучы барлык балалар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар җәмәгать ярдәмчеләре булалар.

2018 елда балалар җәмәгать ярдәмчеләре тарафыннан балаларны хокукый агарту буенча 58 белем бирү проекты гамәлгә ашырылды, 100дән артык темати чаралар, яшьтәшләре белән очрашулар үткәрелде. Социаль челтәрләрдә «ДОП» аккаунтларында #ПовышаемПравовуюГрамотность (ХоккыйБелемнеАрттырабыз) кысаларында балалар турындагы законнарга бәйле актуаль яңалыклар чыгарылды.

2018 елның мартында балалар җәмәгать ярдәмчеләре Үзәк федераль округта (алга таба – ҮФО) (Мәскәү өлкәсе) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр каршында III Балалар иҗтимагый советы (СДО) слеты узды. Слет эшендә Россиянең 25 субъектыннан 250дән артык бала – делегат катнашты. III Балалар иҗтимагый советы (БИС) слетының йомгаклау чарасы буларак, осталар шәһәре «Мастерславль»та Балалар иҗтимагый советы форумы узды, анда катнашучылар спикерлар белән бергәләп үз идеялары һәм проектлары буенча фикер алаштылар. Аларның тәкъдимнәре «Десятилетие детства» (“Балалыкның унъеллыгы”) программасын үстерүнең “юл картасына” җибәрелде.



27 апрельдә «Балалар җәмәгатьчелек кабул итүе» (ДОП) проектында катнашучылар СДО активистлары белән бергә Европа Советының Яшьләр департаменты белән вебинарда катнаштылар. Чара «IT-парк» технопаркында узды. Балалар белән элемтәгә Департамент секретариаты вәкилләре һәм «ENTER!» хокукый проектын оештыручылар чыкты.

Советның Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Җәмәгать ярдәмчесе департаменты эшчәнлеге белән танышканнан соң Тимерхан Шәйхетдинов вебинарда катнашучыларга «Балалар җәмәгатьчелек кабул итүе» проектын тәкъдим итә.

2018 елның 10 ноябреннән 15 декабренә кадәр Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләре вәкилләре арасында Проектның яңа катнашучыларын читтән торып сайлап алу конкурсы узды.

Конкурс 6 – 10 сыйныф укучылары арасында ике этапта узды:

I этап – анкеталау, катнашу өчен анкета тутырырга һәм телефон аша аралашырга кирәк (Проектта катнашу мотивларын, мәнфәгатьләрнең өстенлекле өлкәләрен, граждан позициясен ачыклау); Проектның конкурс буенча читтән торып сайлап алу этабында җиңүчеләр профильле сменада катнашу өчен чакырылдылар;

II этап – турыдан-туры катнашу – Проектның профильле сменаларында катнашу һәм конкурс сынауларын үтәү; Проектта катнашкан җиңүчеләрне – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар җәмәгать ярдәмчеләрен билгеләү.

Конкурс буенча сайлап алуның I этабында республиканың барлык муниципаль берәмлекләреннән 328 баладан заявка керде. II этапта катнашучылар – актив тормыш позициясе белән 157 укучы булды.





2018 елның 26 – 28 декабрендә «Балалар оешмалары советы» төбәк иҗтимагый оешмасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән берлектә «Идел” яшьләр үзәге” ДАУ базасында профильле укулар сменасы уздырылды. Аның йомгаклары буенча 2019-2020 елларга “Балалар җәмәгатьчелек кабул итүе” проектында яңа катнашучыларны җыйдылар.




Балаларны хокукый агарту, аларда гражданлык һәм социаль активлык булдыру, аларның иҗади сәләтләрен үстерү бурычларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән тагын бер проект – ***«Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» республика мәгълүмати-социаль видеороликлар конкурсы.***

Әлеге конкурс 2014 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәмендә һәм әлеге органнар тарафыннан гамәлгә куелган иде. Конкурсны шулай ук Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» (алга таба – БОС) региональ иҗтимагый оешмасы оештыра.

Конкурсның максатлары түбәндәгеләр: балалар һәм өлкәннәр җәмәгатьчелеген, дәүләт һәм муниципаль органнарны, оешмаларны республикада балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү мәсьәләләренә җәлеп итү, балалар хокукларын популярлаштыру, балаларны һәм яшьләрне мәгълүмати-хокукый агарту, аларның социаль-хокукый активлыгын кызыксындыру, хокукый гыйлемне һәм хокукый культураны үстерү, шулай ук үсеп килүче буында иҗади сәләтләрне үстерү.



2018 елның сентябреннән ноябренә кадәр республикада «Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның чираттагы V республика конкурсы узды.

Аны уздыру турындагы матбугат конференциясендә, ул 20 сентябрьдә узды, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә Конкурсның төп нигезләмәләре, эшләргә куелган таләпләр һәм аларны бәяләү критерийлары тәкъдим ителде.

Конкурс гамәлдә булган вакытта анда 10 меңләп кеше катнашты, жюри бала хокуклары турында 2100ләп видеоролик карады. 2016 елдан авторлар үз роликларын «Интернет» челтәрендә куя алалар.

2018 елда роликларны 45 мең тамашачы карады. Аеруча активлык күрсәткән авторлар: Казан шәһәреннән – 93 видеоролик, Чаллыдан – 29 видеоролик, Буа районыннан – 25, Саба районыннан – 20 видеоролик, Түбән Кама районыннан – 19 ролик, Әлмәт, Аксубай һәм Нурлат районнарыннан 18әр ролик, Әлмәт районыннан – 17 ролик.



2018 елның 1 ноябреннән Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина рәислегендә бишенче конкурсның жюри утырышы узды, анда катнашучылар арасында җиңүчеләр билгеләнде. Иң күп баллар җыйган түбәндәге авторлар конкурста җиңүчеләр дип танылды:



Алексашин Матвей, Кама Тамагы муниципаль районының Рудницкий урта мәктәбе укучысы, «Я имею право на счастливое детство» (“Мин бәхетле балачакка хокуклы”) видеоклибы;



Газетдинов Шамил, Мөслим муниципаль районының Мөслим гомуми белем бирү мәктәбе укучысы видеоклип «Ул да нәкъ безнең кебек» видеоклибы;



Гайнетдинова Виктория, Балык Бистәсе муниципаль районының Масловка урта мәктәбе укучысы, «Аркадий Паровозов спешит на помощь» («Аркадий Паровозов ярдәмгә ашыга») агитация-художество тамашасы;



Минһаҗев Фаяз, Шәйдуллин Марат, А.П.Обыденнов ис. Казан автотранспорты техникумы студентлары, «Мы тоже хотим знать» (“Без дә белергә телибез”) социаль видеороли-гы;



Әлмәт шәһәренең 46 номерлы «Золушка» балалар бакчасы – Балаларны өйрәтү үзәгенең Чирикова Эльвира, Афанасьева Вера, Корчагина Альбина, Павлов Кирилл, Хәйруллин Эмиль составындагы иҗат төркеме, «Волшебные дети» (“Сихри балалар”) анимациясе;



Балалар иҗтимагый оешмасының Батюкова Ева, Антонов Максим, Исаев Артём, Мансурова Гүзәл, Хәбибуллина Зилә, Николаева София, Хахин Илья, Фәйзрахманов Әмир, Мельникова Дарьи, Галанин Даниил составындагы иҗат төркеме, «Мастер-шеф Казан балалары» кулинар шоу;



Капитонова Анастасия Владимировна, Нурлат муниципаль районының «Росинка» 4 нче балалар бакчасы хезмәткәре, «Бала хокуклар дөньясында» яңалыклар сюжеты;



Хаҗиев Таһир, Хаҗиев Искәндәр, Казан шәһәре Вахитов районының 3 нче гимназия укучысы, «Все познается в сравнении» (“Барысы да чагыштыруда күренә”) видеоролигы;



Добродеева Елена, Григорьева Кристина, Хайдарова Сабина составындагы «Фракция»иҗат берләшмәсе укучылары, «Мәктәп вакыйгалары» мультфильмы;



Хисамов Артур Илдар улы, Казан шәһәре Яңа Савин районының 146 нчы гомуми белем бирү мәктәбе укучысы, «Сайлау хокукы: ирек яисә җаваплылык» сәнгать видеоролигы;



Тамашачылар симпатиясе призына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлары берләшмәсенең махсус «Татарстан Республикасы аталар Советы» РОО рәисе призына Казан шәһәренең 83 нче «Улыбка» (”Елмаю”) балалар бакчасының иҗат коллективы эшләре һәм «Имеем право быть с родителями» (“Әти-әнием белән булырга хокуклы”) видеоклибы лаек булдылар.



V Конкурска тантаналы рәвештә йомгаклар ясау гадәттәгечә Бөтендөнья балалар көненә багышланган иде һәм ул 2018 елның 20 ноябрендә узды. Җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү тантанасы Казан шәһәренең «Московский» мәдәни үзәгендә узды, анда республиканың 350дән артык баласы катнашты. Конкурста җиңүчеләр дипломнар һәм 20 000 мең сум күләмендә акчалата премияләр белән бүләкләнделәр.






Җиңүчеләрдән тыш, җиңүчеләр арасына кермәгән 15 эш авторы да жюри әгъзалары инициативасы белән кызыксындыру призлары һәм рәхмәт хатлары белән бүләкләнделәр.

Икенче этапка узган барлык катнашучылар – болар 452 эш авторлары – конкурста катнашу турында таныклыклар алдылар.

2016 – 2018 елларда җиңүчеләрнең видеороликлары «Татарстан Республикасында электрон белем бирү» ГИСта (алга таба – Портал) урнаштырылды һәм алар белән «Ученику-Творческаядеятельность-Конкурсы» бүлегендә теркәлгән кулланучыларның барысы да таныша алалар https://edu.tatar.ru/scontest/index/31.

Балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү чараларын көчәйтү һәм хокукый агарту бурычларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, «МТС» гавами АҖенең Татарстан Республикасы филиалы белән берлектә 2018 елның 10 сентябреннән 15 ноябренә кадәр республиканың мәгариф оешмаларында Интернет челтәрендә иминлек буенча ел саен үткәрелә торган V Бердәм дәрес (алга таба – Бердәм дәрес) үткәрелде, ул кибер иминлек дәрәҗәсен күтәрүгә, ата-аналарның һәм педагогика җәмәгатьчелегенең «Интернет» челтәрендә балалар иминлеге проблемасына игътибарын тәэмин итүгә һәм балаларда цифрлы белемлелекне үстерүгә юнәлдерелә.




2018 елның яңалыгы – Бердәм дәресне яңа уку елыннан гомуми белем бирү оешмалары арасында гына түгел, ә ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен булган учреждениеләр, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары, өстәмә белем бирү учреждениеләре арасында да үткәрү булды.

Агымдагы елда Бердәм дәрес уздыруның төрле рәвешләре тәкъдим ителде: гадәттәге дәрес, сыйныф сәгате, эшлекле уен, мультфильмны һәм (яисә) видедәресне күрсәтү, чакырылган эксперт катнашында семинар яисә дәрес үткәрү, мәгълүмати иминлек буенча листовкалар һәм брошюралар өләшү һәм башкалар.

Бердәм дәрес чараларында Татарстан Республикасының 2 566 белем бирү оешмасы, 446 465 укучы, 154 088 ата-ана, 28 747 педагогика хезмәткәрләре катнашты.

«Татарстан Республикасында электрон белем» ДМСта (ГИСта) мәгариф оешмаларының битләрендә, бергәлекләрдә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең рәсми аккаунтларында, массакүләм мәгълүмат чараларында Бердәм дәрес чараларына багышланган пресс-релизлар (статьялар, искәрмәләр һәм башка материаллар) (барысы 1 096 материал) урнаштырылды.

Instagram социаль челтәрендә Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы тарафыннан #добраясеть хэштегы эшләнде, анда укучылар, аларның ата-аналары һәм педагогика хезмәткәрләре контролендә балаларның мәгълүмати иминлеге мәсьәләләренә кагылышлы фотографияләр һәм видеороликлар урнаштырыла.



Казан шәһәре Яңа Савин районының “179 нчы гимназия” МБМУ базасында Бердәм дәрес йомгакларына һәм балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча фикер алышуга багышланган видеоконференция режимында республика семинар-киңәшмәсе узды (07.12.2018).

Чарада Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты, Роскомнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе, «Таттелеком» ГАЖ (ПАО) белгечләре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының бүле (идарә) башлыклары һәм аларның урынбасарлары, методисты по информационно-коммуникационным технологиям, директора образовательных организаций, ата-аналар җәмәгатьчелеге вәкилләре катнашты.




2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан яңа ***«Балалар сагында»*** мәгълүмати проектына старт бирелде – бу радиода балаларның актуаль мәсьәләләре буенча фикер алышуга багышланган һәм ай саен оештырыла торган рубрика. Проект «Татарстан» ДРТК Радиосында (Бөтенроссия ДТРК филиалы) «Новый день» атналык иҗтимагый-публицистик каналында үткәрелә. Әлеге проект кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил редакциягә тыңлаучылардан килгән балалы гаиләләрдә килеп чыга торган проблемалар турындагы сорауларга җаваплар бирә, балаларны яклауның кискен аеруча кискен мәсьәләләрен яктырта, шул исәптән: торак мәсьәләләрен, опека һәм попечительлек мәсьәләләрен, мәктәптә укыту-тәрбия процессын, инклюзив белем бирүне, гаиләдә тәрбия мәсьәләләрен, ата-ана бурычларын билгеләү һәм үтәү, балигъ булмаганнарның һәм башка туганнарның гаилә бәйләнешләренә хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләрен.




Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау форматында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан даими нигездә үткәрелә торган чараларның тагын берсе – ***“Балалар соравы” хокукый ярдәм көннәре.*** Бу проект республикада ведомствоара нигезендә барлык кызыксынучы һәм балалар өлкәсен дә эшләүче министрлыклар, ведомстволар, хокук саклау һәм контроль-күзәтчелек органнары катнашында гамәлгә ашырыла.

Гражданнарга Хокукый ярдәм көннәре кысаларында балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча республиканың 20дән артык ведомство белгечләре консультацияләр бирделәр, аңлатулар алып бардылар, ярдәм күрсәттеләр, болар: Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы прокуратурасы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь

хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча медико-социаль экспертизаның баш бюросы» ФКУ, Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы Идарәсе, Кулланучылар хокукларын һәм иминлеген яклау буеенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсе (Татарстан), «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы» НКО, Россия Федерациясе Социаль иминләштерү фондының – Дәүләт учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлекчәсе, Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе һәм башкалар.

Хокукый ярдәм көне 2018 елның 1 июнендә Казан шәһәрендә Татарстан халыклары дуслыгы йортында үткәрелде һәм ул Балаларны яклауның халыкара көненә багышланган иде. Хокукый ярдәм көне кысаларында 71 мәсьәлә буенча 42 граждан мөрәҗәгать итте.





Түбән Кама (чаллы) икътисадый зонасыннан, башка шул яклардан алынган граждannар мөрәҗәгатьләренең шактый күп булуын истә тотып, 2018 елның 31 мартында чираттагы Хокукый ярдәм көнен үткәрү турында карар кабул ителде. Бу чараны Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе С.М.Захарова белән бергә үткәрде. Хокукый ярдәм көне кысаларында консультациягә Чаллыдан, Зәй һәм Түбән Кама муниципаль районнарыннан 72 мәсьәлә буенча 51 граждан мөрәҗәгать итте.





Моннан тыш, 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил А.Ю.Кузнецова тарафыннан күрсәтелгән берничә Бөтенроссия проектын хуплады.

***«Вектор «Детство-2018» (Вектор “Балачак-2018”)*** проекты республикада 2018 елның мартында башланды, ул гаиләгә, аналарга, аталарга һәм балаларга ярдәм итү, балигъ булмаган балалы гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрү мәсьәләләре буенча иң яхшы төбәк практикаларына

анализ ясауга, шулай ук Россия Федерациясендә социаль сәясәтне камилләштерү өчен дәүләт оешмаларын, НКО секторын, җирле үзидарәне, дәүләт хакимиятен берләштерүгә юнәлдерелгән.

Азнакай муниципаль районының "Яшьләр үзәге" МБУнең (Татарстан Республикасы, Азнакай шәһәре) «Папа может...» проекты «Вектор «Детство-2018» Бөтенросиия проектлары конкурсының гаиләгә һәм балаларга ярдәм итү буенча Топ-10 иң яхшы практик төбәкләренә керде, әлеге проект бала тәрбияләүдә аталарның тәрбияви ролен, аның актуальлеген һәм әһәмиятен арттыруга юнәлдерелгән.

2018 елда мәктәп балаларының җәйге каникул вакытында балигъ булмаганнар белән гадәттән тыш хәлләрне профилактикалауга юнәлдерелгән ***«Балалар иминлеге»*** Бөтенроссия акциясе 1 июльдән 31 августка кадәр узды. Акциянең бурычына балаларның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч яный торган факторларны ачыклау максатында балалар күпләп җыела торган урыннарда булу, балигъ булмаганнар катнашындагы чараларны оештыруда ярдәм итү, яшүсмерләрне куркыныч инфраструктура объектларына якын җибәрмәү чараларын күрү зарурлыгы турында кызыксынучы структураларга мәгълүмат бирү, шулай ук балалар булырга мөмкин булган территорияләрне, биналарны һәм корылмаларны тикшерү керә. Проект чараларын гамәлгә ашыруда иҗтимагый оешмаларның, республиканың «Совет отцов» ("Аталар киңәше") муниципаль иҗтимагый оешмалар ресурслары актив кулланылды.

***«Балалар иминлеге»*** Бөтенроссия акциясен үткәргәндә актив эшләгәне өчен Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Бөгелмә муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе Мортазина Гүзәл Миндар кызы Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Рәхмәт хаты белән бүләкләнделәр.

2018 елның октябрендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ярдәмендә Бөтенрроссия проектына ***«Юнармия. Наставничество»*** – ***("Юнармия. Остазлык")*** проекты кушылды. Проектның максаты – ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга шәхес формалаштыруда, үз-үзләрен күрсәтүдә, актив тормыш позициясен булдыруда ярдәм итү. «ЮНАРМИЯ. Наставничество» проекты түбәндәге сигез юнәлеш буенча гамәлгә ашырыла: патриотик һәм башлангыч хәрби әзерлек, лагерьлар һәм җыеннар, һөнәри ориентация, эзләү эше, мәдәният, иҗат, спорт, ихтыярыйчылык.

2018 елда проектка ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Нурлат балалар йорты» (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы остазлары – Татарстан Республикасы Идел аръягы зонасының юнармия отрядлары) һәм "Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Е.Г.Ласточкина ис. Казан интернат-мәктәбе" дәүләт бюджет учреждениесе (остазлары – Казан шәһәре Совет районының "175 нче гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең юнармия отряды) кушылдылар.

## 1.10. Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү эшчәнлеге

Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны яхшырак тәэмин итү дә Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, гражданлык җәмгыятьләре институты белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итү шартларында гына мөмкин булуын аңлаудан чыгып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең мөһим принципларыннан берсе мондый хезмәттәшлек итүнең тотрыклы практикасын булдырудан гыйбарәт.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы территориясендә хезмәттәшлек итүе үзара мөнәсәбәтләр һәм хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасында балаларны яклауның нәтиҗәле системасын булдыру максатларында ***федераль контроль-күзәтчелек органнары белән көйле хезмәттәшлек*** итү бурычы аеруча әһәмиятле. Уртак эш үзара мөнәсәбәтләр һәм хезмәттәшлек итү турында төзелгән килешүләр нигезендә алып барыла. 2012 елдан – мондый хезмәттәшлек Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең (Роспотребнадзор) Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән, 2016 елдан – Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек (Роскомнадзор) буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсе белән гамәлгә ашырыла.

***Федераль дәүләт хакимияте органнарының*** территориаль органнары компетенциясе мәсьәләләре буенча балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауның Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында булмаган нәтиҗәле механизмнарын эшләү өчен үзара мөнәсәбәтләрне шулай ук хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләр нигезендә оештыру практикага кертелгән. 2018 елда шундый килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе, Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Җәза үтәү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе, «Медик-социаль экспертизаның Татарстан Республикасы буенча баш бюросы» федераль казна учреждениесе, Россия Федерациясенең Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү буенча Татарстан Республикасы баш идарәсе, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе белән хезмәттәшлек итү дәвам итте.

2018 елда балаларга карата киберҗинаятьләрне кисәтү һәм булдырмау максатларында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының “К” Бүлеге белән оператив рәвештә мөһим мәгълүмат алмашу өчен беркетмә имзаланды.

Федераль структуралар белән хезмәттәшлек итүнең традицион форматлары түбәндәгеләр:

гражданнарны урта кабул итүләр;

уртак тикшерүләр;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы координацион киңәшләшү органнары (Координацион комитет, Балаларны гаиләдән алуны анализлау буенча эшче төркем) эшендә катнашу;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең кайбер федераль структураларның (Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе, «Медик-социаль экспертизаның Татарстан Республикасы буенча баш бюросы» федераль казна учреждениесе (ФКУ), Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе) иҗтимагый һәм координацион советларында әгъза булып катнашу;

аерым мәсьәләләр буенча эшче киңәшмәләрдә һәм консультацияләрдә катнашу практикасы.

2018 елда ***суд органнары*** белән хезмәттәшлек итү практикасы дәвам итте.

***Татарстан Республикасы Конституциясе суды*** белән хезмәттәшлек итү 2017 елда төзелгән килешү кысаларында дәвам итте. Әлеге килешү яклар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче балалы гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү юлы белән балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау гарантияләрен тәэмин итү, шулай балаларның бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуга ярдәм итү һәм дәүләт хакимияте органнарының ачыклыгын булдыру максатларында төзелгән иде.

Бала һәм хокукларын һәм мәнфәгатьләрен судта яклау өчен гомуми юрисдикция судлары белән хезмәттәшлек итү мөһим санала. Балаларны яклау буенча суд граждан процессларында катнашуга суд инициативасы белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне җәлеп итү практикасы бала мәнфәгатьләрен яклауны чагылдыра торган карарлар кабул иткәндә аларның кызыксынучанлык күрсәтүен раслый. Аерым алганда, 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Граждан эшләрен караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр турында» темасы буенча Татарстан Республикасы Югары Суды тарафыннан үткәрелгән район (шәһәр) судларының һәм җәмәгать судьяларының семинар-утырышларында катнашты. Системалы проблемалы мәсьәләләрне хәл итүгә үзара консультацияләр практикасы да ярдәм итә.

2018 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының ***депутатлар корпусы*** белән хезмәттәшлек итү киңәйде. Мондый эшнең нәтиҗәле форматлары түбәндәгеләр булды:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе белән хезмәттәшлек итү;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең закон чыгару собраниесе комитетлары (социаль сәясәт, мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр буенча) эшендә катнашуы;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Социаль сәясәт буенча Эксперт составында әгъзалыгы;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм депутатлар тарафыннан гражданнарны урыннарга чыгып кабул итүләр;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең республика районнарына эш сәфәрләрендә депутатларның катнашуы.

Татарстан Республикасы ***дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары*** белән хезмәттәшлек итү шулай ук конструктив нигезгә корылган. Контроль органнары белән үзара мөнәсәбәтләрне бары тик хакими күзәтчелек вәкаләтләрен гамәлгә ашыру шартларында гына алып бару тиешле нәтитҗәләр бирмәячәген аңлап, уртак максатларга ирешү өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан республика министрлыклары, ведомстволары, муниципаль органнар белән актив партнерлык хезмәттәшлеге форматы практикага кертелде. Мондый хезмәттәшлек итүнең иң нәтиҗәле һәм перспек-

тив вариантларыннан берсе – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең республика районнарына һәм шәһәрләренә эш визитлары.

Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләре яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлегенә ярдәм итү бурычларына таянып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты белгечләре 15 ***даими республика ведомствоара, координацион, киңәшләшү органнары, эшче төркемнәр, комиссияләр эшендә*** актив катнаштылар, шул исәптән:

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшендә;

Балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча ведомствара комиссиясе;

Татарстан Республикасы буенча Федераль инспектор каршындагы Гаилә, аналар һәм балалар мәсьәләләре. социаль ятимлекне профилактикалау, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрәм калган балаларга ярдәм итү буенча эшче төркем;

Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы инвалидлар эшләре советы;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы «Созвездие – Йолдызлык» республика фестивале хәрәкәтенә ярдәм итү советы;

Татарстан Республикасы территориясендә демография һәм гаилә сәясәте өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Торак комиссиясе;

Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия;

Алыштыручы гаиләләрдән балаларны кире кайтару очракларын анализлау буенча Татарстан Республикасы Экспертной комиссиясе;

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм булган балалар оешмаларының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм булган балалар оешмаларының эшчәнлеге, аларда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру турында” 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карары таләпләренә туры килүен бәяләү буенча эксперт төркеме;

Инвалидларны һәм сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле затларны һөнәри әзерләү һәм аларны эш белән тәэмин итү проблемалары буенча ведомствоара эшче төркем;

Татарстан Республикасында иртә ярдәм күрсәтү системасын үстерү буенча ведомствоара эшче төркем;

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыру буенча координацион төркем;

Алимент түләүләре буенча бурычларны түләтү буенча ведомствоара эшче төркем эшендә.

2018 елда бердәм “112” номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үзара мәгълүмати хезмәттәшлеге турында килешүгә ирешелде. Мондый эш форматы төбәк Вәкаләтле вәкиле хезмәтенең балалар һәм



балалы гаиләләр проблемаларына оператив йогынты ясавын тәэмин итәргә һәм тиешле ярдәм алырга мөмкинлек бирә.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына мәгълүмат тапшырыла торган вакыйгалар исемлеге түбәндәгеләр:

бәла-казалар, хәвефле табигать күренеше, афәтләр, табигый һәм кеше үлеменә, кешеләр сәламәтлегенә яисә әйләнә-тирә мохиткә зыян, зур маиди югалтуларга һәм кешеләрнең тормыш эшчәнлеге шартлары бозылуга китергән яки китерергә мөмкин булган башка бәлалар нәтиҗәсендә аерым территориядә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында;

балаларга карата мәрхәмәтсез булу һәм көч куллану турында;

гаиләдә балалар хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы имин булмаган проблемалар турында;

җинаятьчел гамәлләрдән зыян күрүче балигъ булмаганнар турында;

балигъ булмаганнарны җинаять кылуга һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү турында;

балигъ булмаганнарның үлеме турында (бәхетсезлек очраклары, суицидлар, җинаятьләр);

миграция өлкәсендә балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу турында;

вазыйфаи затлар тарафыннан балигъ булмаганнарның хокуклары бозылуга китергән гамәлләр (гамәл кылмаулар) турында;



мәгариф, сәламәтлекне саклау, баланың, шул исәптән ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, күпбалалы гаиләләрнең, инвалид балалары булган гаиләләрнең торак һәм башка мөлкәти хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү өлкәсендә бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча консультация ярдәмен күрсәтүне тәэмин итүче, җинаять үтәтү системасы учреждениеләреннән кайткан балигъ булмаганнарның мәгълүмати иминлеге, реабилитациясе һәм адаптациясе турында хәбәрләр (хокукый, консультацион, социаль һәм психологик ярдәм, һөнәри ориентация һәм эшкә урнашуда ярдәм өлешендә).

Балаларны яклау өлкәсендә ***гражданлык җәмгыяте институтлары*** белән хезмәттәшлек итү дә бик мөһим.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән хезмәттәшлеге иң мөһим граждани иҗтимагый партнер булып кала: Иҗтимагый палата әгъзалары Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координацион киңәшләшү органнарында (Координацион комитет һәм гаиләләрдән балаларны алу практикасына анализ буенча эшче төркемдә) актив катнашучылар.

Шул ук вакытта 2018 елда «Социаль реабилитация һәм адаптация» коммерциягә карамаган автоном оешма, «Татарстан Республикасының «Параллель» мәктәп психологлары ассоциациясе" коммерциягә карамаган партнерлык, «АК БАРС ЯҢАРЫШ» хәйрия фонды, Анжела Вавилова ис. фонд, «Дом Роналда Макдоналда» хәйрия фонды, «Татарстан Республикасының күпбалалы гаиләләре» төбәк иҗтимагый оешмасы, Ретта синдромы белән авыручыларга ярәм итү ассоциациясе, «Гаилә канаты астында» төбәк иҗтимагый оешмасы; «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» төбәк иҗтимагый оешмасы; «УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе", «Умиление» аналарны яклау үзәге" коммерциягә карамаган автоном оешма, «Татарстан Республикасы Адвокатлар па-

латасы» коммерциягә карамаган оешма, «Инвалид балалар ата-аналарының Бөтенроссия оешмасы» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының төбәк бүлекчәсе, Авыр тормыш хәленә эләккән кешеләргә ярдәм итү буенча «Игелекле эшләр» хәйрия фонды, «Балалар хыялы» хәйрия фонды, «Детские деревни – SOS» Россия комитеты” төбәкара хәйрия иҗтимагый оешмасы фонды, «Добрые сердца» ВДВ һәм ВСпН хәйрия фонды белән хезмәттәшлек итү үстерелде.

Дәүләт хакимияте органнары белән һәм җәмәгатьчелек белән аралашуда мөһим фактор буларак ***Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм аның Аппараты белгечләренең республикада һәм аннан читтә уздырыла торган гавами һәм иҗтимагый мәйданчыкларда*** (семинар-киңәшмәләрдә, форумнарда, “түгәрәк өстәлләрдә”, конференцияләрдә) балаларның һәм балалы гаиләләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча төрле форматларда катнашуларын әйтеп китәргә кирәк.

Балаларны яклауның төрле мәсьәләләре буенча 80ләп чара Татарстанның балалар хокукларын яклаучы позициясен презентацияләү урыны булды.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балалар мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкил белән, Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр белән ***төбәкара хезмәттәшлекне*** дәвам итте. Хезмәттәшлек түбәндәге форматларда барды: Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән бергә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, бала хокуклары мәсьәләләре буенча икеяклы консультацияләр, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Бөтенроссия һәм төбәкара форумнарда, конференцияләрдә, семинарларда, киңәшмәләрдә катнашуы.










Узган ел Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкил А.Ю.Кузнецова оештырган түбәндәге чараларда катнашты:

Россия Федерациясе субъектларында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең «Вектор Десятилетия детства: Счастливые дети – счастливая страна» темасына XV Бөтенроссия съездында (28 –29 май);

“Балалар иминлеге” («Безопасность детства») Бөтенроссия акциясенең I этапбын гамәлгә ашыру йомгаклары буенча Бөтенроссия утырышында (24 сентябрь);

Җәйге савыктыру кампаниясенә йомгаклар ясау мәсьәләләре буенча Бөтенроссия киңәшмәсендә (8 октябрь);

Россиядә балаларның имин булмаган тормышына ведомство оператив игътибарының нәтиҗәле механизмын булдыру мәсьәләсе буенча Бөтенроссия фәнни-методик семинар-киңәшмәсендә (31 октябрь);

«Янгыннар нәтиҗәсендә балалар имгәнүләрен һәм үлемен профилактикалау» темасына Бөтенроссия селектор киңәшмәсендә (19 ноябрь);

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил А.Ю.Кузнецованың Казанга визиты кысаларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аның белән бергә





«Балигъ булмаганнарда суицидка омтылыш барлыкка килү сәбәпләрен ачыклау буенча тикшеренүләр нәтиҗәләрен презентацияләү» темасына Россия Федерациясе тикшерү комитеты тарафыннан оештырылган Бөтенроссия селектор киңәшмәсендә катнаштылар (30 ноябрь);

Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Координацион советы йомгаклау утырышында (10 – 12 декабрь).

Төбәкара хезмәттәшлекнең актив формасы – Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән баланы яклауның аерым мәсьәләләре буенча нотыклар һәм башка материаллар белән ***мәгълүмат алмашудан гыйбарәт.*** 2018 елда Бала хокуклары буенча федераль вәкаләтле вәкил А.Ю.Кузнецова таләбе буенча 10 проблемалы һәм 14 мәгълүмати белешмәгә анализ ясалды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ярдәм алым системаларын эшләгәндә, шулай ук балаларга конкрет ярдәм иткәндә дә хезмәттәшлек итүе бик мөһим. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә еш кына башка төбәкләрдәге балаларның авыр тормыш хәлләрдә калуын хәл итү буенча вакыйгалар үзәгендә еш булырга туры килә. 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе субъектларыннан коллегалары үтенечләре буенча 30 проблемалы мәсьәләне анализлады, шул исәптән:

Түбән Новгород өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил М.В.Ушакова – тикшерү изоляторларында торучы балигъ булмаганнарны укыту мәсьәләләсе буенча;

Липецк өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Л.В.Куракова – опека һәм попечительлек органнары эше принципларын камилләштерү мәсьәләсе буенча;

Тула өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Н.А.Зыкова – төбәктә мәктәпкәчә гаилә төркемнәре институтын булдыру һәм үстерүнең уңай тәҗрибәсен трансляцияләү (тарату) турында;

Киров өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил В.В.Шабардин – менталь кимчелекләре булган, аутик спекторы дөрес булмаган затлар өчен уңай мохит булдыру һәм һәрвакыт алар янында булу, укыту процессын оештыру, мондый төркемдәге балаларны укыту һәм үстерү өчен шартлар булдыру буенча төбәк тәҗрибәсе турында мәгълүмат бирүдә ярдәм итү турында;

Кемерово өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Д.В.Кислицыннан – шикәр диабеты белән авыручы балаларны профилактикалау, дәвалау һәм аларга социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча;

Киров өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил В.В.Шабардин – белем бирү оешмаларында иминлекне тәэмин итү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыру буенча төбәкнең уңай тәҗрибәсе турында мәгълүмат бирү хакында;

Саратов өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н.Загородня – альтернатив системада уку буенча хокукларны гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча;

Оренбург өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил О.Г.Ковыльская – төбәктә реаль уеннар аша балигъ булмаганнарга шикле психологик тәэсир ясый торган квест-чаралар эшчәнлеген җайга сала торган төбәк законнары турында мәгълүмат бирү мәсьәләсе буенча;

Краснодар краенда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Ф.Ковалева – тиешле шартларда ял итүгә һәм савыгуга балалар хокукларының бозылу мәсьәләсе буенча;

Карачай-Черкес Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфаларын башкаручы А.С.Лайпанов – белем бирү учреждениеләрендә бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр институтын булдыру һәм үстерү буенча булган уңай тәҗрибә турында мәгълүмат бирүдә ярдәм итү буенча;

Оренбург Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил өлкәсендә О.Г.Ковыльская – «Дифицит лизосомальной кислой липазы: болезнь накопления эфиров холестерина» диагнозлы (начар холестирин эфирлары туплану авыруы) инвалид балалар саны турында, шулай ук балаларга «Себелипаза альфа» препараты ферменты аша терапия ярдәме күрсәтү буенча күрелә торган чаралар хакында мәгълүмат бирү буенча;

Әстерхан өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил А.А.Бондарева – инвалид балаларны техник реабилитацияләү чаралары белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча;

Чуаш Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Е.В.Сапаркина – яшьләр мохитендә экстремизмны профилактикалау мәсьәләсе буенча;

Киров өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил В.В.Шабардин – «Вектор Десятилетия детства: счастливые дети – счастливая страна» (“Балалыкның унъеллыгы векторы: бәхетле балалар – бәхетле ил”) темасына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең бөтенроссия съездына әзерләнү мәсьәләләре буенча;

Бурятия Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Е.Вежевич – ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның опекасы һәм попечительлеге мәсьәләсе буенча;

Төмән өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил А.Э.Степанов – авыл җирлекләрендә мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләрен саклап калу мәсьәләсе буенча;

Киров өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил В.В.Шабардин – ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балигъ булмаган балаларны торак белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча;

Томск өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Л.Е.Эфтимович – ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр мәсьәләсе турында;

Марий Эл Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Е.П.Бурдо – аутическ спектр кимчелекле балаларның һәм олыларның хәлен яхшырту буенча төбәк тәҗрибәсе турында мәгълүмат бирүгә ярдәм итү хакында;

Киров өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил В.В.Шабардин – балалар төркемнәрен автоoранспортта йөртүне оештыру тәртибе мәсьәләсе буенча;

Курск өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил А.О.Коллегаева – балаларны гаиләдә укытканда ата-аналарның чыгымнарын компенсацияләү мәсьәләсе буенча;

Удмуртия Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил О.Л.Авдеева – ВИЧ-йогышлы ата-аналарны һәм балаларны дәвалау проблемалары буенча Татарстан Республикасында булган нәтиҗәле эш тәҗрибәсе турында мәгълүмат бирүдә ярдәм итү хакында;

Липецк өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Л.В.Куракова – торак алу өчен ана капиталын куллану мәсьәләсе буенча;

Чиләбе өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил И.В.Буторина – «Южный Урал. Россия – без сирот!» (“Көньяк Урал – Россия – ятимләрсез!”) VI медиафестивален үткәрү мәсьәләсе буенча;

Калмык Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил О.В.Умгаева – балигъ булмаган балаларның яшәү шартларын тикшерүгә ярдәм итү турында;

Киров өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил В.В.Шабардин – балаларның җәйге ялын оештыру мәсьәләсе буенча;

Тула өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Н.А.Зыкова – күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм мәсьәләләре буенча;

Иваново өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.П.Океанская – инвалид балаларга һәм аларны җитәкләп йөрүче затларга шәһәр җәмәгать транспортында түләүсез йөрү хокукын бирү мәсьәләсе буенча;

Киров өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил В.В.Шабардин – ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның туклануын һәм трансортта йөрүен компенсацияләү мәсьәләсе буенча;

Тула өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Н.А.Зыкова – белем бирү оешмаларында туклана алуны һәм аның сыйфатын тәэмин итү мәсьәләсе буенча.

Шулай ук Россия Федерациясенең аерым субъектларында проблемалы мәсьәләләргә анализ ясау, балаларның хокукларын һәрьяклап тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре буенча тәҗрибәләр алмашу максатында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәге мәсьәләләр буенча коллегалары адресына мөрәҗәгать итте:

Камчатка краенда, Төмән, Ульяновск өлкәләрендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына – субъектларда мәктәп балаларын ашатуны оештыру, белем бирү учреждениеләрендә ашатуны оештыру өлкәсендә иң яхшы практика белән алмашу мәсьәләсе буенча;

Россия Федерациясе субъектларының бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр адресына – «Интернет» челтәрендә түбәндәгеләр турында балигъ булмаганнарның мәгълүмат иминлеге мәсьәләләре буенча: Россия Федерациясе субъектларында халыкның медиабелемен булдыру тәҗрибәсеннән мәгълүмат бирү турында, мәгълүмати янаулар турында мәгълүмат булган махсус белем бирү һәм агарту программаларын эшләү турында, «Интернет» челтәреннән балаларның имин файдалану кагыйдәләре турында, балигъ булмаганнарны аларның сәламәтлегенә, әхлакый һәм рухи үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан файдалануны яклау чаралары турында;

Россия Федерациясенең тиешле субъектларында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләргә түбәндәге үтенечләр белән: Казан шәһәре үзәкләренең берсендә балалар булуның куркынычы турында ата-аналарга аңлату эшләрен оештыруда ярдәм итү турында һәм кыен балаларны тәрбияләүнең проблемалы мәсьәләләрен хәл итүдә ата-аналарга ярдәм итү турында;

Идел буе федераль округында төбәк бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр адесына – ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан чыккан затларны торак белән тәэмин итү буенча мәгълүмат бирүдә ярдәм итү турында;

балигъ булмаганнар арасында суицид хәлләрнең торышы турында.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил алга таба да Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил А.Ю.Кузнецова һәм Россия Федерациясенең башка субъектларыннан коллегалары белән хезмәттәшлекне дәвам итүне планлаштыра.

Бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсендә хокукый белем бирүнең һәм дөньяга карашның дөрес формалашуын тәэмин итүнең иң көчле чыганакларының берсе – ***массакүләм мәгълүмат чаралары (алга таба – ММЧ)***. Хисап чорында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән массакүләм мәгълүмат чараларының үзара эшчәнлеге тагын да активлашты.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән 67 очрашу уздырды, болар – радиоэфирлар, тематик брифинглар, матбугат конференцияләре, комментарийлар бирү, төрле басма һәм интернет баасмаларда катнашу.





Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чараларына балалар мәнфәгатьләрендә нәтиҗәле хезмәттәшлек өчен рәхмәт белдерә һәм бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча хокукый карашны җәмәгатьчелеккә җиткерүдә перспектив мөмкинлекләрнең берсе буларак массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлекне дәвам итүне күздә тота.

## 1.11. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре институты эшчәнлеге

«Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы нигезендә 2016 елдан системалы нигездә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең иҗтимагый башлангычларда эшләүче ярдәмчеләре институты (алга таба – Җәмәгать ярдәмчеләре) эшли башлады.



2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карары белән республиканың 15 муниципаль районында 17 җәмәгать ярдәмчесе билгеләнде 2018 елда – тагын 22 җәмәгать ярдәмчесе. Шулай итеп, 2018 елда 37 муниципаль районда (шәһәр округларында) Җәмәгать ярдәмчеләре эшләде, болар: Алексеевск, Әгерҗе, Әлки, Азнакай, Әлмәт, Арча, Алексеевск, Балтач, Баулы, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Кайбыч, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Нурлат, Питрәч, Сарман, Спас, Тәтеш, Теләче, Тукай, Чистай, Чирмешән, Ютазы муниципаль районнары, Казан һәм Чаллы шәһәрләре.

Җәмәгать ярдәмчеләре эшендә өстенлек конкрет кешегә ярдәм итүгә бирелә.

Җәмәгать ярдәмчеләренең эшчәнлеген оештыру-методик тәэмин итү Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары белән берлектә гамәлгә ашырыла.

Эшчәнлекне алып бару методикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Аппараты тарафыннан ел дәвамында системалы нигездә гамәлгә ашырылды. Җәмәгать ярдәмчеләре балаларны һәм балалы гаиләләрне яклау мәсьәләләре буенча Россия

Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларындагы яңалыклардан һәм үзгәрешләрдән һәрвакыт хәбәрдар булып тордылар, гражданнар мөрәҗәгатьләрен караганда проблемалы аерым мәсьәләлә буенча хокукый ярдәм күрсәтелде.



Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законды мәнфәгатьләрен үтәү өлкәсендә компетенцияләрне арттыру максатында, 2018 елның 26 октябрендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Н.А. Галләмов ис. республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» девиант балалар өчен ябык типтагы махсус дәүләт казна укыту-тәрбияләү учреждениесе базасында Җәмәгать ярдәмчеләре белән уку семинар-киңәшмәсен үткәрде.

Семинарда түбәндәге мәсьәләләр каралды:

«Татарстан Республикасында балалар хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында» (Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Удачина Гүзәл Любис кызы чыгыш ясады);







«Балигъ булмаганнарга һәм яшьләргә карата законнар үтәлеше мәсьәләләре» (Ибраһимов Җәүдәт Хәмзин улы, Татарстан Республикасы Прокуратурасының булмаганнарга һәм яшьләргә карата законнар үтәлешенә күзәтчелек итү бүлеге башлыгы);

«Социаль авыр хәлдәге гаиләләргә ярдәм итү буенча Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең эшчәнлеге турында» (Гарифуллина Илсөяр Хәләлетдин кызы, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларны хокукларын яклау буенча республика комиссиясе җаваплы секретаре);

«Н.А. Галләмов ис. республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе эшчәнлеге турында» (Бахусова Ирина Илдар кызы, «Н.А. Галләмов ис. республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» девиант балалар өчен ябык типтагы махсус дәүләт казна укыту-тәрбияләү учреждениесе директоры урынбасары);

«Татарстан Республикасында балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары» (Наталья Владимировна Бутаева, Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары);

«Законнар таләпләренең үтәлешен тәэмин итү һәм белем бирү оешмалары тарафыннан укучыларның һәм тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарынннан финанс һәм матди чаралар алуны булдырмау» (Гаязова Лилия Рәхимулла кызы, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгының Күзәтчелек һәм контроль департаментының хокукый җайга салу бүлеге әйдәүче консультанты);

«Хокукый белемне арттыру буенча альтернатив эш рәвешләре» (Башлай Эльвира Хәмзә кызы, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгының Төбәк психологик хезмәтне үстерү буенча штаттан тыш хезмәткәре).



2018 елда балаларның хокукларын яклаучылар тарафыннан республика районнарында һәм шәһәрләрендә шактый күп эш башкарылды.

Вәкаләтле вәкил кушуы буенча Җәмәгать ярдәмчеләре үз районнарында җәйге савыктыру оешмаларын тикшерүдә катнаштылар. 2018 елның җәйге чорында Җәмәгать ярдәмчеләре тарафыннан 12 муниципаль районда 49 лагерь тикшерелде, шул исәптән – мәктәпләр каршындагы көндез эшли торган 35 лагерь, 12 – балалар өчен шәһәрдән читтәге савыктыру лагерьлары, 1 – палата лагере.



Мәктәпләрдә химия һәм физика кабинетларының махсус лаборатор җайланмалары, реактивалар белән тәэмин ителеше турында республика күләмендә тулырак һәм объектив мәгълүмати-аналитик белешмә әзерләү максатында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил кушуы буенча Җәмәгать ярдәмчеләре тарафыннан мәгариф идарәсенең муниципаль органнары белән (гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре) берлектә тиешле анализ ясалды һәм гомумиләштерү өчен тапшырылды.

Шул ук вакытта, балаларга өстәмә белем бирү системасын үстерү мәсьәләләренең актуальлеген исәпкә алып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Җәмәгать ярдәмчеләре балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре белән бергә әлеге балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре биналарының торышы һәм аларга капиталь ремонт ясау кирәклеге турындагы мәсьәлә эшләнде.



2018 елда Җәмәгать ярдәмчеләре тарафыннан 30 муниципаль районда, Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә 193 мәртәбә гражданнарны кабул итү оештырылды, гражданнардан 309 мөрәҗәгать кабул ителде.

Җәмәгать ярдәмчеләре балигъ булмаганнарның, педагогларның хокукый культурасын күтәрүгә юнәлдерелгән чараларга актив кушылдылар. Җәмәгать ярдәмчеләре тарафыннан 100 чара үткәрелде, аларда гражданнарны хокукый агартуга зур игътибар бирелде.

Мәсәлән, 2018 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Чүпрәле районындагы Җәмәгать ярдәмчесе И.И.Борисова тарафыннан гомуми белем бирү мәктәпләрендә «Мои права и обязанности – что я должен знать» (“Минем хокукларым һәм бурычларым”) һәм «Виртуальный мир глазами детей» (Виртуаль дөнья – балалар күзлегеннән”) темасына чаралар уздырылды. Балаларга аларның хокукларын һәм социаль челтәрләрдә балалар иминлеген аңлату буенча дәресләр уздырылды.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Җәмәгать ярдәмчесе И.В.Фесенко тарафыннан 2018 елның җәендә районның балалар лагерьларында – «Костер» республика балалар савыктыру-белем бирү үзәге” дәүләт бюджет учреждениесендә һәм «Сәләт» үзәгендә слет кысала-





рында «Все зависит от нас самих» (“Барысы да үзебездән тора”) тренинглар үткәрелде. Ата-аналар белән эшләү дәрәҗәсен күтәрү һәм гаилә кыйммәтләрен пропагандалау максатында ул “Гаилә учагы” клубы эшенә дә кушылды. Клуб җыеннарына юарлыкка килә торган проблемаларны үзара хәл итүче төрле социаль категорияләрдән хатын-кызлар чакырыла, алар хокукый консультация алалар.



Кайбыч муниципаль районында Җәмәгать ярдәмчесе О.А.Сарханова тарафыннан урта звено укучылары өчен класстан тыш чаара үткәрелде. Чара «Знатоки права» (“Хокук белгечләре”) уены рәвешендә узды. Уен укучыларда хокукый культураны булдыруга юнәлдерелгән.



Алексеевск муниципаль районында Җәмәгать ярдәмчесе Л.Г.Осянина тарафыннан Балаларны яклауның халыкара көненә багышланган «Пробег в колясках» йөкле хатыннар һәм сабыйлар фестивале кысаларында Хокукый белемнәр мәктәбе эше оештырылды.

Теләче муниципаль районында Җәмәгать ярдәмчесе С.Н.Хаҗипова «Подросток-2018» (“Яшүсмер-2018”) ведомствоара профилактик операциягә кушылды һәм аның кысаларында социаль куркыныч хәлдәге 7 гаиләгә, тәрбиягә балалар алган 10 гаиләгә (аларда 24 балигъ булмаган бала яши), 28 бала опекага алынган 19 гаиләгә чыктылар.



Яңа Чишмә муниципаль районында Җәмәгать ярдәмчесе С.В.Мартышова Яңа Чишмә районының Балар иҗаты үзәге методистлары белән берлектә «Звёздный десант» (“Йолдызлы десант”) палата лагеренда булды, анда яшүсмерләр белән хокукый квестлар үткәрде.



Бөгелмә муниципаль районында Җәмәгать ярдәмчесе Г.М.Муртазина районның Хатын-кызлар советы тарафыннан оештырылган «Крепкая семья» (“Ныклы гаилә”) проекты кысаларында «Фамильная пицца» (“Гаилә пиццасы”) проектын гамәлгә ашыруга кушылды. Бу проектта үзенчәлекле балалар яши торган гаиләләр катнаша һәм аларга комплекслы ярдәм күрсәтелә.



2018 елның 29 ноябрендә Бөгелмә шәһәренең урта һөнәри уку йортларында укучы барлык студентлар «В.Г.Тимирясов ис. Казан инновацион университеты (ИЭУП)» югары белем бирү ЧОУның Бөгелмә филиалында «Яшьләрнең тормыш сыйфаты һәм социаль иминлеге» темасына шәһәр студентлар форумына җыелдылар. Форумны оештыруда шулай ук Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Бөгелмә районындагы Җәмәгать ярдәмчесе Г.М.Муртазина да катнашты. Форумның форматы күрсәтелгән мәсьәләләр буенча яшьләрнең хәбәрдарлыгын арттырырга, актуаль темалар буенча фикер алышырга,



мәгълүмати-аналитик белемнәр белән алмашырга, профилактик чараларны гамәлгә ашыру өлешендә тыгызрак хезмәттәшлек итү мөмкинлекләрен аңларга һәм перспективаларын билгеләргә ярдәм итә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Җәмәгать ярдәмчесе Э.Х.Башлай тарафыннан ата-аналарны хокукый агарту буенча берничә чара үткәрелде: «Кама Тамагы муниципаль районының ата-аналарга җәмәгатьчелеге катнашында Җаваплы ата-ана мәктәбе» темасына семинар-практикум; Азнакайда «Аттестация сынаулары чорында балаларның эмоциональ халәтне җиңүләрендә ата-аналарга ярдәм» темасына гавами лекция, Казанда «Гаиләдәге мәрхәмәтсезлекне һәм көч куллануны профилактикалау кысаларында ата-аналар белән эшләүнең альтернатив рәвешләре» темасына мастер-класслар.



Баулы районында Җәмәгать ярдәмчесе Л.Ф.Фәхриева Халыкара кеше хокуклары көненә багышланган дәрес әзерләү һәм уздыру эшенә кушылды. Дәрес дебатлар рәвешендә узды. Сөйләшүләр аша проблемаларны хәл итү юлларын таптылар. Балалар үз фикерләрен якларга өйрәнделәр.

Тәтеш муниципаль районында Җәмәгать ярдәмчесе Е.С.Куранова трафыннан «Чайка» балалар савыктыру лагеренда эшлекле интерактив уен оештырылды, ул балаларның хокукый тематика белән кызыксынуын үстерүгә юнәлдерелгән, уен барышында балаларның тормыш эшчәнлегенә, хокукларына һәм бурычларына бәйле законнар анализланды.





Чистай муниципаль районында Җәмәгать ярдәмчесе С.М.Хәсәнова тарафыннан ПДНда профилактик исәптә торучы балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре өчен методик уку семинары үткәрелде, анда сыйныф житәкчеләре, урта белем бирү мәктәпләренең һәм ССУларның тәрбия эше буенча директор урынбасарлары катнашты. Чара Чистай муниципаль районының Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе һәм Мәгариф идарәсе ярәмендә узды.

Чаллы шәһәрендә Җәмәгать ярдәмчесе С.Б.Соколова тарафыннан «Мәгарифтә инновацияләр: гамәлгә ашыру тәҗрибәсе» темасы буенча төбәкара фәнни-гамәли конференциядә укучылар тәртибенең асоциаль профилактик эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре буенча эш тәҗрибәсе күрсәтелде (Казан).





Әлмәт муниципаль районында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Җәмәгать ярдәмчеләре «Игелекле Әлмәт» хәйрия акциясендә катнаштылар. Күпбалалы Ефимовлар гаиләсен Яңа ел белән котладылар.

Ноябрьдә Халыкара балалар көне кысаларында Чүпрәле муниципаль районында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Җәмәгать ярдәмчесе И.И.Борисова балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район комиссиясенең җаваплы секретаре А.В.Афанасьева, опека

һәм попечительлек бүлеге мөдире Л.М.Сәлимҗанова, Җәмәгать ярдәмчесе Л.А.Җәләлов белән берлектә гражданнарны киңәйтелгән рәвештә кабул итүне оештырды, аның барышында авыр тормыш хәлендә калган гаиләгә матди ярдәм күрсәтү мәсьәләсен хәл итүдә һәм ата-анасы вакытлыча эшсез калган гаиләдәге балаларны мәктәптә бушлай ашату мәсьәләсен хәл итүдә булыштылар.



«Югары Ослан» муниципаль районында Вәкаләтле вәкилнең Җәмәгать ярдәмчесе Г.Т.Абдуллина тарафыннан «Кышкы каникуллар» операциясе кысаларында «Югары Ослан гимназиясе» МБМУендә ОГИБДД һәм Татарстан Республикасы Юл хәрәкәте иминлеге фонды вәкилләре чакырылды, алар балалар өчен яңа ел бәйрәмнәре кысаларында укучылар һәм аларның ата-аналары белән профилактик әңгәмәләр үткәрделәр. Тәртип сагындагылар ут яктысында чагыла торган билгеләр, юл кагыйдәләрен искә төшерделәр. Балаларны да, ата-аналарны да саграк булырга өндәделәр.



2018 елда барлык республиканың муниципаль районнарында һәм шәһәрләрендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 37 олы җәмәгать ярдәмчесе белән бергә 53 балалар җәмәгать ярдәмчесе эшләде.

***«Балалар җәмәгать кабул итүе»*** проектын гамәлгә ашыру турындагы мәгълүмат әлеге нотыкның 1.9 «Проект эшчәнлеге» бүлегендә бирелде.

Җәмәгать ярдәмчеләре институтын үстерү Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2019 елгы эшчәнлегендә дә үзенең кирәклеген һәм реаль файдалы булуын раслаган перспектив бурычларның берсе буларак кала.

# 2018 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛАЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕ ҮТӘЛЕШЕНЕҢ ГОМУМИ МОНИТОРИНГЫ

2

БҮЛЕК

## 2.1. 2018 елда Татарстан Республикасында төп демографик тенденцияләр


Татарстан Республикасында балаларның һәм балалы гаиләләрнең хәлен гомуми бәяләү өчен төп демографик күрсәткечләрне анализлау мөһим.

Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы белешмәләре буенча 2018 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында халык саны 3 894,3 мең кеше тәшкил итте.

2011 елдан алып республикада ***халыкның табигый артуы*** күзәтелә. 2018 ел йомгаклары буенча бу артым 1 596 кеше яисә 1000 кешегә (+) 0,4 кеше тәшкил итте. Шуны әйтергә кирәк, Федераль дәүләт статистика хезмәтенең оператив белешмәләреннән күренгәнчә, Татарстан Республикасы 2018 елның 11 ае йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Идел буе федераль округында халыкның табигый артуы күзәтелә торган бердәнбер субъект булып тора.

*Диаграмма*


***2009 – 2018 елларда Татарстан Республикасы халкының табигый артуы (кимүе) (кеше)***




Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2018 елда 46 320 бала туган. Республикада бала туу күрсәткечләре 2017 ел белән чагыштырганда кимегән. Һичшиксез, моңа хатын-кызларның саны һәм аларның репродуктив яше зур йогынты ясый. Соңгы 10 елда аларның саны кими, бу узган гасырның 90 нчы елларында балалар тууның кинәт кимеп китүе белән аңлатыла. Бу чорда туган балалар хәзер үзләре ата-ана булып җитешә, шунлыктан киләсе елларда балалар тууның кимүе көтелә.

*Диаграмма*

***2013 – 2018 елларда Татарстан Республикасында балалар туу динамикасы (кеше)***





Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе белешмәләренә караганда, 2018 ел йомгаклары буенча республикада 18 357 бала (39,2%) гаиләдә беренче бала булып туган, 19 458 (41,6%) – икенче бала, 6 990 (14,9%) – өченче, 1 988 (4,3%) –

дүртенче һәм аннан күбрәк. Балалар туу структурасында соңгы биш елда беренче балалар туунын кимүенә игътибар итәргә кирәк (2014 елда 25 539 беренче бала булып туган, 2015 елда – 24 832, 2016 елда – 22 511, 2017 елда – 19 543, 2018 елда – 18 357 бала). Икенче балаларның тууы да узган елга караганда кимүе күзәтелә. Шул ук вакытта 2018 елда өченче балалар узган елга караганда 3,3%ка күбрәк туган, дүртенче балалар – 4,3%ка күбрәк.

*14 нче диаграмма*


***2018 елда беренче һәм аннан соңгы балаларның туу өлеше***




Соңгы елларда абортлар саны киму динамикасы да игътибарга лаек. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы күрсәткечләре буенча, 2018 елда 22 атналык срокта 14 478 аборт ясалган. Бу 2009 елдан соңгы чор эчендә иң түбән күрсәткеч. Шул ук вакытта хатын-кызларның үз теләге белән абортка барулары (12 атнага кадәр сроекта) борчуга сала, мондый абортлар саны 7 261гә житә (50,2%). Абортларның 49,8%ы медицина күрсәткечләре буенча ясалган (2017 елда – 48%).

*15 нче диаграмма*


***2009 елдан 2018 елга кадәр Татарстан Республикасында туган балалар һәм абортлар саны (мең кеше)***




Республикада ***балалар саны*** 2018 ел башына 826 872 кеше тәшкил итә, ягъни барлык халыкның 21,2%ы. 2017 ел белән чагыштырганда 12 669 балага күбрәк. 2010 елдан статистика күрсәткечләрен анализлаудан күренгәнчә, республикада балалар саны елдан-ел арта бара.

*16 нчы диаграмма*

***2013 -2018 елларда тулаем һәм яшьләре буенча балалар динамикасы***





Яшь балалар саны (0 яшьтән 13 яшькә кадәрге) 674 917 кеше, яшүсмерләр (14 яшьтән 17 яшькә кадәрге) – 151 955 кеше.

Балалар санын анализлаудан күренгәнчә, 2018 елда мәктәп балалары (7 – 17 яшьлекләр) саны арткан. Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы белешмәләре буенча, бу яшьтәге контингент 436 548 кешедән 436 548 кешегә җиткән, ягъни 11 515 кеше арткан.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар (0 – 6 яшь) санының артуы күзәтелә. 2019 ел башына республикада 378 809 кеше исәпләнә. Шул ук вакытта мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны кимегән. 2014 елда 2013 ел белән чагыштырганда 18 745 балага артык, 2015 елда 2014 ел белән чагыштырганда – 15 370 кеше, 2016 елда 2015 ел белән чагыштырганда – 11 663 кеше, 2017 елда 2016 ел белән чагыштырганда – 9 287 кеше, 2018 елда 2017 ел белән чагыштырганда – 1 154 кеше.

*17 нче диаграмма*


***2012 – 2018 елларда мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар саны динамикасы***




Республикада 2014 елдан алып халыкның гомуми үлем санынннан балалар үлеменең кимүе күзәтелә. 2018 елда 365 бала үлгән, бу 2017 елдагыга караганда 54 балага әзрәк. Бу соңгы сигез елда иң түбән күрсәткеч.

*18 нче диаграмма*

***2013 – 2018 елларда Татарстан Республикасында балалар үлеме динамикасы (кеше)***




***Гаилә кору һәм аерылышулар*** балалар мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагыла торган һәм күп очракта шуңа бәйле процесслар булып тора.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ЗАГС Идарәсе белешмәләре буенча, 2018 елда 24 865 никах теркәлгән, бу, 2017 ел белән чагыштырганда, 2 118 (7,8%) күбрәк. Аерылышкан парлар буенча 13 456 акт теркәлгән.

*19 нчы диаграмма*

***2013 – 2018 елларда Татарстан Республикасында теркәлгән никахлар һәм аерылышулар динамикасы***




Бу күрсәткеч узган елга караганда 130га кимегән. Әмма теркәлгән никахлар һәм аерылышулар чагыштырмасы буенча 2018 елда теркәлгән 1000 никахка 541 аерылышу туры килә (2013 елда – 467, 2014 елда – 464, 2015 елда – 440, 2016 елда – 522, 2017 елда – 503). Балигъ булмаган балалар булган гаиләләрнең аерылышу мәсьәләсенә игътибар итәргә кирәк. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе белешмәләре буенча, узган ел аерылышуларның 80,4%ы (10 815) суд карарлары белән башкарылган. Бу карарларның күпчелеге (7 778) аерылышучы гаиләдә балигъ булмаган балаларның булуына бәйле чыгарылган. 2018 елда 10 596 бала ата-аналары аерылышу аркасында кризис хәлдә калганнар.

## 2.2. 2018 елда Татарстан Республикасында бала хокукларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән төп гамәлләр һәм чаралар

2018 елда Татарстан Республикасы күп социаль-икътисадый күрсәткечләр буенча Россия Федерациясендә алдынгы урыннарны били. 2015 елдан башлап Татарстанның 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеш стратегиясе гамәлгә ашырыла, анда республиканың озак сроклы үсешенең төп юнәлешләре билгеләнгән, гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту бурычы уңышлы хәл ителә. Ныклы икътисадый нигез республикага балаларның һәм балалы гаиләләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тагын да яхшырак тәэмин итү бурычларын уңышлы хәл итәргә ярдәм итә.

2012 елдан башлап Татарстанда социаль учреждениеләрнең, шул исәптән балалар өчен, матди-техник базасын ныгытуга, яңартуга, инфраструктура объектларын, шәһәр мохитен үстерүгә юнәлдерелгән берничә республика программасы гамәлгә ашырыла.

Республикада сәламәтлек саклау учреждениеләрен модернизацияләүнең күләмле программасы гамәлгә ашырыла.

Мәсәлән, 2018 елда 226 сәламәтлек саклау учреждениесен төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга 5,6 млрд сум акча җибәрелде. 150,0 мең кв.метрдан артык ремонтланды, шул исәптән төзелде:

48 – фельдшерлык-акушерлык пункты,

11 – модуль технологиясе буенча табиб амбулаториясе.

«Перинаталь үзәк белән Түбән Кама балалар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (ГАУЗ) сабыйлар корпусында эшләр тәгәлләнде; «Перинаталь үзәк белән Әлмәт балалар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе объектларында төзелеш-монтаж эшләре дәвам итә.





7 сәламәтлек саклау объектына капиталь ремонт ясалды.

2017 елда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча Татарстан Республикасының 207 амбулатор-поликлина учреждениесен модернизацияләү буенча икееллык программа кабул ителгән иде, аны финанслауга 7,837 млрд. сум акча бирелде, шул исәптән 800 млн. сум медицина җайланмаларына каралган иде. 2018 елда 132 объект ремонтланды, шул исәптән 9 – балалар поликлиникасы (22 – элегрәк ремонтланган амбулатор-поликлиника учреждениеләре өчен өстәмә җайланмалар алынды).

Республикада икенче ел педагогларны беренчел ярдәм нигезләренә өйрәтү буенча «Иминлек» проекты гамәлгә ашырыла. 2018 елда моңа 2 815 укытучы өйрәтелде.

Бүген динамикалы үсә торган ***мәгариф системасы*** республика җитәкчелеге тарафыннан Татарстанның социаль һәм хуҗалык өлкәләрен модернизацияләү өчен шартлар булдыручы төп өстенлекләре буларак карала. Төп бурыч – сыйфатлы белем алуны тәэмин итү. Бу юнәлештә күп эшләр башкарыла. Шуның аркасында Татарстан күп күрсәткечләр буенча Россия Федерациясендә әйдәүче төбәкләрнең берсе булып санала.




***Мәгариф өлкәсендә*** мәгариф системасының инфраструктурасын үстерү программалары да гамәлгә ашырыла.

Татарстанда 2012 – 2018 елларда республикада балалар бакчаларында 48 меңгә якын урын булдырылды. 2018 елда





бу программаны гамәлгә ашыру кысаларында 805 урынлык 8 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төзелде, шул исәптән:

Югары Ослан муниципаль районында Яр буе Морквашы авылында 50 урынлык балалар бакчасы;

Кукмара муниципаль районында Ядегәр 50 урынлык балалар бакчасы;

Түбән Кама шәһәрендә 47 нче микрорайонда 260 урынлык балалар бакчасы;

Актаныш муниципаль районында Пучы авылында 120 урынлык балалар бакчасы;

Арча шәһәрендә урынлык балалар бакчасы;

Тукай муниципаль районында Иске Ерыклы авылында 140 урынлык балалар бакчасы;

Әтнә муниципаль районында Түбән Шашы авылында 25 урынлык балалар бакчасы;

Әлки муниципаль районында Татар Борнае авылында 20 урынлык балалар бакчасы.

Шул ук вакытта, яңа балалар бакчалары төзү белән бергә, мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен капиталь ремонтлау (реконструкцияләү) программасы да гамәлгә ашырыла. 2012 – 2018 елларда 267 балалар бакчасы ремонтланды.

Республиканың гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар төзү программасын гамәлгә ашыру да дәвам итә.





Республиканың гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар төзү программасын гамәлгә ашыру да дәвам итә. аның нигезендә 2018 елда 8 мәктәп үз ишекләрен ачты, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» МБМУнең яңа бинасы;

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының “Әлши урта гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУнең яңа бинасы;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «36 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Совет районының «183 нче гимназиясе» МБМУ;

Казан шәһәре Совет районының «М.И.Мәхмүтов ис. аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 184 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Киров муниципаль районының «182 нче Политехник лицее» МБМУ;



Казанкино башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе – «П.С.Курасанов ис. 1 нче Чирмешән урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ филиалы;

Чаллы шәһәренең “39 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ.

Ел дәвамында шулай ук Әлки муниципаль районының “Татар Борнае төп гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУнең,







Чирмешән муниципаль районының Сосновака башлангыч мәктәбе – «Ульяновск урта гомуми белем бюирү мәктәбе" МБМУ филиалының яңа биналарын төзү эшләре гамәлгә ашырылды.

Шул ук вакытта, 2012 – 2018 елларда капиталь ремонт программасы буенча 781 гомуми белем бирү мәктәбе ремонтланды.

Моннан тыш, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга гомуми белем бирү мәктәпләренә керү мөмкинлеген тәэмин итү өчен 2012 елдан башлап республиканың гомуми белем бирү учреждениеләре биналарында уңайлы мохит булдыру эше башланды. 2012 – 2018 елларда 334 мәктәптә, шул исәптән 41 махсус (коррекцияле) мәктәптә җайлаштыру чаралары үткәрелде. 2018 елда 12 гомуми белем бирү оешмасында, шул исәптән 5 махсус (коррекцияле) мәктәптә аз хәрәкәтләнүчән балалар төркемнәре өчен махсус объектлар барлыкка килде. Бу гамәлләр өчен 2012 елдан башлап 541 млн. сум акча тотылды.

Соңгы ике елда муниципалитетлар 168 яңа мәктәп автобусы алдылар, шул исәптән 127 – федераль акчалардан. Республика Президенты ярдәме белән мәгариф идарәсе органнарының автопаркын яңарту максатларында муниципалитетларга 34 җиңел автомобиль һәм 57 автобус бирелде.

Татарстан Республикасында төрле ведомстволарга карый торган 439 өстәмә белем бирү оешмасы эшли, аларда 321 мең бала шөгыльләнә, бу гомуми санның 77 % ын тәшкил итә.

*1 нче таблица*

***2018 елда Татарстан Республикасында балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары һәм аларда укучы балалар саны***

| **Эшчәнлек юнәлешләре буенча оешмалар** | **Балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары саны, бер.** | ***Аларда укучы балалар саны*, кеше** |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | **154** | **189 452** |
| Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | **105** | **38 206** |
| Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы | **170** | **89 035** |
| Балаларга өстәм белем бирү оешмаларының дәүләткә карамаган челтәре | **10** | **4 255** |
| Барысы | **439** | **320 928** |

2018 елда балалар өчен 5 өстәмә белем бирү учреждениесенә капиталь ремонт ясалды, алар өчен 106,0 млн сум акча тотылды, шул исәптән 2 спорт мәктәбенә. Федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, шулай ук хосусый инвесторлар акчаларыннан балаларга өстәмә белем бирүнең матди-техник базасын ныгытуга 2016 – 2018 елларда 201 млн. сумнан артык акча җәлеп ителде.

2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү буенча федераль максатчан программа кысаларында республикада JuniorSkills компетенцияләре буенча 9 база мәйданчык төзелде.

Республикада ***спорт объектлары челтәре инфраструктурасын,*** шул исәптән балалар өчен, үстерү, һичшиксез, өстенлек итә.

Татарстан Республикасында 10 844 спорт объекты эшли, шул исәптән авыл җирлекләрендә – 4 979.














2018 елда республика программасы кысаларында районнарда түбәндәгеләр төзелде:

Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авылында тент япмасы белән ачык шугалак;

Апас, Әлмәт, Әтнә, Югары Ослан, Мамадыш, Түбән Кама, Питрәч, Тукай, Теләче муниципаль районнарында 9 ябык йөзү бассейны;

Алексеевск, Апас, Чүпрәле, Лаеш һәм Чирмешән муниципаль районнарында 5 универсаль спорт залы;

Саба муниципаль районында Байлар Сабасы ш.т.п.ында универсаль спорт комплексы;

Лаеш муниципаль районының Каип авылында универсаль спорт комплексы.

Универсаль спорт мәйданчыкларын төзү буенча масштаблы проектны гамәлгә ашыру кысаларында 2013 елдан башлап республиканың барлык муниципаль районнарында 887 спорт мәйданчыгы, төзелде, 2018 елда 112 универсаль-спорт мәйданчыгы һәм блок-модуль чаңгы базалары төзелде. Бу максатлар өчен республика бюджетыннан 2 261,2 млн. сум акча бүленде, шул исәптән 2018 елда – 422,3 млн. сум.

Татарстан Республикасында балаларны **ял иттерү һәм савыктыру** өчен кирәкле һәм тиешле шартлар тудыруга зур игътибар бирелә.

2014 елда Татарстан Республикасында шәһәр яны стационар савыктыру учреждениеләре объектларын капиталь ремонтлау һәм төзү буенча өчьеллык программа эшли башлады. Әлеге программа буенча 2014 елдан башлап гомумуи суммасы 606,35 млн. сумлык 54 шәһәр яны лагерена ремонт ясалды, 15 лагерь төзелде, 5 лагерьга ремонт ясалды. 2018 елда 200 млн. сумга 14 лагерьга ремонт ясалды, 6 лагерь төзелде, 1 – реконструкцияләнде.

Балаларны һәм яшьләрне савыктыру кампаниясен оештыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан 2018 елда 1 458 млн. сум бүлеп бирелде, бу 2016 елдагыга караганда 26,7 млн. сумга күбрәк (2017 елда – 1 431,3 млн. сум).

2018 елның җәйге чорында 1 836 ял итү оешмасы эшләде. 2018 елның савыктыру кампаниясе чорында 219 752 бала ял итте, бу 2017 елга караганда 1 243 кешегә күбрәк. 2018 елда балаларны һәм яшьләрне савыктыру кампаниясен финанслауның гомуми күләме 1 731,0 млн. сум булды, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 495,2 млн. сум.

Ял программасы үзенең социаль юнәлешен сакелап калды. 2018 елда 54 831 кешегә ял һәм савыктыру юлламалары бирелде, алар тулысынча республика бюджеты акчаларыннан түләнде, шул исәптән 13 616 юллама авыр тормыш шартларындагы балалар өчен бирелде. Моннан тыш, 2018 елда хроник авырулардан интегүче балаларны шифаханәдә дәвалау, реабилитацияләү өчен, шулай ук хроник авырулары булган балалар өчен “Балалар” һәм “Ана һәм бала”юлламалары буенча 7 790 юллама бирелде.



Республикада балалар һәм яшьләр өчен ***ял итү учреждениеләре челтәрен*** киңәйтүгә зур игътибар бирелә.

2015 елда Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов тарафыннан яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау программасы хупланды. Программаны гамәлгә ашыруның дүрт елында 6 яшьләр үзәгенә 88,4 млн. сумлык капиталь ремонт ясалды, 114 – яшүсмерләр клубына 400 млн. сумлык, шуларның 28е – 2018 елда – 100 млн. сумлык.

Балаларның һәм яшүсмерләрнең культуралы ял итүен оештыруда, аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерүдә мәдәни, ял итү учреждениеләренең роле бик зур. Авыл халкының, шул исәптән авыл балаларының ялын оештыру һәм аларга иҗади мөмкинлекләр өчен заманча шартлар тудыру максатында, Татарстан Республикасында 2012 елдан күпфункцияле мәдәни үзәкләр (авыл клублары) төзү программасы эшләп килә. Шул чорда республикада 285 авыл мәдәният йорты төзелде – 2,9 млрд. сумлык, шул исәптән 2018 елда 28 авыл мәдәният йорты төзелде – 282 млн. сумлык.



2015 елдан республикада мәдәни билгеләнештәге объектларны капиталь ремонтлау программасы эшли. Шул чорда 156 мәдәният учреждениесенә 1,14 млрд. сумлык ремонт ясалды, шул исәптән 2018 елда 42 мәдәният объектына 343 млн. сумлык капиталь ремонт ясалды.



2015 елдан Татарстанда ***җәмәгатьчелек киңлекләрен үстерү*** (“Парклар һәм скверлар” – 2015 елдан, «Су саклау зоналарын төзекләндерү» – 2016 елдан) программасы эшли. Программаны гамәлгә ашыру башланган вакыттан 315 объект төзекләндерелде, шул исәптән 2018 елда – 58. Татарстан Республикасы «Уңайлы шәһәр мохитен булдыру» проектын гамәлгә ашыру буенча Россия төбәкләре рейтингында 1 урынны алды.



***Социаль ярдәм чараларының гамәлгә кергән системасы*** өлешендә 2018 ел дәвамында тиешле пособиеләр һәм түләүләр сакланып калды һәм, инфляция үсеше темпларын исәпкә алып, индексацияләнде. Икътисадый проблемалар булуга карамастан, узган ел республика бюджетының балаларга һәм балалы гаиләләргә гамәлдәге законнарда каралган социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә чыгымнары артты һәм 6 315,7 млн.сум (2017 елда – 5 921,7 млн. сум) тәшкил итте.

Татарстан Республикасында балалар тууын арттыру буенча чараларны көчәйтү максатларында 2018 елның 1 гыйнварыннан бер мәртәбәле түләүләр кертелде:

авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда кимендә өч ел даими яшәүче 25 яшькә кадәрге хатыннарга беренче бала тудыргач – 50 мең сум;

авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда кимендә өч ел даими яшәүче 29 яшькә кадәрге хатыннарга өченче бала тудыргач – 100 мең сум.

2018 елда гаиләләргә социаль ярәм федераль һәм республика бюджетларыннан 6,6 млрд. сум акча бирелде, бу тулаем республика буенча каралган социаль ярдәм чарараларының 40%ын тәшкил итә. 2018 елда 430,7 мең кеше балалы гаиләләр өчен булган социаль ярдәм чараларын алдылар.

2018 елда биш һәм аннан күбрәк бала тудырган һәм тәрбияләүче (тәрбияләгән) 105 ана «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнде. Аларга бер мәртәбәле түләү бирелә: биш балалы аналарга – 50 мең сум; алты һәм аннан күбрәк балалыларга – алтынчы баладан алып һәркайсына тагын 10 мең сум исәбеннән түләнә, әмма бүләкләү көненә бу балаларга өч яшь тулган булырга тиеш.





2017 – 2018 елларда социаль учреждениеләрне капиталь ремонтлау программасы кысаларында балалар һәм яшүсмерләр өчен 10 социаль приютта 29 627,9 мең сумга ремонт эшләре башкарылды, 2 сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен йортка – 13 813 мең сумга, мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен 9 реабилитация үзгендә – 29 707,5 мең сумга, шул исәптән 2018 елда балалар һәм яшүсмерләр өчен 8 реабилитация үзгендә һәм 3 социаль приютта ремонт ясалды.

Татарстан Республикасының социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына 19 дәүләткә карамаган оешма кертелде (2017 елда – 13 оешма, 2016 елда – 8 ешма, 2015 елда – 3 оешма), шул исәптән мөмкинлекләре чикле балаларга һәм яшүсмерләргә реабилитация хезмәтләре күрсәтүче 7 дәүләткә карамаган оешма (шул исәптән 5 СОНКО).

Бала хокукларын тәэмин итүгә турыдантуры яисә якынча гына йогынты ясый торган гомуми характеристиканы күз алдына китергәндә, 2018 елда республикада балаларның һәм балалы гаиләләрнең ***торак мәсьәләсен*** хәл итүгә ярдәм чараларына тукталып китәргә кирәк.

Күпбалалы гаиләләргә торак төзелеше өчен җир кишәрлеген түләүсез бирү (тапшыру) күздә тотылган федераль һәм региональ закон нормаларын Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру дәвам итә.

2018 ел ахырына дәүләт ярдәменең әлеге чарасына хокукы булган һәм бу хакта мөрәҗәгать иткән 49 284 күпбалалы гаиләдән 32 372 гаилә, ягъни 64 %ы мондый хокукларыннан файдаланып, өлешле гомуми милеккә җир кишәрлекләре алдылар.

2018 елда ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итүне Россия Федерациясе бюджетыннан финанслауның гомуми күләме кимеде, әмма әлеге йөкләмәне үтәү өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары шактый артты. Мәсәлән, 2017 елда гомуми финанслау күләме 346,7 млн. сум булса, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары 302,8 млн. сум иде, ә 2018 елда гомуми финанслау күләме 355,3 млн.сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары 314,96 млн. сум тәшкил итте.

2018 елда күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәме чараларын региональ финанслау күләме артты. Бу биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы 46 гаиләгә торак субсидияләре түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 149,4 млн.сум (2017 елда – 144,3 млн.сум) акча бүлеп бирелде.



Гражданнарга торак мәсьәләсен социаль ипотека программасында катнашу юлы белән хәл итү мөмкинлеген бирә торган республика программасы кысаларында балалы гаиләләргә ярдәм итү чарасы буларак 200 000 сум күләмендә акчалата компенсация бирү дәвам итте, ул программада катнашучы гаиләдә бала тугач, шулай ук уллыкка (кызлыкка) бала алгач бирелә. Шуны билгеләп үтәргә кирәк, 2018 елда мондый чараны финанслауның гомуми күләме 173,7 млн. сумга артты һәм ул хәзер 688,4 млн. сум тәшкил итә (2017 елда – 513,7 млн. сум).

## 2.3. 2018 елда халыкара, федераль һәм республика законнарындагы бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсенә караган яңалыкларга күзәтү

Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан яклауны тәэмин итүнең торышын бәяләү өчен бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләрен хокукый җайга сала торган гамәлдәге законнарга, дөресрәге, андагы үзгәрешләргә һәм узган чордагы яңалыкларга анализ ясарга кирәк.

Соңгы елларда, шулай ук 2018 елда да, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләрен җайга сала торган нинди дә булса ***халыкара норматив хокукый актларны*** Россия Федерациясе тарафыннан ратификацияләү яисә имзалау булмады.

Ф***едераль дәрәҗәдә*** түбәндәге мәсьәләләр регламентлаштырылды.

*«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»* 2018 елның 18 апрелендәге 85-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органының балалар ялын оештыру эшенә җәмәгатьчелек контроленең яңа формасы кертелде.

Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының балалар ялын һәм аларны савыктыруны оештыру мәсьәләләре буенча аларның ата-аналары (аларны алыштыручы затлары) белән үзара хезмәттәшлеге гавами башкарылырга тиеш дип билгеләнә. Ата-аналарның язмача яисә электрон документ рәвешендә җибәрелә торган мөрәҗәгатьләре һәм бу мөрәҗәгатьләргә җаваплар «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш. Моннан тыш, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы вәкаләтләре балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча үрнәк шартнамә формасын раслау юлы белән өстәлә, ә Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнарының балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру вәкаләтләре – балаларның оешкан төркемнәре үтү өчен тәкъдим ителүче туристик маршрутлар исемлеген (башка маршрутлар хәрәкәтен) раслау һәм күрсәтелгән мәгълүматны үзенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән өстәлә. Шулай ук «Интернет» челтәрендә Россия Федерациясе субъектлары тиешле башкарма хакимият органнарының рәсми сайтларында балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру оешмаларының реестрлары урнаштырылырга тиеш.

*«Россия Федерациясенең кайбер закон актларына ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан чыккан затларны торак урыннары белән тәэмин итү*

*өлешендә үзгәрешләр кертү турында»* 2018 елның 30 июлендәге 267-ФЗ номерлы Федераль закон белән ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны (алга таба – ятим балалар), ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан чыккан затларны (алга таба – ятим балалар арасыннан чыккан затлар) торак урыннары белән тәэмин итү механизмын камилләштерде.

Аерым алганда, ятим балаларны, ятим балалар арасыннан чыккан затларны торак алу өчен исемлеккә (алга таба – исемлек) кертү һәм аларны исемлектән чыгару тәртибе төгәлләштерелде. Мәсәлән, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге балаларның законлы вәкиленә балаларны исемлеккә кертү турында гаризаны мөстәкыйль бирү мөмкинлеге бирелә, ә опека һәм попечительлек органнарына балаларны исемлеккә кертү турындагы гаризаны ятим балаларның законлы вәкилләре тарафыннан вакытында кертелүен тикшереп тору йөкләнә. Законлы вәкилләр тарафыннан тиешле гариза бирелмәгән очракта, опека һәм попечительлек органы балаларны исемлеккә кертү буенча чаралар күрергә тиеш. Моннан тыш, беренче биш ел срок узганнан соң махсус торак урынын яллау шартнамәсе буенча торак урыны бирү срогына кагылышлы җитди үзгәрешләр бар. Кертелгән үзгәрешләр нигезендә Россия Федерациясе субъектларының опека һәм попечительлек буенча вәкаләтләр башкаручы башкарма хакимият органнарына беренче биш ел срок узганнан соң махсус торак урынын яллау шартнамәсе төзү зарурлыгы турында карар кабул итү хокукы бирелә. Мондый карарны кабул итү күрсәтелгән категориядәге затларның мәнфәгатьләрен, шул исәптән мөлкәти мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында аларны тикшереп торуның зарурлыгын раслый торган фактик белешмәләргә нигезләнергә тиеш.

*«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау турында» 2018 елның 3 августындагы 299 номерлы Федераль закон* белән дәвалау өчен дару препаратлары Россия Федерациясе Сәламәтлек министрлыгы тарафыннан федераль бюджет акчадары исәбеннән үзәкләштерелгән рәвештә сатып алына торган сирәк очрый торган (орфан) авырулар исемлег киңәйтелде, аңа зур чыгымнар таләп итә торган тагын биш авыру төре кертелде: гемолитико-уремический синдром, яшүсмерләрдә була торган системалы башлангыч белән артрит, I, II VI типлардагы мукополисахаридоз.

*«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2018 елның 3 августындагы 317-ФЗ номерлы Федераль закон белән* мәктәпкәчә, башлангыч, төп гомуми белем бирү оешмаларында туган телдә белем алу һәм туган телне өйрәнү хокукы регламентлаштырыла.

Мәсәлән, Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан булган туган телне, шул исәптән рус телен туган тел буларак өйрәнү хокукы укуыларның һәм аларның ата-аналарының ихтыяҗларын исәпкә алып гамәлгә ашырылачак. Мәсәлән, Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан булган туган телне, шул исәптән туган тел буларак рус телен, Россия Федерациясе республикаларының дәүләт телләрен ирекле сайлап алу хокукы дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга алганда (күчергәндә) балигъ булмаган укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) гаризалары буенча гамәлгә ашырыла.

*«Россия Федерациясендә бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2018 елның 27 декабрендәге 501-ФЗ номерлы Федераль закон белән* Россия Федерациясендә бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр институтының эшчәнлеге регламентлаштырыла. Мәсәлән, закон белән Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең (алга таба – Вәкаләтле вәкил) хокукый хәле

үзенчәлекләре, төп бурычлары, вәкаләтләре, шулай ук Россия Федерациясендә субъектларында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең хокукый статусы билгеләнә.

*Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 29 маендагы 240 номерлы Указы белән якындагы ун елда Россия Федерациясендә Балачак унъеллыгы дип игълан ителде.* Әлеге документ балалар мәнфәгатьләрендә уйланылган системалы дәүләт сәясәтенең дәвамы булды аның нигезләре беренче мәртәбә 1994 елның 18 августында Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган «Россия балалары» Президент программасында салынган иде, аннары – Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы указы белән расланган 2012 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең Илкүләм стратегиясендә, аның гамәлдә булуы 2017 елда тәмамланды, бу инде Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Балачак унъеллыгы кысаларында уздырыла торган 2020 елга кадәр төп чаралар планын эшләү зарурлыгын китереп чыгарды.

Бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив хокукый закон актлары арасындагы яңалыклардан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең түбәндәге актларын атарга кирәк:

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балаларны уллыкка (кызлыкка) тапшыру һәм Россия Федерациясе территориясендә уллыкка алучылар гаиләләрендә аларның тормыш шартларына контрольне гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 9 апрелендәге 427 номерлы карары белән* Россия Федерациясенең төп аз санлы халыкларыннан булган күчмә тормыш алып баручы гражданнары тарафыннан балаларны уллыкка алу үзенчәлекләре билгеләнде.

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 6 июлендәге 1375-р номерлы күрсәтмәсе белән* Балачакның унъеллыгы кысаларында 2020 елга кадәр уздырыла торган төп чаралар планы (алга таба – План) расланды. Планда түбәндәге бүлекләр белән кайбер чараларны уздыру каралган: балалы гаиләләрнең иминлеген арттыру; балалар иминлеген тәэмин итү; сәламәт бала; балаларга һәрьяклап белем бирү; балаларны мәдәни үстерү; балалар өчен физкультураны һәм спортны үстерү; балаларның имин ялы; һәркем өчен туризм; балалар өчен имин мәгълүмат киңлеге; бала һәм аның гаиләгә хокукы; ятим балаларны һәм сәламәтлеге чикле балаларны социаль яклау һәм аларның бүгенге җәмгыятькә яраклашуы; балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау; сыйфатлы балалар товарлары һәм азык-төлек продуктлары; оештыру чаралары. Әлеге күрсәтмә белән Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарына үз эшчәнлеген агмәлгә ашырганда План чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә тәкъдим ителде.

*Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2018 елның 23 августындагы 6 номерлы боерыгы белән* балаларның ялын һәм савыктыруны оештыру һәм тәэмин итү буенча хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк формасы расланды, ул балаларның ялын һәм савыктыруны оештыручы оешма һәм баланың ата-анасы (законлы вәкиле) тарафыннан төзелергә мөмкин. Шартнамәгә түбәндәге бүлекләрне кертергә тәкъдим ителә: якларның үзара хезмәттәшлек итү тәртибе; түләү күләме, сроклары һәм тәртибе; якларның җаваплылыгы; шартнамәне үзгәртү һәм өзү нигезләре. Шулай ук шартнамәгә хезмәтләр күрсәтү чорында балалар өчен оештырыла торган чаралар исемлеген кушып бирергә тәкъдим ителә, анда чараларның исемнәре һәм хезмәтләр (индивидуаль, төркемле) күрсәтү рәвешләре бирелергә тиеш.

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 27 сентябрендәге 600н номерлы боерыгы белән *«Балалар өчен товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең иминлеге буенча белгеч» Һөнәри стандарты* расланды.

Стандарт нигезендә бу белгечләр эшчәнлегенең максаты балалар өчен чыгарыла торган өчен товарларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең иминлеген тәэмин итүдән гыйбарәт. Бу белгечләрнең функциясенә балалар өчен өчен товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең иминлеге һәм бәяләү эшләренә лаборатор-техник тикшерүләр уздыру, җитештерелә торган товарлар һәм күрсәтелә торган хезмәтләр иминлегенә контроль уздыру, балалар өчен товарларны җитештерүне һәм аларга хезмәтләр күрсәтүне проектлау, аларны җитештерү, ташу, саклау һәм сату стадиясендә техник контроль уздыру, балалар өчен товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең иминлегенә инспекция контроле уздыру керә. Стандарт белән бу функцияләрне башкару өчен белгечкә кирәкле белемгә һәм аның эш тәҗрибәсенә таләпләр билгеләнә.

*Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2018 елның 7 мартындагы 92н номерлы боерыгы белән Россия Федерациясендә балаларга медицина һәм дәүләт, муниципаль һәм шәхси сәламәтлек саклау системалары тарафыннан беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) расланды.* Элегрәк балаларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү балалар сәламәтлеген саклауның барлык мәсьәләләрен үз эченә алган киңрәк спектрдагы норматив хокукый акт белән (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2013 елның 5 ноябрендәге 822н номерлы «Балигъ булмаганнарга, шул исәптән мәгариф оешмаларында уку һәм тәрбияләнү чорында медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» боерыгы) регламентлаштырылган иде. Хәзер беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү мәсьәләләре махсус җайга салу предметына әверелде, бу сәламәтлек саклауда әлеге юнәлешнең ни дәрәҗәдә мөһим булуын күрсәтә.

Шулай итеп, Нигезләмә нигезендә беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү медицина ярдәме күрсәтүнең төп системасын тәшкил итә һәм үз эченә авыруларны һәм аларның торышын диагностикалау, дәвалау, профилактикалау чараларын, медицина реабилитациясен, сәламәт тормыш рәвешен булдыруны, шул исәптән авырулар барлыкка китерә торган факторларны киметүне һәм халыкны санитария-гигиена ягыннан агартуны үз эченә ала. Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү табиб килгәнче ярдәм күрсәтүне, табиб ярдәмен һәм махсус ярдәм күрсәтүне үз эченә ала һәм болар амбулатор шартларда һәм көндезге стационар шартларында гамәлгә ашырыла. Балаларга табибка кадәрге ярдәм урта медицина белеме булган фельдшерлар һәм башка медицина хезмәткәрләре тарафыннан күрсәтелә; табиб ярдәме – педиатр-табиблар һәм гомуми практика табиблары (гаилә табиблары) тарафыннан; махсус медицина ярдәме белгеч-табиблар тарафыннан күрсәтелә. Балаларга шундый ярдәм күрсәтүне оештыру территориаль-участок принцибы буенча гамәлгә ашырыла, ул яшәү (тору) урыны буенча яисә уку (эшләү) урыны буенча халыкка хезмәт күрсәтә торган төркемнәр булдыруны күздә тота. Балаларны төркемнәр буенча бүлү медицина оешмалары җитәкчеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Участокта беркетелгән балалар саны 800ләп булырга тиеш, бу сан эченә медицина оешмасының штат саны һәм медицина хезмәткәрләре саны да керә.

Карала торган боерык белән шулай ук табиб-педиатр кабинеты эшчәнлеген оештыру кагыйдәләре, штат нормативлары һәм участок табиб-педиатр кабинетын, балалар поли-

клиникасын, балалар консультатив-диагностикалау үзәген, балалар поликлиникасының көндезге стационарын (балалар поликлиника бүлекчәсен) җиһазлау стандартлары расланды.

*Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2018 елның 9 ноябрендәге 196 номерлы боерыгы белән Өстәмә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыруның һәм гамәлгә ашыруның яңа тәртибе расланды.*

Аерым алганда, өстәмә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә аашыру максатлары; өстәмә белем бирү программаларын раслау тәртибенә таләпләр; өстәмә белем бирү программалары төрләре; өстәмә белем бирү программалары буенча укыту процессын оештыру үзенчәлекләре; өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруның мөмкин булган рәвешләре; өстәмә белем бирү программаларын яңартуга таләпләр; өстәмә белем бирү программалары буенча укыта торган затларга таләпләр; мөмикнлекләре чикле балаллар өчен өстәмә белем бирү программалары буенча укыту процессын оештыруга таләпләр билгеләнде.

***Гаилә законнарының хокук куллану практикасында*** түбәндәге яңалыкларга игътибар итү мөһим.

Россия Федерациясе Конституция Судның 2018 елның 20 июнендәге 25-П карары белән Россия Федерациясе Гаилә кодксының 127 статьясындагы 1 пунктының 6 пунктчасына һәм баланы уллыкка (кызлыкка), опекага һәм попечительлеккә, гаилә тәрбиясенә яисә патронат гаиләгә алу рөхсәт бирелми торган авырулар исемлегенең 2 пунктына (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 14.02.2013 № 117 карары белән расланган) аларның конституциячеллегенә бәяләмә бирелде. Әлеге нигезләмәләр кеше иммунодефициты һәм (иясә) С гепатиты вирусы белән йогышланган затларга баланы уллыкка (кызлыкка) алу, әгәр бала даими рәвештә алар белән бер гаиләдә яши торган булса, рөхсәт ителмәү турында карар кабул итү өчен нигез булып торалар. Россия Федерациясе Конституция Суды әлеге карар белән аларны аларны кеше иммунодефициты һәм (иясә) С гепатиты вирусы белән йогышланган затларга баланы уллыкка (кызлыкка) алу, әгәр бала даими рәвештә алар белән бер гаиләдә яши торган булса, рөхсәт ителмәү турында карар кабул итү өчен нигез булып торучы өлешендә Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килә дип таныды, әгәр суд белән билгеләнгән хәлләр бөтенесе бергә уллыкка алуны юридик яктан рәсмиләштерегән һәм алар бала мәнфәгатьләреннән чыгып башкарылган булса.

***Татарстан Республикасы законнарына килгәндә,*** 2018 елда түбәндәге әһәмиятле норматив хокукый актлар кабул ителде.

*«Татарстан Республикасында беренче бала туугa (уллыкка алуга) бәйле рәвештә айлык түләү билгеләүне һәм аны түләүне оештыру турында» 2018 елның 11 апрелендәге 18 номерлы Татарстан Республикасы Законында* нигез «Балалы гаиләләргә айлык түләүләр турында» 2017 елның 28 декабрендәге 418-ФЗ номерлы Федераль закон нормалары алынды һәм алар үстерелде. Мәсәлән, беренче бала тууга (уллыкка алуга) бәйле рәвештә айлык түләүне билгеләү һәм аны түләү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган исемлек нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары карамагына тапшырылды.

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 13 статьялары-

на үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы белән балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләренең координатор функцияләре киңәйтелде. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре хәзер балигъ булмаганнарны җинаятьләр, хокука каршы һәм (яисә) җәмәгатьчелеккә каршы башка гамәлләр кылуга, шулай ук аларны суицидаль гамәлләргә этәрү очракларын ачыклауда һәм аларны булдырмый калуда берләштерү звеносы булып тора.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте норматив хокукый актларны арасында түбәндәгеләргә игътибар итәргә кирәк.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 19 гыйнварындагы 19 номерлы карары белән балалар төркемнәрен чыгаруны оештыру буенча Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документ әйләнешенең бердәм системасында ведомстоара хезмәттәшлек регламентлаштырылды.*

Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документ әйләнешенең бердәм системасында ияртүле хатка балалар төркемен оештыру өчен җаваплы дәүләт яисә муниципаль оешмалар билгеләнә һәм түбәндгеләр турындагы документларны килештерүгә җибәрәләр: кая булса чыгу өчен нигезләр, фрахта шартнамәсе, медицина хезмәткәре турында белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасы исеме, вазыйфасы), ашамлык продуктлары җыелмасы исемлеге (өч сәгатьтән артык юлда булучы балалар өчен), балалар исемлеге (фамилияләре, исемнәре, аталары исеме (булганда) һәм һәр баланың яше, ата-аналарының (законлы вәкилләренең) элемтә өчен телефон номерлары, юлга чыгучыларга ияреп чыгучылар исемлеге, машина йөртүче (водитель) турында белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме, телефон номеры), балаларны автобуска утырту тәртибе, маршрутның программасы, автобуста балалар төркемен алып чыгу турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр органының Юллар хәрәкәте иминлегенең инспекциясе идарәсенә хәбәр итү. Күрсәтелгән документлар юлга чыгу инициаторы тарафыннан ведоствоара электрон документ әйләнешенә системасында килештерү өчен адресатка бердәм докумен итеп җибәрелә. Имзаланганнан соң документ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекнең башкарма комитетында яисә, нинди ведомство каравында булуыннан чыгып, Татарстан Республикасы дәүләт оешмасында теркәлә. Килештерү нәтиҗәсе яисә адресатлар тарафыннан хатлар алынганнан соң документ килештерелгән дип санала. Документ килештерү өчен инициаторга юлга чыгу алдыннан биш эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә. Инициатор шәхси белешмәләрне эшкәртүгә юлга чыгучыларның ризалыгын алуны тәэмин итә. Карар белән шулай ук балалар төркеменең Татарстан Республикасы буенча һәм аннан читкә чыгарга торулары турында хәбәр итү хатының формасы раслана.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә даими яшәүче хатын-кызларга бала тудыргач бер мәртәбә түләүләр бирү турында»* 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карары белән түбәндәге түләүләр кертелде: авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда кимендә өч ел даими яшәүче 25 яшькә кадәрге хатыннарга беренче бала тудыргач – 50 мең сум; авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда кимендә өч ел даими яшәүче 29 яшькә кадәрге хатыннарга өченче бала тудыргач – 100 мең сум. Хатыны үлгәндә, ул ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгәндә (ата-ана хокуклары чикләнгәдә) бер мәртәбә түләү баланың атасына (опекунга) бирелә. Бала тугач бер мәртәбәле түләү ул туганнан соң алты айдан да соңга калмыйча мөрәҗәгать иткәндә бирелә. Бала тугач бер мәртәбәле түләү бирүдән баш тарту

өчен булган белешмәләрдә моның өчен сәбәп булырлык хәлләр ачыклану һәм аны алу өчен хокук бирә торган документлар булмау нигез була.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 26 апрелендәге 294 номерлы карары белән үзенең* «Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы карарына үзгәрешләр кертелде. Кертелгән үзгәрешләр белән түбәндәге позицияләр буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре өчен йөкләмәләр, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, яшьләр, балалар иҗтимагый оешмаларына күрсәтмәләр исемлеге киңәйтелде:

палата тибындагы туристик лагерьларны оештыру маршрутын һәм юлда барганда туктау пунктларын Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсенең территориаль органы белән килештерү (Татарстан);

палата тибындагы туристик лагерьларның, шул исәптән күчмә лагерьларның, урнашу урыны, аларның туристик маршруты, контроль пунктлар һәм аларны узу сроклары, төркемнең составы турында “Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының эзләүкоткару хезмәте” дәүләт казна учреждениесенә хәбәр итү.

Шулай ук шәһәр читендә ял итү лагеренда ике этаплы – 3 һәм 4 көнлек 7 көн дәвамлы профильле смена оештыру мөкинлеге карала.

«Татарстан Республикасында беренче бала туугa (уллыкка алуга) бәйле рәвештә айлык түләү билгеләүне һәм аны түләүне оештыру турында» 2018 елның 11 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 маендагы 389 номерлы карары белән беренче бала туугa (уллыкка алуга) бәйле рәвештә айлык түләү билгеләүне һәм аны түләүне оештыру өчен вәкаләтле оешма итеп Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Матди ярдәмнең (компенсация түләүләренең) республика үзәге» дәүләт казна учреждениесе билгеләнде.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга айлык һәм башка төр түләүләр турында» 2018 елның 10 сентябрендәге 767 номерлы карары белән* 2019 елның 1 гыйнварыннан айлык һәм башка төр түләүләрне индексацияләү коэффициенты 1,043 итеп билгеләнде.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 13 сентябрендәге 777 номерлы карары белән* дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары һөнәри белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп белем бирү программалары буенча укучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан чыккан затларга, уку чорында ата-анасыз калган яисә аларның берсе белән генә калган затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм төрләре буенча 2019 елга түләүләр күләмнәре расланды.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 4 сентябрендәге 2332-р күрсәтмәсе белән* 2018 – 2022 елларга ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ата-ананы алыштыручы гаиләдә тәрбиядә торучыларны, шулай ук ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен булган оешмаларда торучыларны яклауны көчәйтүгә юнәлдерелгән өстәмә чаралар комплексы расланды. Әлеге комплекс, аерым алганда, ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән

мәхрүм калган балаларның өстенлеген пропагандалый торган даими мәгълүмат-агарту кампаниямәрен уздыруны; гаилә кыйммәтләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән республика чараларын оештыруны; опека һәм попечительлек органнары, ата-ананы алыштыручы гаиләләр белән эшләүче хезмәтләр, ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның оешмалары белгечләренең белем һәм һөнәри дәрәҗәләрен анализлауны; ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен булган оешмаларның белгечләрен балаларны карауның индивидуаль планын төзүгә һәм ата-ананы алыштыручы гаиләләрдә тәрбияләнүчеләр белән эшләү буенча укытуны; алыштыручы ата-аналарның һәм опека һәм попечительлек ораганнарының ата-ананы алыштыручы гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүләрен тәэмин итүне; опекада торучы балаларның, ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның тормыш шартларын, аларның хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешен, аларның мөлкәтенең сакланышын тәэмин итүне, шулай ук опекуннарның үз хокукларын һәм бурычларын үтәүләрен тикшереп тору критерийларын эшләүне; экспертиза, диагностика, нәтиҗәләрне интерпретацияләү, коррекция-үстерү эшләрен башкару өчен тикшерү органнары белгечләре һәм психологик-педагогик һәм социаль-медицина юнәлешендәге махсус белемнәре булган белгечләр (психологлар, педагоглар, юристлар, табиб-психиатрлар) катнашында опекада (попечительлектә) торучы балаларның тормыш һәм тәрбия шартларын тикшереп торуны; алыштыручы гаиләләрдәге кризис хәлләрне педагогик коллективлар, алыштыручы гаиләләрдәге балаларны укыта торган мәгариф оешмаларының психологлары белән бергә ачыклау һәм профилактикалау эшен оештыруны күздә тота.

Шулай ук республикада 2018 елда билгеләп үтелгән түбәндәге ***социаль әһәмиятле мәсьәләләр дә*** игътибар үзәгендә булды.

Республика өчен мөһим булган мәсьәләләрнең берсе – *2020 елга кадәр* Балалыкның унъеллыгы кысаларында уздырыла торган *Татарстан Республикасы чаралар планын* раслау булды. Әлеге документ Россия Федерациясе Хөкүмәтенең *2020 елга кадәр* Балалыкның унъеллыгы кысаларында уздырыла торган *төп чаралар планын* раслый торган 2018 елның 6 июлендәге 1375-р номерлы Күрсәтмәсен (алга таба – федераль план) үстерү максатында кабул ителде. Ул федераль планның төп идеяләрен үз эченә алган, болар, аерым алганда, балалар иминлеген тәэмин итү, сәламәт бала, балаларга – һәрьяклап белем бирү, балалар туризмы, балалар өчен имин мәгълүмат киңлеге, бала һәм аның гаиләгә хокукы, инвалид балаларны һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны социаль яклау һәм аларны бүгенге җәмгыятькә яраклаштыру, балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, сыйфатлы балалар товарлары һәм азык-төлек продуктлары юнәлешләре.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Т.П.Ларионова инициативасы белән һәм “Бердәм Россия” сәяси партиясе Иҗтимагый Советы ярдәмендә Татарстан Республикасында “Ныклы гаилә” сәяси проектын гамәлгә ашырып, республика җирле үзидарә органнарының хокукларны гамәлгә ашыру эшчәнлеге гаилә иминлеген яхшыртуга юнәлдерелгән яңалыкларга бай булды.

Мәсәлән, 39 муниципаль районда депутатлар Советлары сессияләре карарлары белән, Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән тәртиптә һәм тапшырылган вәкаләтләр кысаларында өч һәм аннан күбрәк, дүрт һәм аннан күбрәк, биш һәм аннан

күбрәк балалы гаиләләрне физик затлар мөлкәтенә салымнан азат ителүче гражданнар категорияләренә кертү турында карар кабул ителде. ***Өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләр*** **–** Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләрендә хәзер физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат ителәләр: Балтач, Чүпрәле, Зеленодольск, Кукмара, Түбән Кама, Әлмәт, Лаеш, Сарман, Минзәлә, Кама Тамагы муниципаль районнарында һәм Казан, Чаллы шәһәрләрендә; ***дүрт һәм аннан күбрәк балалы гаиләләр*** – Алексеевск, Алабуга, Кайбыч, Лениногорск, Яңа Чишмә, Сарман, Спас, Теләче, Апас, Баулы, Менделеевск, Ютазы, Азнакай, Актаныш, Югары Ослан муниципаль районнарында; ***биш һәм аннан күбрәк балалы гаиләләр*** – Әгерҗе, Аксубай, Арча, Балтач, Бөгелмә, Буа, Балык Бистәсе, Чирмешән, Биектау, Нурлат, Чистай, Әлки муниципаль районнарында.

# 2018 ЕЛДА ТӨП ТОРМЫШ ЭШЧӘНЛЕГЕ ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ БАЛА ХОКУКЛАРЫН ҮТӘҮ

3

БҮЛЕК

## 3.1. 2018 елда гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауга нигезләнгән Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләрнең гомуми мониторингы


Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендә проблемалы мәсьәләләрне ачыкларга мөмкинлек бирә торган мөһим индикатор була.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 2 103 мәсьәлә буенча 1 998 мөрәҗәгать керде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау, тормыш эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә балаларның хокукларын гамәлгә ашыруның торышын чагылдыра торган шикаятьләр санына карап, аларның **тематикасын** структураларга мөмкинлек бирә.

*20 нче диаграмма*


***2018 елда Ввәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




2018 ел йомгаклары буенча әлеге анализ нәтиҗәләреннән күренгәнчә, иң күп мөрәҗәгатьләр (2017 елдагы кебек) баланың белемгә хокуклары бозылуга карата керә.

*21 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда Вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасының структурасы***




2018 елда мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны арту, аерым алганда, баланың белем алуга хокуклары бозылуга карата шикаятьләрнең күбрәк булуына бәйле.

*2 нче таблица*


***2017-2018 елларда Вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасы***

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (абс., бер.) |
|---|---|---|---|
| | 2017 ел | 2018 ел | |
| **Барлыгы** | **2007** | **2103** | + 96 |
| Белемгә хокук | **510** | **658** | + 148 |
| Гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә хокук | **434** | **440** | + 6 |
| Торакка хокук | **437** | **426** | -11 |
| Лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук | **196** | **204** | + 8 |
| Яшәүгә хокук һәм сәламәтлек саклау хезмәтләренә хокук | **109** | **146** | + 37 |
| Социаль тәэмин ителешкә хокук | **128** | **145** | + 17 |
| Көч кулланудан яклануга хокук | **87** | **55** | -32 |
| Гражданлыкка хокук | **16** | **17** | + 1 |
| Фикер, вөждан һәм дин ирегенә хокук | **1** | **0** | – 1 |
| Башка мөрәҗәгатьләр | **20** | **12** | – 8 |

2018 елда мөрәҗәгатьләр саны буенча беренче урында ***балаларның белемгә хокукларын*** гамәлгә ашыру мәсьәләләре сакланып калды. Күрсәтелгән тематика буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 658 мөрәҗәгать керде, бу барлык кергән мөрәҗәгатьләр саныннан 31,3%ын тәшкил итә, һәр өченче мөрәҗәгать дигә сүз. Агымдагы елда бу тема буенча мөрәҗәгатьләр саны 2017 елга караганда 29%ка артты (148 мөрәҗәгать).

*22 нче диаграмма*

***2018 елда белем алу хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча кергән мөрәҗәгатьләр тематикасының структурасы***




*3 нче таблица*

***2017 – 2018 елларда белем алу хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы***

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (абс., бер.) |
|---|---|---|---|
| | 2017 ел | 2018 ел | |
| **Барлыгы** | **510** | **658** | +148 |
| Укучыларны белем бирү оешмаларына алу йә күчерү | **36** | **179** | +143 |
| Белем бирү процессында катнашучылар арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләр | **105** | **123** | +18 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Белем бирү оешмаларында туклануны оештыру | **93** | **120** | +27 |
| Мәктәпкәчә учреждениеләрдә урыннар бирү | **122** | **96** | -26 |
| Белем бирү оешмаларында укыту-тәрбияләү процессын оештыру, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты | **81** | **64** | -17 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларны укыту | **37** | **38** | +1 |
| Белем бирү оешмаларын бетерү, үзгәртеп кору | **18** | **4** | -14 |
| Укучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә транспорт хезмәте күрсәтү | **11** | **20** | +9 |
| Башка мөрәҗәгатьләр | **7** | **13** | +6 |

Бу тематика буенча мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге (179 яисә 27,2%) укучыларны белем бирү оешмаларына алу яисә күчерү мәсьәләләренә кагылышлы иде. Мондый мөрәҗәгатьләр 2017 ел белән чагыштырганда биш мәртәбә диярлек күбрәк. Аларның саны арту 2018 елның февралендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан оештырылган “кайнар линия” телефонының эшләве белән аңлатыла. Бу тематика буенча “кайнар линиягә” 105 мөрәҗәгать керде.

Әлмәт шәһәрендә “Татарстан нефтенең 70 еллыгы ис. 25 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУенең (65 мөрәҗәгать) һәм Казан шәһәре Киров районының “182 нче политехника лицее” МБМУенең (“Салават күпере” торак комплексы) 1 нче сыйныфларына балаларны кертү мәсьәләләре аеруча проблемалы булды.

Белем бирү өлкәсендә аеруча игътибар үзәгендәге мәсьәләләр рейтингында икенче урында – белем бирү процессында катнашучылар арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләр. Бу өлкәдә шикаятьләрнең артуы мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында белем бирү һәм тәрбияләү шартларында тискәре күренешләрнең сакланып калуын күрсәтә, бу, әлбәттә, борчуга сала. Шул ук вакытта мәктәпләрдәге конфликтларга кагылышлы шикаятьләр белемгә хокукларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать саны буенча беренче өчлектә дүрт ел инде өстенлек итә Мондый мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар, аларның җитәкчеләре адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан укучыларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында 24 бәяләмә җибәрелде, бу гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча бәяләмәләр санынннан 28 % тәшкил итә.

Анализдан күренгәнчә, 2018 елда укучыларны (тәрбияләнүчеләрне) тукландыруны оештыру мәсьәләләре буенча да мөрәҗәгатьләр артты. 2017 ел белән чагыштырганда аларның саны 29%ка артты ( 92дән 120гә). Бу категория мөрәҗәгатьләр өченче урынны ала. Бу темага иң күп мөрәҗәгатьләр Казан, Чаллы шәһәрләреннән, Түбән Кама муниципаль районыннан килде.


Белем бирү өлкәсендәге мөрәҗәгатьләр саны буенча дүртенче баскычта – балаларның мәктәпкәчә белемгә хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре (96 мөрәҗәгать). Узган ел белән чагыштырганда мондый шикаятьләр саны 21,3 %ка кимеде. Гражданнарның мәктәпкәчә белемгә бала хокукын гамәлгә ашыруга кагылышлы мөрәҗәгатьләре (46 мөрәҗәгать) арасында 48%ы өч яшькә кадәрге балаларны балалар бакчасына урнаштыруга ярдәм итүне сорап язылган, 11,5%ы (11 мөрәҗәгать) – сәләмәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларга ярдәм итүне сорап язылган.

Беренче өчлектәге икенче урыннны ***балаларның гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә*** хокукларын яклау турындагы мөрәҗәгатьләр булды. Агымдагы елда гаилә тәрбиясе, ата-ана бурычларын билгеләү һәм үтәү, балигъ булмаганнарның һәм башка туганнарның гаилә

элемтәләренә хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча төрле мөрәҗәгатьләрнең артуы күзәтелә. Бу тематика буенча 440 мөрәҗәгать каралды, бу барлык мөрәҗәгатьләр саныннан 21% тәшкил итә.

*23 нче диаграмма*

***2018 елда гаилә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематиксының структурасы***




*4 нче таблица*

***2017-2018 елларда гаилә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы***

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (абс., бер.) |
|---|---|---|---|
| | 2017 ел | 2018 ел | |
| **Барлыгы** | **434** | **440** | +6 |
| Ата-аналары аерылганнан соң, аларның берәрсе вафат булганнан соң балаларны тәрбияләү мәсьәләләре | **149** | **182** | +33 |
| Опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеге, балаларны опекага (попечительлеккә) тапшыру, уллыкка алу мәсьәләләре | **96** | **116** | +20 |
| Гаиләдәге ыгы-зыгылар турында хәбәр итү | **86** | **69** | -17 |
| Балаларны законсыз рәвештә алып китү һәм җибәрмәү | **36** | **33** | -3 |
| Ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү мәсьәләсен күтәреп чыгу | **27** | **18** | -9 |
| Ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән ата-аналарның балаларын кире кайтару теләге | **11** | **8** | -3 |
| Бу тематика буенча башка мөрәҗәгатьләр | **29** | **14** | -15 |

Агымдагы елда баланың ата-анасы аерылышканнан соң аның яшәү урынын ачыклауга бәйле бәхәсле вәзгыять турындагы, баланың аерым яшәүче атасы яисә анасы белән, башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү, бала белән аралашуга киртәләрне юкка чыгару хакындагы мәсьләләр буенча мөрәҗәгатьләр 41% тәшкил итте. Гаилә эчендәге мондый бәхәсле мәсьәләләрне хәл итүдә булышуны сорап 2018 елда 182 кеше мөрәҗәгать итте 2017 елда мондый мөрәҗәгатьләр 149 булган иде, ягъни 34,3% тәшкил иттте.

Узган елдагы кебек, 2018 елда да балаларны бүтән гаилә тәрбиясенә тапшыру мәсьәләләрен хәл итүдә муниципаль районнардагы опека һәм попечительлек органнарының гамәлләренә, аларның битарафлыгына карата да гражданнардан шикаятьләр ешрак килә башлады, шул исәптән опекадагы балаларны тоту өчен бирелә торган акчаларның дөрес

тотылмавына карата юлланганнары да бар. 2017 елда шул темага 96 мөрәҗәгать каралган булса, 2018 елда аларның саны 116га җитте, бу барлык мөрәҗәгатьләрнең 26,4%ын тәшкил итә (2017 елда – 22,1%).

2018 елда гаиләләрдәге социаль тотрыксызлык, гражданнарның үз ата-аналарына рәхимсезлеге, шул исәптән балаларга карата мәрхәмәтсезлек турындагы хәбәрләр саны кимеде (2017 елда – 86, 2018 елда – 69). Мондый категориядәге мөрәҗәгатьләр саны барлык мөрәҗәгатьләрнең 20%ын тәшкил итә (һәр бишенче мөрәҗәгать).

Мөрәҗәгатьләрне анализдаудан күренгәнчә, балаларны ата-ана хокуклары чикләнгән яисә ул хокуклардан мәхрүм ителгән гражданнар тарафыннан балаларны законсыз рәвештә гаиләдән алып китү һәм аларны җибәрмәү турындагы мөрәҗәгатьләр беркадәр кимеде. Андый очраклар 2018 елда 33 булды, ә 2017 елда – 36.

2018 елда ата-ана хокуклары чикләнгән яисә ул хокуклардан мәхрүм ителгән гражданнар тарафыннан балаларны үзләренә кире кайтаруда ярдәм итүне үтенеп язылган мөрәҗәгатьләр саны кимеде (2017 елда 11 булса, 2018 елда 8 булды). Шул ук вакытта ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүгә ярдәм итүне үтенеп язылганнары да кимеде (2017 елда 27 булса, 2018 елда 18гә җитте (33%ка кимеде). Мондый мөрәҗәгатьләрнең инициаторлары күпчелек очракта балаларның туганнары була.

Өченче урынны ***балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыру*** мәсьәләләре турындагы шикаятьләр били. Бу темага Вәкаләтле вәкилгә 426 мөрәҗәгать килде, бу барлык мөрәҗәгатьләрнең 20%ын тәшкил итә (2017 елда – 22,5%).

*24 нче диаграмма*

***2018 елда балаларның торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




*5 нче таблица*

***2017 – 2018 елларда балаларның торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы***

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (абс., бер.) |
|---|---|---|---|
| | 2017 ел | 2018 ел | |
| **Барлыгы** | **437** | **426** | -11 |
| Гаиләнең торак шартларын яхшырту мәсьәләләре | **110** | **109** | -1 |
| Торак мәсьәләләрен суд тәртибендә хәл итү | **70** | **87** | +17 |
| Күпбалалы гаиләләрне һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү | **55** | **76** | +21 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Гаиләләрне аврия хәлендәге торактан чыгару мәсьәләләре | **40** | **37** | -3 |
| Кредит йөкләмәләре буенча бурыч булуга бәйле рәвештә балаларны торактан чыгару, теркәүдән төшерү | **38** | **27** | -11 |
| Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү | **36** | **38** | +2 |
| Ата-анасы аерылышуга бәйле рәвештә баланы теркәүдән төшерү, торактан чыгару | **18** | **23** | +5 |
| Бу тематика буенча башка мөрәҗәгатьләр (шул исәптән торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү, торак төзү өчен җир бүлеп бирү мәсьәләләре буенча) | **70** | **29** | -41 |

Гаиләнең торак шартларын яхшырту мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле мөрәҗәгатьләр саны узган елгы дәрәҗәдә калды. 2018 елда торак мәсьәләләрен суд тәртибендә хәл итүгә бәйле мәсьәләләр 24%ка артты, барысы 87 мөрәҗәгать булды.

Шулай ук күпбалалы гаиләләрдән һәм инвалид балалары булган гаиләләрдән торак шартларын яхшырту мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьләр саны 38%ка артты (2017 елда 55 булса, 2018 елда – 76).

2018 елда җир кишәрлеге бирү мәсьәләсен хәл итү буенча җирле үзидарә органнарына, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү буенча идарәчел компанияләргә шикаятьләр саны ике мәртәбә кимеде.

Балаларның ***лаеклы тормыш дәрәҗәсенә*** хокукларын тәэмин итүгә бәйле проблемалар дүртенче урында тора, мондыйлар – 204 мөрәҗәгать (9,7%). Элеккечә үк шикаятьләрнең төп субъектлары – үз балаларына яшәү һәм тәрбия өчен кирәкле матди шартлар тудыру буенча ата-ана бурычларын тиешенчә үтәмәгән ата-аналар, бу мөрәҗәгатьләр, күбрәк, алимент йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәүгә кагыла. Мондый сораулар белән ел саен мөрәҗәгать итүче гражданнарның саны соңгы елларда гел бер чамада тора. 2018 елда мондый мәсьәләләр буенча 148 кеше мөрәҗәгать керде, бу әлеге темага кергән барлык мөрәҗәгатьләрнең 72,6%ын тәшкил итә, бу 2017 елга караганда 25%ка күбрәк (2017 елда – 118 яки 60,2%). Бу ата-аналарның алимент йөкләмәләрен үтәмәү проблемасының актуальлеге елдан-ел сакланып калуын күрсәтә һәм ул Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең игътибар үзәгендә тора.

Балаларны ***социаль тәэмин итү*** мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр бишенче урында тора. 2018 елда аларның саны 145 о булды яки 7%. Шулай да узган ел белән чагыштырганда аларрның саны 17гә артты. Узган ел йомгаклары буенча әлеге тематикага караган мөрәҗәгатьләр 128 иде. Бу күрсәткеч 13%ка артты.

Төрле социаль түләүләр мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең саны кимү икенче ел инде сакланып кала. Бу мәсьәләләр буенча 75 мөрәҗәгать булды, ул 2017 елга караганда 7гә кимеде һәм шушы темага гомуми мөрәҗәгатьләр санынннан 51,7 % тәшкил итә (2017 елда – 82 мөрәҗәгать иде).

Һәр бишенче мөрәҗәгать диярлек (29 мөрәҗәгать яки 19,8%) балаларны җәйге савыктыру лагерьларына юлламалар бирү мәсьәләләренә кагылышлы иде.

Инвалид балаларны шифаханә-курортта дәвалауга кагылышлы 10 мөрәҗәгать һәм заманча техник реабилитацияләү чаралары белән тәэмин итүгә кагылышлы 13 мөрәҗәгать булды, барлык мөрәҗәгатьләр санынннан икесе бергә 16% тәшкил итә.

***Балаларның сыйфатлы медицина хезмәтләренә хокукларын яклау*** мәсьәләләре буенча язылган мөрәҗәгатьләр алтынчы урында тора (146 мөрәҗәгать, ягъни 7%). Бу күрсәткеч 2017 елга караганда 34%ка күбрәк. Гражданнар үз мөрәҗәгатьләрендә,

элеккечә үк, ташламалы дарулар белән тәэмин итү, медицина ярдәме күрсәтүне оештыру, аңардан файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфаты мәсьәләләре турында язалар. Соңгы 5 елда бу мәсьәләләр буенча гражданнардан мөрәҗәгатьләрнең артуын исәпкә алып, 2018 елда «Балаларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру: мәсьәләләр, проблемалар, тәкъдимнәр» темасына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан “кайнар линия” телефонын эшләтү инициативасы белдерелде, ул 2018 елның маенда сәламәтлек саклау системасы белгечләре катнашында узды. «Кайнар линиягә» 57 мөрәҗәгать керде. Гражданнар үз мөрәҗәгатьләрендә медицина учреждениеләрендә балаларга күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатсыз булуы турында язалар һәм аерым белгечләрнең житешмәвенә зарланалар, дарулар белән тәэмин итү мәсьәләләрендә булышуны сорыйлар. Мөрәҗәгатьләрнең 19%ы Казан шәһәренең «Салават Купере» торак комплексында поликлиника төзү һәм аны файдалануга тапшыру мәсьәләләренә бәйле иде.


Гражданнар мөрәҗәгатьләре саны буенча җиденче урында б***аларны барлык төр көч куллануллардан һәм рәхимсезлекләрдән*** яклау мәсьәләләре булды. 2018 елда бу темага мөрәҗәгатьләр 2,6% (55 мөрәҗәгать) булды, 2017 елда бу күрсәткеч 4,4% (87 мөрәҗәгать булган иде). Бигрәк тә, 2017 елдагы кебек үк, күпчелек мөрәҗәгатьләрнең (54,6%) күбесендә гаиләдә балага карата көч куллану һәм аңа карата рәхимсезлек кылу гамәлләре (гаиләдә көч кулланулар) фактлары борчу уята. Моннан тыш, полиция, тикшерү органнарына карата да шикаятьләр керү дәвам итә, аларда, аерым алганда, җинаять эшләрен кузгатудан, гариза бирүче фикеренчә, нигезсез баш тартулар һәм процессуаль карарлар кабул итү яки процессуаль гамәлләр башкару сроклары бозылу турында сүз алып барыла.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрнең тематикалары буенча иң соңгы урында паспорт алганда, теркәү исәбенә басканда, гражданлыкны билгеләгәндә ***балигъ булмаганнарның гражданлык хокуклары бозылу*** турындагы мөрәҗәгатьләр тора. Хисап чоры дәвамында әлеге мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм сорап 17 кеше мөрәҗәгать итте (2017 елда – 16).

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән ***гражданнар категорияләренә килгәндә,*** гадәттәгечә, 2018 елда да балигъ булмаганнарның ата-аналарыннан килгән мөрәҗәгатьләр өстенлек итә – аларның саны 1 359 булды (68%) (2017 елда – 1342 яки 69,2%).

*25 нче диаграмма*

***2018 елда Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гражданнар категорияләре***



*6 нчы таблица*

***2016 – 2018 елларда Ввәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гражданнар категорияләре***

| Гражданнар категорияләре | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | |
|---|---|---|---|---|
| | Мөрәҗәгать итүчеләр саны | | | % |
| Ата-аналар | 1148 | **1342** | **1359** | **68** |
| Башка туганнар | 231 | **229** | **279** | **14** |
| Башка затлар (чит гражданнар, күршеләр һәм башкалар) | 140 | **164** | **141** | **7** |
| Опекуннар һәм попечительләр | 93 | **92** | **102** | **5,1** |
| Балигъ булмаганнар | 46 | **34** | **29** | **1,4** |
| Ижтимагый оешмалар вәкилләре | 20 | **30** | **28** | **1,4** |
| Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар | 24 | **25** | **31** | **1,6** |
| Балалар учреждениеләре житәкчеләре, хезмәткәрләре | 27 | **22** | **29** | **1,5** |

Балаларның туганнарыннан 279 мөрәҗәгать (14%) алынды, 2017 елдагыдан 2,2%ка күбрәк. Мөрәҗәгатьләрдә, нигездә, ата-аналарның үз вазыйфаларын намуссыз башкаруларына, балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм аларның хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының битарафлыгына, туганнары белән аралашуда бала хокуклары бозылуга зарланалар.

Мөрәҗәгать итүчеләрдән өченче урында – балалар язмышына битараф булмаган чит гражданнар. Гомуми мөрәҗәгатьләр саныннан аларның өлеше 7% тәшкил итә яки 141 мөрәҗәгать (2017 елда – 164 мөрәҗәгать).

Опекуннар (попечительләр), тәрбиягә бала алган ата-аналар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә 102 мөрәҗәгать юллаганнар, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 5 % тәшкил итә (2017 елда – 92 мөрәҗәгать). Аларда күтәрелгән төп темалар опека һәм попечительлек, аларның тәрбиясендәге балаларның торак хокукларын үтәү, алар тәрбиясендәге балаларның торак хокукларын үтәү мәсьәләләренә кагыла.

2018 елда балигъ булмаганнарның үзләреннән 29 мөрәҗәгать керде, бу барлык мөрәҗәгатьләрдән 1,4% тәшкил итә (2017 елда – 34 мөрәҗәгать).

2018 елда елда ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлардан килгән мөрәҗәгатьләр саны беркадәр артты (2017 елда – 25, 2018 елда – 31). Аларның барысы да диярлек торак алу яисә торак шартларын яхшырту хокукын яклауга кагылышлы иде

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә хезмәттәшлек итү, үзара мөнәсәбәтләр һәм балаларга ярдәм итү мәсьәләләре буенча ижтимагый оешмалар вәкилләреннән 28 мөрәҗәгать керде.

***Мөрәҗәгатьләрнең географиясенә килгәндә,*** шуны билгеләп китәргә кирәк, 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гариза бирүчеләрнең иң күп өлешен Татарстан Республикасында яшәүчеләр алып тора, алар тарафыннан 1 882 мөрәҗәгать җибәрелгән (94,2%), башка илләрдән һәм Россия Федерациясенең башка субъектларыннан – 48 граждан (2,4%). 68 граждан (3,4%) үзләренең яшәү урыннарын белә торып күрсәтмәгәннәр яисә онытканнар.


Республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча карасак, элеккечә, мөрәҗәгатьләрнең иң күп саны – 1 246 мөрәҗәгать (62,4%) – Казан шәһәре халкыннан алынды. Мөрәҗәгатьләр саны буенча икенче урында Чаллы шәһәрендә

яшәүчеләрдән килгән мөрәҗәгатьләр – (131 мөрәҗәгать яки 6,6%), өченче урында – Әлмәт районыннан килгән мөрәҗәгатьләр (94 мөрәҗәгать, ягъни 4,7%), дүртенчедә – Зеленодольск районы (51 мөрәҗәгать, ягъни 2,6%), бишенчедә – Түбән Кама районы (28 мөрәҗәгать, ягъни 1,4%), алтынчыда – Лаеш районы (18 мөрәҗәгать, ягъни 2,0%), җиденчедә – Түбән Кама районы (36 мөрәҗәгать, ягъни 1,0%).

Республиканың башка муниципаль районнарыннан кергән мөрәҗәгатьләр саны диаграммада күрсәтелде.

*26 нчы диаграмма*

***2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең республика муниципаль районнары буенча саны***





2018 елда шулай ук Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына турыдан-туры яисә төбәкләрдәге бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр аша Россиянең башка төбәкләреннән 49 мөрәҗәгать (гомуми мөрәҗәгатьләр саныннан 2,5%) керде: Ленинград, Ульяновск, Мәскәү, Төмән, Киров, Иркутск, Түбән Новгорд, Волгоград, Ростов, Саратов өлкәләреннән, Башкортостан Республикасыннан, Марий Эл Республикасыннан, Карелия Республикасыннан, Кырым Республикасыннан, Пермь краеннан, Ханты-Мансый – Югра автоном округыннан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Ростов-Дон шәһәрләреннән, 8 мөрәҗәгать – чит ил гражданнарыннан (Үзбәкстан, Украина, Португалия, Болгария, Мисыр (Египет), Греция).

***Мөрәҗәгатьләрнең төрләрен анализлаудан күренгәнчә,*** Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең 958е – шикаять, калган 1040ы – башка төр мөрәҗәгатьләр (мәгълүмат, аңлатмалар, консультацияләр бирү, ярдәм күрсәтү турында үтенечнамәләр). 2018 елда мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан шикаятьләр 52% тәшкил итә.

*27 нче диаграмма*


***2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрне төрләре буенча бүлү***



2018 елда 2017 елдагыга караганда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә консультацияләр бирү, гамәлдәге законнарның нормаларын аңлату һәм проблеманы яки каршылыклы очракны хәл итүдә ярдәм күрсәтү үтенече белән язылган мөрәҗәгатьләр ешрак булды (1040 мөрәҗәгать, ягъни 52%), шикаятьләргә бәйле мөрәҗәгатьләр 958 булды (алар 51дән 48гә төште).

*28 нче диаграмма*


***2014 – 2018 елларда шикаятьләр һәм башка мөрәҗәгатьләр өлешләренә чагыштырма анализ***




***Шикаятьләр бирү субъектлары*** буенча шикаятьләрне түбәндәгечә структуралаштырырга мөмкин.

*29 нчы диаграмма*

***2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән шикаятьләрнең шикаять бирелү субъектлары буенча бүлү***




2018 елда шикаять бирелү субъектларына барлык дәрәҗәдәге гавами хакимият органнары (федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары), суд органнары, төрле оешмаларның җитәкчеләре һәм гражданнар керә.

2018 ел йомгаклары буенча, 2017 елдагы кебек үк, төрле оешмаларның җитәкчеләренә һәм вазыйфаи затларына карата шикаятьләр өстенлек итә (30%).

Шикаять бирелү субъектлары арасында икенче урында, 2017 елдагы кебек үк, җирле үзидарә органнары тора. Шул ук вакытта, аларның саны 2,2%ка кимрәк (2018 елда – 231 шикаять яки 25,2%, 2017 елда – 267 шикаять яки 27%).

Өченче урында – гражданнар гамәлләренә карата шикаятьләр, 2018 елда шундый шикаятьләр 2,8%ка артты һәм аларның саны 172 булды, ягъни 18% (2017 елда – 150 шикаять, ягъни 15,2%).


Федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына карата шикаятьләр белән гражданнар 156 очракта (16,3%) мөрәҗәгать иттеләр. Бу күрсәткеч 2017 ел белән чагыштырганда 2%ка артты.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына карата 63 шикаять булды, ягъни 6,6%). 2017 елда – 72 шикаять, ягъни 7,2%.

Суд органнары карарлары белән канәгать булмаган 58 граждан (ягъни (5%) мөрәҗәгать итте.

*30 нчы диаграмма*

***2014 -2018 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә шикаять бирелү субъектлары буенча кергән шикаятьләр саны***




Бала хокуклары, гарантияләнгәндә генә түгел, ә гамәлгә ашырылганда һәм яклангананда аларның чын кыйммәткә әверелүен аңлап, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә баланың бозылган хокукларын торгызу, Татарстан Республикасы территориясендә балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре яклануын тәэмин итү бурычларын үтәү аерым урын алып тора.

Гомумән алганда, 2018 елда гражданнар шикаятьләрен карау нәтиҗәләре буенча 42% очракта бала хокукларын яклау ысуллары һәм чаралары турында квалификацияле консультацияләр һәм аңлатмалар бирелде. 58% очракта баланың бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуда ярдәм күрсәтелде, шул исәптән 287 очракта (51,7%) мәсьәләнең асылы буенча уңай хәл итүгә ирешелде.

Гражданнар шикаятьләре нәтиҗәләре буенча тиешле органнар һәм вазыйфаи затлар адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бала хокуклары бозылу турында 43 бәяләмәсе җибәрелде.

## 3.2. Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү

Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү хокукын үтәү торышын анализлау нигезенә статистика белешмәләре һәм республикада күрелә торган «баланы барлык рәвешле физик һәм психологик көч куллануднан, хурлаудан, кайгыртучанлык күрсәтмәүдән яисә саксызлык күрсәтүдән яклау максатында барлык кирәкле закон, административ, социаль һәм агарту чараларын...» өйрәнү нәтиҗәләре салынган.

### *3.2.1. Балаларның тышкы сәбәпләр аркасында үлүен анализлау*


Һәр баланың яшәү хокукын гарантияләү баланың яшәү мөмкинлеген тәэмин итү бурычларын дәүләт тарафыннан тиешенчә үтәүдән гыйбарәт (Бала хокуклары турында БМО Конвенциясенең 6 статьясы). Беренчедән, бу идарә ителә торган үлем очракларын киметү буенча профилактик чаралар күрү.

Шундый “идарә ителә торган үлем”гә балаларның тышкы сәбәпләрдән – бәхетсезлек очракларыннан, суицидлардан, белә торып кылынган җинаятьләрдән балалар үлгән очраклар керә. Әмма балалар үлеменең табигый булмаган сәбәпләрен кисәтеп тә яки алар белән идарә итеп тә була торган категориягә керә һәм тиешле дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, «балачак өлкәсендә» эшләүче төрле оешмалар мондый фаҗигаләрне кисәтү буенча профилактика эшен, массакүләм мәгълүмат чаралары, ата-аналар белән тыгыз элемтәдә торып, оешкан рәвештә тиешле дәрәҗәдә башкарсалар, бу югалтуларны юк дәрәҗәсенә киметергә мөмкин булыр иде.

Балалар үлеме структурасы анализында балаларның тышкы сәбәпләр аркасында вафат булу очраклары 2018 елда 20% тәшкил итте. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының оператив белешмәләренә караганда тышкы сәбәпләрдән балалар үлгән 74 факт теркәлгән, бу 2017 елга караганда 13%ка азрак һәм соңгы тугыз елда иң түбән күрсәткеч.

*32 нче диаграмма*


***2012 – 2018 елларда тышкы сәбәпләр аркасында һәлак булган балаларның гомуми саны (кеше)***




Тышкы сәбәпләрдән балалар үлемен анализлаудан күренгәнчә, гадәттәгечә, балигъ булмаган балаларның үлеме төрле ***бәхетсезлек очраклары*** нәтиҗәсендә килеп чыга.

*33 нче диаграмма*


***2015 – 2018 елларда тышкы сәбәпләр аркасында һәлак булган балалар саны (кеше)***




2018 елда бәхетсезлек очракларыннан 53 балигъ булмаган бала үлгән. Бу 2017 елга караганда 24%ка азрак. Соңгы еллардагы хәлләрне анализлаудан бәхетсезлек очракларыннан балалар үлеменең кимегәне күренә.

*34 нче диаграмма*


***2018 елда балаларның бәхетсезлек очракларыннан һәлак булу структурасы***




Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белешмәләре буенча 2018 елда төрле сулыкларда 7 бала ***батып*** булган.

*35 нче диаграмма*


***2013-2018 елларда сулыкларда үлгән балалар саны (кеше)***




2018 елда су объектларында үлгән балалар арасында ике бала 6 яшькә кадәр, дүрт – 7 яшьтән 13 яшькә кадәр, бер балигъ булмаган бала – 14 яшьтән 17 яшькә кадәр.

*36 нчы диаграмма*

***2013-2018 елларда су объектларында үлгән балалар саны (яшьләре буенча) (кеше)***




Узган елда елгаларда һәм күлләрдә үлем очраклары Казанда, Әгерже, Апас, Кукмара, Минзәлә, Менделеевск районнарында булды.

Сулыкларда үлүнең төп сәбәпләре балаларны үзләрен генә калдыру һәм сулыкларда хәвефсезлек кагыйдәләрен үтәмәү белән аңлатыла.

Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белешмәләре буенча, 2018 елда Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар катнашында 31 ***янгын очрагы*** була, шулардан 26 бала зыян күргән, 5есе – үлгән. Узган ел белән чагыштырганда янгыннарда һәлак булган балалар саны шул дәрәҗәдә калган. 2018 елда балалар үлеме очрагы белән барысы дүрт янгын булган – Минзәлә, Зеленодольск, Бөгелмә районнарында һәм Казан шәһәрендә.

*37 нче диаграмма*


***2014 – 2018 елларда янгыннарда һәлак булган балалар саны (кеше)***




Элеккечә, анализдан күренгәнчә, мәктәпкәчә яшьтәге балалар аеруча хәтәр төркемгә керә. Бу кече яшьтә булуга, килеп чыккан хәлне тиз генә аңлап, хәл итү юлын таба белмәүгә бәйле. Янгын нәтиҗәсендә үлүчеләр арасында 3 бала 6 яшькә кадәрге, 1 бала – 7 яшьтән 13 яшькә кадәрге, 1 бала – 14 яшьтән 17яшькә кадәрге категориягә керә.

*38 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда янгыннарда һәлак булган балалар саны (яшьләре буенча) кеше)***




2018 елда күпчелек янгыннар олылар гаебе белән булган (31 янгыннан 27се).

*7 нче таблица*

***2018 елда янгыннарның сәбәпләре***


| *Янгыннарның сәбәпләре* | *2018 ел* |
|---|---|
| *Олыларның ут белән саксыз булуы* | *14* |
| *Балаларның ут белән шаяруы* | *7* |
| *Электр җиһазларын урнаштыру һәм эшләтү кагыйдәләрен бозу* | *6* |
| *Көнкүреш газларыннан, керосинда, бензинда эшләүче җайланмалардан файдалану кагыйдәләрен бозу, шулай ук аларны шарталтуга китерерлек итеп файдалану* | *3* |
| *Житешреү җайланмаларының төзексезлеге* | *1* |
| *Белә торып мөлкәтне бозу (зарарлау), кеше гомеренә зарар китерү (ут төртү)* | - |
| *Тәмәке тартканда саксыз кылану* | - |
| *Башка сәбәпләр* | - |

Янгыннарны тикшерү нәтиҗәләрке буенгча, муниципаль районнарда балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре исеменә Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре тарафыннан 27 ата-ананы (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә (ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен) административ җаваплылыкка тарту турында материаллар җибәрелгән. Шулай да әлеге эшне житәрлек дип бәяләп булмый, чөнки янгыннар турында муниципаль комиссияләргә материаллар җибәрү янгыннарда балаларның фаҗигале һәлак булуына китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны карау һәм өйрәнү кебек мөһим бурычны башкаруга ярдәм итә. Балаларны тәрбияләүдә җаваплылыкны арттыру күзлегеннән ата-аналарга тәэсир итү механизмы буларак әлеге алымны куллану алга таба мондый фаҗигаләрне булдырмау һәм кисәтү, профилактика буларак каралырга тиеш.

Бәхетсезлек очраклары аркасында балаларның үлеменә китергән сәбәпләр структурасында ***юл-транспорт һәлакәтләрендә*** җәрәхәтләр алу аерым урын алып тора. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе (алга таба – ТР буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе) мәгълүматлары буенча, 2018 елда балигъ булмаганнар катнашында 694 юл-транспорт һәлакәте (ЮТҺ) теркәлгән, аларда 19 бала һәлак булган һәм 728 бала җәрәхәт алган.

*39 нчы диаграмма*

***2013-2018 елларда Татарстан Республикасында балалар катнашындагы ЮТҺ саны (кеше)***




2017 ел белән чагыштырганда балигъ булмаганнар катнашындагы ЮТҺ 1,6%ка кимрәк (2017 елда – 705 очрак, 2018 елда – 694 очрак).

ЮТҺ нәтиҗәсендә җәрәхәт алган балалар саны узган елга караганда 1,6%ка кимрәк (2017 елда – 740, 2018 елда – 728 ). Һәлак булган балалар саны узган ел дәрәҗәсендә диярлек – 2018 елда – 19 бала (2017 елда – 18 бала).

*40 нчы диаграмма*


***2013 – 2018 елларда ЮТҺендә һәлак булган һәм җәрәхәт алган балалар саны (кеше)***




Зыян күргән һәм һәлак булган балалар составын анализлау хәтәр төркемгә керә торган балалар турында берьяклы гына нәтиҗә бирми. Әмма җәрәхәт алган балалар арасында юл хәрәкәтендә мөстәкыйль (олылардан башка) катнашучы 7 яшьтән 13 яшькә кадәрге балалар (башлангыч сыйныф укучылары) күбрәк булуга игътибар итәргә кирәк.


*41 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда ЮТҺендә һәлак булган балалар саны (яшьләре буенча) (кеше)***




*42 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда ЮТҺ нәтиҗәсендә җәрәхәт алган балалар саны (яшьләре буенча) (кеше)***



ЮТҺ нәтиҗәсендә һәлак булучылар саны кимү Татарстан Республикасы муниципаль районнары җирле үзидарә органнарының нәтиҗәле эшчәнлеген күрсәтә, шуны исәпкә алып, муниципаль берәмлекләрдә балалар алган юл-хәрәкәт җәрәхәтен анализлау әһәмиятле булыр.

*8 нче таблица*

***2016 – 2018 елларда юл-транспорт һәлакәтендә һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән балалар саны (муниципаль берәмлекләрдә, кеше)***

| Муниципаль берәмлек (шәһәр округы) исеме | 2016 ел | | 2017 ел | | 2018 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәлак булган | җәрәхәтләнгән | һәлак булган | җәрәхәтләнгән | һәлак булган | җәрәхәтләнгән |
| Әгерҗе | 0 | 1 | 0 | 1 | 3 | 0 |
| Әлмәт | 0 | 36 | 1 | 27 | 3 | 28 |
| Зеленодольск | 1 | 18 | 0 | 18 | 3 | 15 |
| Казан шәһәре | 2 | 297 | 0 | 283 | 1 | 254 |
| Азнакай | 0 | 5 | 0 | 7 | 1 | 10 |
| Аксубай | 0 | 1 | 1 | 6 | 1 | 1 |
| Биектау | 0 | 5 | 0 | 5 | 1 | 8 |
| Алабуга | 0 | 17 | 0 | 25 | 1 | 19 |
| Мамадыш | 0 | 10 | 2 | 6 | 1 | 7 |
| Минзәлә | 0 | 5 | 0 | 4 | 1 | 5 |
| Түбән Кама | 0 | 68 | 1 | 66 | 1 | 74 |
| Питрәч | 2 | 17 | 0 | 18 | 1 | 17 |
| Тукай | 1 | 12 | 0 | 13 | 1 | 23 |
| Чаллы шәһәре | 1 | 159 | 1 | 113 | 0 | 116 |
| Бөгелмә | 0 | 20 | 1 | 17 | 0 | 24 |
| Чистай | 0 | 20 | 1 | 12 | 0 | 22 |
| Лаеш | 3 | 3 | 1 | 13 | 0 | 15 |
| Зәй | 2 | 9 | 4 | 8 | 0 | 11 |
| Лениногорск | 0 | 6 | 0 | 8 | 0 | 10 |
| Кукмара | 0 | 12 | 0 | 5 | 0 | 6 |
| Балык Бистәсе | 0 | 9 | 0 | 12 | 0 | 6 |
| Актаныш | 1 | 5 | 0 | 3 | 0 | 5 |
| Алексеевск | 0 | 4 | 0 | 2 | 0 | 5 |
| Чирмешән | 0 | 2 | 0 | 1 | 0 | 5 |
| Баулы | 0 | 1 | 1 | 1 | 0 | 4 |
| Сарман | 1 | 17 | 1 | 2 | 0 | 4 |
| Әлки | 1 | 2 | 0 | 1 | 0 | 3 |
| Арча | 1 | 8 | 0 | 9 | 0 | 3 |
| Балтач | 0 | 5 | 0 | 5 | 0 | 3 |
| Буа | 1 | 6 | 0 | 3 | 0 | 3 |
| Кайбыч | 0 | 0 | 0 | 2 | 0 | 3 |
| Тәтеш | 0 | 0 | 0 | 4 | 0 | 3 |
| Кама Тамагы | 0 | 0 | 0 | 3 | 0 | 2 |
| Апас | 0 | 0 | 0 | 3 | 0 | 2 |
| Яңа Чишмә | 0 | 4 | 1 | 3 | 0 | 2 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| *Нурлат* | *0* | *4* | *0* | *3* | *0* | *2* |
| *Теләче* | *1* | *2* | *1* | *10* | *0* | *2* |
| *Әтнә* | *0* | *2* | *0* | *3* | *0* | *1* |
| *Югары Ослан* | *0* | *6* | *1* | *5* | *0* | *1* |
| *Менделеевск* | *1* | *0* | *0* | *1* | *0* | *1* |
| *Мөслим* | *0* | *2* | *0* | *1* | *0* | *1* |
| *Саба* | *0* | *2* | *0* | *4* | *0* | *1* |
| *Ютазы* | *0* | *1* | *0* | *2* | *0* | *1* |
| *Спас* | *0* | *0* | *0* | *2* | *0* | *0* |
| *Чүпрәле* | *0* | *0* | *0* | *0* | *0* | *0* |

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе мәгълүматлары буенча, 2018 елда 177 ЮТҺ – бу балигъ булмаганнар катнашындагы ЮТҺләрнең гомуми санынннан 25% – балалар гаебе белән килеп чыккан. Шулай итеп, балалар гаебе белән килеп чыккан ЮТҺ саны соңгы өч ел дәрәҗәсендә калган диярлек, бу исә балаларга юлларда куркынычсызлык нигезләрен укыту методикасын камилләштерү, анда инновацион технологияләр кертү зарурлыгы турында сөйли.

Балалар гаебе белән килеп чыккан ЮТҺнең төп сәбәпләре түбәндәгеләр булды: тоткарланып торганнан соң кинәт юлга йөгереп чыгу (44 очрак), велосипедчылар, скутерчылар, мотоциклчыларның юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуы (33 очрак), транспорт якынлашканда, махсус билгеләнмәгән урында юлны аркылы чыгу (21 очрак), светофорның тыелып калу сигналына чыгу аркасында (16 очрак).

*9 нчы таблица*

***2014 – 2018 елларда балалар гаебе белән ЮТҺ сәбәпләре***

| ***ЮТҺ сәбәпләре*** | ***2014 ел*** | ***2015 ел*** | ***2016 ел*** | ***2017 ел*** | ***2018 ел*** |
|---|---|---|---|---|---|
| Велосипедчылар, скутерчылар, мотоциклчыларның юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуы | *53* | *31* | *29* | *33* | *33* |
| Тоткарланып торганнан соң кинәт юлга йөгереп чыгу | *40* | *34* | *38* | *31* | *44* |
| Транспорт якынлашканда, махсус билгеләнмәгән урында юлны аркылы чыгу | *26* | *68* | *66* | *18* | *21* |
| Светофорның тыю сигналына юлны аркылы чыгу | *7* | *6* | *8* | *15* | *16* |
| Балаларның юлга чыгып уйнавы | *6* | *1* | *5* | *0* | *1* |
| Автомобиль юлы буйлап хәрәкәт итү | *1* | *0* | *2* | *2* | *3* |
| Юл хәрәкәте кагыйдәләрен балаларның башкача бозуы | *20* | *11* | *5* | *50* | *59* |
| ***Барысы*** | ***153*** | ***151*** | ***153*** | ***149*** | ***177*** |


Олылар (транспорт йөртүчеләр) гаебе белән булган ЮТҺнең төп сәбәпләренә тизлек режимын сакламау, каршы хәрәкәт өчен билгеләнгән полосага чыгу, юл аша чыгу урыннарында җәяүлеләрнең өстенлекләре булса да, аларны уздырмау, транспорт чарасы белән исерек хәлдә идарә итү керә.

ЮТҺ китергән шартларны караганнан соң, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район (шәһәр) комиссияләре исеменә Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе хезмәткәрләре тарафыннан 375 ата-ананы (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә (ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен) административ җаваплылыкка тарту турында **материаллар җибәрелгән**.

2018 елда 3 бала ***егылып төшү*** аркасында үлгән, бу очраклар суицидка бәйле түгел. Болар – мәктәпкәчә яшьтәге һәм сабый балалар тәрәзәдән егылып төшү аркасында булган очраклар. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының оператив белешмәләренә караганда, 2018 елда ике мәктәпкәчә яшьтәге (5 яшьлек) бала тәрәзәдән егылып төшеп үлгән. 2017 елда мондый очрак 5 булган.

*43 нче диаграмма*

***2015-2018 елларда тәрәзәдән егылып төшеп үлгән балалар саны (кеше)***




Тәрәзәдән егылып төшү очраклары Казанда һәм Түбән Кама муниципаль районының Кама Аланы ш.т.п.ында теркәлгән.

*10 нчы таблица*

***2017 – 2018 елларда тәрәзәдән егылып төшеп үлгән балалар саны (муниципаль берәмлекләрдә, кеше)***

| ***Муниципаль район, шәһәр исеме*** | ***2017 ел*** | ***2018 ел*** |
|---|---|---|
| *Казан шәһәре* | ***2*** | *1* |
| *Түбән Кама* | *1* | *1* |
| *Бөгелмә* | *1* | *-* |
| *Әлмәт* | *1* | *-* |
| ***Барысы*** | ***5*** | ***2*** |

Шул ук вакытта, балаларның, тәрәзәдән егылып төшеп, җәрәхәт алган очраклары да бар.

Тәрәзәдән егылып төшү очракларыннан тыш, 2018 елда бер яшүсмер төзелеп бетмәгән бинадан егылып төшеп үлә, ул шунда башка балалар белән бер компаниядә булган.

2018 елда ун балигъ булмаган бала ***буылудан*** үлгән, бу суицид очракларына бәйле түгел (караватта очраклы рәвештә буылу, сулыш юлына чит әйбер китү, урамга чыккач, бер балигъ булмаган баланың өстенә кар төшә, бер бала кулдан ясалган таганда атынганда буыла).

Балаларның үлеменә китергән фаҗигале бәхетсезлек очракларының сәбәпләренә һәм шартларына ясалган анализдан күренгәнчә, әлеге очракларның күбесенең олыларның үз ата-ана вазыйфаларына җавапсыз караулары аркасында барлыкка килә.

Бәхетсезлек очраклары аркасында балаларның үлемен һәм җәрәхәтен профилактикалау максатында республикада бәхетсезлек очраклары аркасында балалар үлемен булдырмау һәм профилактикалау буенча өстәмә чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә кирәк дип саныйбыз, шул исәптән:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ның ЮХИДИ идарәсе, муниципаль районнар башлыклары белән берлектә янгыннарда, суда, юлларда, урманда, өйдә һәм башка вәзгыятьләрдә куркынычсызлык нигезләренә өйрәтү предметларына гомуми белем бирү оешмаларында һәм мәктәпкәчә балалар бакчаларында системалы нигездә өйрәтү һәм әзерләү дәресләре алып баруны тәэмин итәргә,   шулай ук балалар белән бәхетсезлек очракларын профилактикалау максатыннан һәм ата-аналарның җаваплылыгын арттыру йөзеннән ата-аналар җыелышлары үткәрергә;

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, муниципаль районнар башлыклары белән берлектә, мәктәпкәчә һәм башлангыч мәктәп яшендәге балаларны түләүсез яисә ташламалы нигездә йөзәргә өйрәтү мөмкинлекләрен киңәйтү мәсьәләсен карарга;

3. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән берлектә, тәрәзәдән егылып төшү нәтиҗәсендә яшь балаларның үлемен булдырмау буенча, башка илләрнең әлеге мәсьәләне хәл итү тәҗрибәсен өйрәнеп, чаралар эшләргә;

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына беренче звено балалар медицина учреждениеләре базасында (балалар поликлиникалары, фельдшерлык-акушерлык пунктлары, табиб амбулаторияләре һ.б.лар) әниләр (ата-аналар) арасында, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен җәлеп итеп, сабый балаларга табибка кадәр беренчел ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча агарту эшләре уздыруны тәэмин итәргә;

5. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә, муниципаль районнар башлыклары белән берлектә, төзелеп бетмәгән объектлар территориясендә һәм күпкатлы төзелешләр түбәсендә балаларның һәм яшүсмерләрнең булуын чикләп, иминлекне тәэмин итү чараларын күрергә;

6. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсенә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр исеменә суда балаларның фаҗигале үлеменә китерү торган сәбәпләрне һәм шартларны карау һәм өйрәнү буенча һәм ата-аналарны (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә административ җаваплылыкка тарту турында материаллар җибәрү эшен активлаштырырга;

7. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә балалар катнашында булган бәхетсезлек очраклары шартларын һәм сәбәпләрен ачыклау максатларында профилактика рәвешендәге системалы чаралар эшләү, шул исәптән ата-аналарны (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы буенча җаваплылыкка тарту өчен нигезләрне тикшерергә;

8. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, муниципаль берәмлекләр башлыклары белән берлектә, балигъ булмаганнарның мөмкин кадәр күбрәк мәшгульлеген тәэмин итәргә, шул исәптән каникуллар вакытында да аларны төрле дәрәҗәдәге өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча шөгыльләнүгә, ял итүгә җәлеп итәргә;

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына балалар катнашында булган бәхетсезлек очракларын, халыкта ата-ана җаваплылыгының

нинди урын алып торуын аңлый башлавына ирешү күзлегеннән чыгып, массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуда ярдәм итәргә.

Балалар үлеменең тышкы сәбәпләре арасында ***суицидлар*** бүген аерым урын алып тора.

2018 елда республикада балигъ булмаганнар арасында теркәлгән 17 суицид очрагы булды. Иң күп очрак – Казан һәм Әлмәт шәһәрләрендә (8 һәм 3 очрак). Бу хәлләр, аерым алганда, әлеге муниципаль берәмлекләрдәге балалар санына бәйле. Шул ук вакытта, без балалар суицидын булдырмаска тырышып эш итәргә тиеш, ә абсолют саннар бу муниципаль берәмлекләрдә суицид очракларын профилактикалау буенча җитәрлек эш башкарылмавын күрсәтә. Чаллы, Зеленодольск, Сарман, Спас, Биектау һәм Буа муниципаль районнарында берәр очрак теркәлгән.

Балигъ булмаганнар арасында үз-үзләренә кул салу очраклары: 10 очрак – асылыну, 7 очрак биектән сикерү булган.

Идел буе федераль округы субъектлары буенча (алга таба – ПФО) балигъ булмаганнар арасында суицидаль вәзгыять түбәндәгечә тасвирлана.

***11 нче таблица***

***2018 елда ПФО субъектлары буенча балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны***

| ПФО субъекты исеме | Балалар саны (мең кеше) | Балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны (кеше) | 10 мең балага суицидлар саны чагыштырмасы |
|---|---|---|---|
| Марий Эл Республикасы | 147,6 | 8 | 0,54 |
| Пермь крае | 585,8 | 23 | 0,39 |
| Удмуртия Республикасы | 340,0 | 13 | 0,38 |
| Башкортостан Республикасы | 904,3 | 31 | 0,34 |
| Оренбург өлкәсе | 443,9 | 15 | 0,34 |
| Чувашия Республикасы | 259,3 | 8 | 0,31 |
| Ульяновск өлкәсе | 226,2 | 5 | 0,22 |
| Саратов өлкәсе | 455,7 | 10 | 0,22 |
| Түбән Новгород өлкәсе | 593,0 | 13 | 0,22 |
| Пенза өлкәсе | 234,0 | 5 | 0,21 |
| Татарстан Республикасы | 826,9 | 17 | 0,20 |
| Самара өлкәсе | 605,9 | 10 | 0,17 |
| Киров өлкәсе | 248,2 | 4 | 0,16 |
| Мордовия Республикасы | 136,8 | 1 | 0,07 |

Яшүсмерләр арасындагы суицид проблемасының социаль портретын анализлаудан күренгәнчә, аның күбесе (17дән 16сы) 14-18 яшьлекләр тарафыннан кылынган. Иң яшь суицид корбанына нибары 13 яшь була.

***Җенси билгедән чыгып*** караганда, суицидантлар арасында ит-атлар күпчелекне тәшкил итә. Гадәттә, малайлар суицидларны кылалар, ә кызлар суицид кылырга омтылалар. 2017 елда суицид кылган 17 баладан 13е малайлар һәм 4 кыз булган.

***Яшәү урыны буенча*** караганда, суицидантлар арасында (шәһәр, авыл) шуны билгеләп үтәргә кирәк, 2018 елда 17 суицидның 14е (якынча 82 %) – шәһәр балалары тарафыннан, 3 (якынча 18%) авыл балалары тарафыннан кылынган.

Балаларның ***мәшгульлегеннән чыгып*** караганда, үлүчеләрнең барысы да укучылар булган: 12 бала мәктәптә укыган, 5 яшүсмер урта һөнәри белем бирү оешмасында укый торган булган.

Соңгы елларда конкрет шартларны өйрәнү шуны күрсәтә, суицид очраклары күпчелек очракларда гап-гади гаиләләрдә булган, шулай итеп, мондый хәлләр ***имин булмаган гаиләдә*** генә була дип әйтеп булмый.

2018 елда үлгән яшүсмерләрнең берсе дә суицидны ***алкоголь (наркотик) кулланган*** халәттә кылмаган, психикасында да кимчелекләр булмаган һәм тиешле исәптә дә тормаган.

Яшүсмерләр кылган барлык суицид очракларының ***сәбәпләрен*** ачыклау мөһим. аларның һәркайсы тирән фаҗига кичергән: эчке гаилә мөнәсәбәтләре, мәхәббәт кичерешләре һәм башка эчен кичерешләр. Биш суицид очрагының сәбәбе ачыкланмый калды. Нәтиҗә шул, һәр очракта да бала үзенең кичерешләре белән, «балалар кайгысы» белән берүзе кала, аның янында аңа ярдәм итәрлек, киңәш бирерлек кеше булмый. Бигрәк тә, гаиләдә, ата-аналар ягынна. Шуны әйтергә кирәк, узган елларда да суицид очракларының берсе дә «Интернет» челтәренең тискәре тәэсирендә булмаган.

Шулай итеп, суицидент-балигъ булмаганнарның социаль портретын анализлау, суицид кылуга омтылыш булудан чыгып, “хәтәр төркем” балаларын ачыкларга мөмкинлек бирми һәм шуңа күрә профилактик эш киң даирә балалар һәм яшүсмерләр арасында үткәрелергә тиеш.

Һәр суицид очрагы буенча Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе тарафыннан Россия Федерациясе җинаять кодексының 110 статьясы нигезендә («үзенә кул салуга җиткерү») җинаять эше ачыла, аның кысаларында булган эшнең бөтен фактлары ачыклана. 2018 елда 17 җинаять эше ачылды. Тикшерү практикасын гомумиләштерү ведомствоара профилактика эшен оештыруда аеруча мөһим.

Балалар арасында суицидны булдырмау һәм киметү күзлегеннән чыгып караганда, һәр ***суицидаль омтылышны*** өйрәнү шулай ук бик мөһим**.**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләреннән күренгәнчә, 2018 елда 64 суицидаль омтылышның балигъ булмаганнар арасында булуы теркәлгән. Аларның күпчелеге 16-18 яшьлек яшүсмерләр. Суицидаль омтылыш ясаган балаларның гомуми саныннан 81%ы кызларга туры килә. Балигъ булмаганнарның суицидаль омтылышларының төп алымнары – кан тамырын кисү һәм агулану.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, соңгы елларда республикада, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең күрсәтмәләрен истә тотып, тәмамланмаган суицидлар фактларын тикшерү буенчав системалы ведомствоара эш оештырып булды. Ведомстволарның – проблемалы балалар арасында профилактика субъектларының суицидларны кабатлау булмасын өчен чаралар күрү буенча үз вакытында һәм төгәл үзара эшчәнлек мөһим профилактика чарасы булып тора. Мәс., балигъ булмаганнарның 64 суицидаль омтылышыннан 53 очрак (83%) балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрдә тикшерелде. Төп бурыч – кабат суицид омтылышларны булдырмау, конкрет балага авыр тормыш хәленнән чыгарга ярдәм итү һәм гомумиләштерелгән практика нигезендә профилактик характердагы чаралар эшләү.

Шуны да танырга кирәк, республикада балигъ булмаганнарның суицидаль халәтен профилактикалау буенча системалы ведомствоара эшне күздә тота торган норматив документлар кабул ителде һәм алар гамәлгә ашырыла. Болар: “2018 – 2020 елларга балигъ булмаганнарның суицидаль халәтен профилактикалау буенча системалы комплек-

слы ведомствоара план”, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 29 декабрендәге 3757-р күрсәтмәсе белән расланды, “Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасына керүче органнар һәм учреждениеләр арасында үзара хезмәттәшлек итү һәм мәгълүмат алмашу тәртибе”, ул Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең 2015 елның 16 гыйнварындагы №01-15 карары белән (26.12.2017 № 18-17 карар белән кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган) расланды.

Шул ук вакытта, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне эшләргә кирәк дип саный:

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе һәм муниципаль комиссияләргә, балалар һәм гаиләләр иминлеген профилактикалау системасының башка органнарына үз карамагындагы һәм ведомствоара буйсынудагы игътибар, контроль һәм исәпкә алу зоналарындагы суицидаль хәтәр төркем балаларын профилактикалау буенча эшчәнлекне камилләштерү чараларын күрергә, әлеге мәсьәләне комиссия утырышында карарга;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына республика сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафынан территориаль хокук саклау органнарына суицидаль омтылышлардан зыян күргән балигъ булмаганнар турында вакытында һәм катгый рәвештә билгеләнгән тәртиптә хәбәр итүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында” 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законндагы 13 статьясының табибның пациент турындагы мәгълүматны тапшыруны чикли торган нормасын исәпкә алып, балигъ булмаганнарның кабат суицидка омтылуларын профилактикалау регламентын эшләргә һәм эшләнгән регламент нигезендә эшләүне оештырырга;

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә суицидка омтылыш ясаган балигъ булмаганнар белән һәм аларның гаиләләре белән индивидуаль реабилитацияләү эшен башкарылуны аерым контрольгә алуны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына республиканың мәгариф оешмаларында конфликтлы очракларны хәл итүнең профессиональ һәм нәтиҗәле алымнарын эшләү һәм куллану, мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләре тарафыннан укучыларга тәрбияви йогынты ясауның балаларны суицид кылуга этәрергә мөмкин рөхсәт ителмәгән алымнарын кулланууларын булдырмау буенча чаралар күрергә кирәк;

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә, түбәндәгеләр буенча эшләүне дәвам итәргә:

Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларын педагог-психолог һәм социаль педагоглар белән тәэмин итү;

профессиональ һәм нәтиҗәле методикалар эшләү һәм куллану;

мәгариф оешмаларында конфликтлы хәлләрне булдырмау хәл итү;

мәгариф оешмалары педагогик хезмәткәрләренең суицидаль хәтәр билгеләрне тану өлкәсендә, шундый хәтәрне җиңеп чыгу, бала белән уртак тел таба белү буенча компетенцияләрне арттыру;

балалар белән аларда стрессларга каршы торучанлык күнекмәләрен булдыру эшләре алып барырга, позитив һәм дуслык алымнары табу юлын күрсәтү;

суицидаль омтылыштан чыгып, хәтәр төркем балаларын ачыклау;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына хәтәр төркемдәге балаларга үз вакытында һәм тиешле дәрәҗәдәге психологик ярдәм күрсәтү максатларында психологик хезмәтләр белгечләренең һөнәри квалификация дәрәҗәсен камилләштерү һәм арттыру буенча чаралар күрергә;

Россия Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе җинаять кодексының 110 статьясы («Үз-үзен үтерүгә кадәр китерү») һәм 110.1 статьясы («Үз-үзеңне үтерүгә өндәү яисә үз-үзеңне үтерүгә булышлык итү»), 110.2 статьясы («Үз-үзеңне үтерүгә өндәүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне оештыру») буенча кузгатылган җинаять эшләре кысаларында төгәлләнгән суицидлар омтылышларның һәр факты буенча процессуаль тикшерүләр уздырырга;

күрсәтелгән эшләр буенча тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча балигъ булмаганнарның суицидаль халәтен кисәтү хакында тәкъдимнәр әзерләп, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе каравына кертергә;

Татарстан Республикасы Яшьләр министрлыгына, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникация агентлыгына Татарстан Республикасында балалар өчен “ышаныч телефоны” һәм “суицидаль хезмәт” телефоны эшләве турында мәгълүмат-реклама кампаниясен көчәйтергә;

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр министрлыгына, муниципаль мәгариф органнары һәм яшьләр эшләре органнары белән берлектә, балигъ булмаганнарга өстәмә белем бирүнең һәм аларның ялын оештыруның төрле рәвешләренә җәлеп итү эшләрен көчәйтергә.

Балалар үлеменең табигый булмаган сәбәпләренең берсе – ***аларга карата башкарылган җинаятьләр аркасында балаларның һәлак булуы***. Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ биргән мәгълүматлар буенча, 2018 елда 2 бала үлгән (Россия Федерациясе җинаять кодексының 105 статьясы) (алга таба – Россия Федерациясе ҖК) (2017 елда – 3 бала). Үз аналарының корбаннарына әверелгән яңа туган сабыйларның саны тотрыклы кала, РФ җинаять кодексының 106 статьясы буенча кузгатылган җинаять эшләре буенча – елына 2 бала. Саксызлык аркасында зыян китереп, 15 балигъ булмаган бала вафат булган (2017 елда -10) (РФ җинаять кодексының 109 статьясы).


### *3.2.2. Рәхимсезлектән һәм көч куллanудан яклану хокукын тәэмин итү*

Балаларга карата көч куллануны һәм рәхимсезлекне кисәтү мәсьәләләре эшчәнлекнең актуаль һәм өстенлекле юнәлеше булып тора.

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ биргән мәгълүматлар буенча, 2018 елда балаларга карата төрле характердагы 1 584 җинаять кылынган (балаларны тәрбияләп торуга акча бирүдән явыз ният белән качу фактлары буенча җинаятьләрдән тыш).

*44 нче диаграмма*

***2015 – 2018 елларда балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләр саны***




Диаграммадан күренгәнчә, балаларга карата кылынган җинаятьләр саны узган елга караганда беркадәр кимеде (7%ка ягъни 121 җинаятькә кимеде).

Җинаять эшләре буенча зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны, узган ел белән чагыштырганда, шулай ук кимеде кимрәк булды (4 %ка) һәм ул 780 кешене тәшкил итте.

*12 нче таблица*

***2017 – 2018 елларда җинаять эшләре буенча зыян күрүчеләр дип танылган балигъ булмаганнар саны***

| ***Җинаять төрләре*** | ***Зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны (кеше)*** | |
|---|---|---|
| | ***2017 ел*** | ***2018 ел*** |
| ***Зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны, шул исәптән*** | **812** | **780** |
| РФ ЖК ст. 105 (“Үтерү”) | 8 | 7 |
| РФ ЖК ст.106 (“Ананың яңа туган баласын үтерүе”) | 2 | 4 |
| РФ ЖК ст. 109 (“Саксызлык аркасында үлемгә китерү”) | 10 | 17 |
| РФ ЖК ст. 110 (“Үз-үзен үтерүгә җиткерү”) | 7 | 3 |
| РФ ЖК ст. 111 (“Аңлы рәвештә сәламәтлеккә зур зыян китерү”) | 8 | 12 |
| РФ ЖК ст. 112 (“Аңлы рәвештә сәламәтлеккә уртача авырлыктагы зыян китерү”) | 21 | 34 |
| РФ ЖК ст. 115 (“Аңлы рәвештә сәламәтлеккә җиңелчә зыян китерү”) | 51 | 30 |
| РФ ЖК ст. 116 (“Кыйнаулар”) | 24 | 10 |
| РФ ЖК ст. 117 (“Җәфалау”) | 30 | 45 |
| РФ ЖК ст. 119 (“Үтерү белән янау”) | 63 | 65 |
| РФ ЖК ст. 125 (“Куркыныч астында калдыру”) | 4 | 9 |
| РФ ЖК ст. 127 (“Законсыз рәвештә иректән мәхрүм итү”) | 5 | 11 |
| РФ ЖК ст. 131 (“Көчләү”) | 24 | 20 |
| РФ ЖК ст. 132 (“Сексуаль характердагы көч куллану гамәлләре”) | 82 | 72 |
| РФ ЖК ст. 133 (“Сексуаль характердагы гамәлләр кылуга мәҗбүр итү”) | 3 | 3 |
| РФ ЖК ст. 134 (“16 яше тулмаган зат белән җенси мөнәсәбәткә керү”) | 73 | 66 |
| РФ ЖК ст. 135 (“Бозыклык гамәлләре кылу”) | 45 | 25 |

| | | |
|---|---|---|
| РФ ҖК ст. 156 (“Балаларга карата рәхимсезлек кылу белән бәйле ата-аналар бурычларын үтәүдән баш тарткан өчен җинаятьләр”) | 71 | 64 |
| РФ ҖК ст. 150, 151, 151.1 (“Балигъ булмаган затны җинаять кылуга, җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү белән бәйле җинаятьләр”) | 49 | 9 |
| РФ ҖК ст. 240–242 (“Фәхишәлек белән шөгыльләнүне, порнография материалларын яисә предметларын законсыз эшләү һәм таратуны оештыру һәм шуңа җәлеп итү белән бәйле җинаятьләр”) | 6 | 9 |
| РФ ҖК ст. 158, 159, 161–163 (“Милеккә каршы җинаятьләр (караклык, мошенниклык, талау, юлбасарлык, куркытып алу”) | 193 | 265 |

Әлеге җинаятьләр буенча зыян күрүчеләр дип танылган балалар турындагы белешмәләргә ясалган анализ 2018 елда яшүсмерләргә карата кылынган хокуксыз җинаятьләрдән 64%ы яшүсмерләргә карата булуын, 36% – сабый балаларга карата, 42% – малайларга карат башкарылган булуын күрсәтте.

*45 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда балаларга карата кылынган җинаятьләр саны, яшь һәм җенес буенча***







***Балаларга карата көч кулланып башкарылган җинаятьләр дә*** борчу уята. Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ белешмәләреннән күренгәнчә, 2018 елда Балаларга карата кылынган җинаятьләр 1137 булган.

Көч кулланылган җинаятьләрнең корбаннары булган балигъ булмаганнар мониторингыннан күренгәнчә, 518 җинаять (балаларга карата көч кулланып кылынган җинаятьләрнең яртысы диярлек (46%) гаилә әгъзалары тарафыннан башкарылган, шул исәптән:

229 җинаять ата-аналар тарафыннан кылынган;


26 – аналары белән бергә яшәүче ир тарафыннан;

263 – гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан.

***Балигъ булмаганнарның җенси кагылгысызлыгына каршы башкарылган җинаятьләр*** дә шактый. 2018 елда 661 шундый җинаять теркәлгән. Мондый җинаятьләрнең күпчелеге купэпизодлы характерда

*46 нчы диаграмма*

***2014 – 2018 елларда Балигъ булмаганнарның җенси кагылгысызлыгына каршы башкарылган җинаятьләр һәм алардан зыян күрүчеләр саны***





Балигъ булмаганнарның җенси кагылгысызлыгына каршы башкарылган җинаятьләр 2018 елда узган елга караганда 18%ка кимеде һәм аларның саны 186га калды.

Шуны әйтергә кирәк, әлеге категориягә караган 204 (31 %) җинаять (Россия Федерациясе Җинаять кодексының 134 статьясы) 16 яшькә җитмәгән зат белән җенси мөнәсәбәткә керүгә бәйле. 66 яшүсмер зыян күрүче дип танылды. Бу эпизодлар аларның ризалыгы белән һәм мәҗбүр итмичә башкарылган. Шулай итеп, җенси кагылгысызлыкка каршы 457 очрак көч кулланып кылынган, шуннан 120 бала зыян күргән.

2018 елда 405 җинаять яшүсмерләрнең җенси кагылгысызлыгына каршы башкарылган, 261 – кече яштәге балаларның җенси кагылгысызлыгына каршы башкарылган. Җенси кагылгысызлыкка каршы башкарылган җинаять корбаннары күбрәк кызлар, аларга карата бу категория җинаятьләрнең 82%ы кылынган.

*47 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган җинаятьләр саны, яшь һәм җенес буенча***






Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ белешмәләреннән күренгәнчә, 2018 елда ***җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган җинаятьләрнең*** яртысы диярлек (48%) гаиләдә башкарылган (2017 елда – 36%, 2016 елда – 25%). Шундый җинаятьләрнең гомуми саны – 320 (2017 елда – 319), шул исәптән:

142 җинаять ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан кылынган;

18 – үги аталары һәм аналары белән бергә яшәүче ир-ат тарафыннан;

160 – гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне эшләргә кирәк дип саный:

Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасының Хөкүмәт комиссиясенә балаларга карата җинаять янауларын профилактикалау һәм көч куллану корбаннары булган балаларны яклау чаралары комплексын эшләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы идарәсенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасының Хөкүмәт комиссиясенә, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча балигъ булмаганнарга каршы җинаятьләрне кисәтү турында тәкъдимнәр бирергә, һәр ел йомгаклары буенча бу эшләр буенча тиешле анализ бирергә;

балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләр буенча тикшерү чараларын башкарганда тиешле органнарның – балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектларының балалар проблемаларын профилактикалау буенча үз вазыйфаи бурычларын тиешенчә башкару мәсьләсе буенча гамәлләренә (гамәл кылмауларына) хокукый бәя бирергә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына рәхимсезлек кылудан, көч куллануудан, җинаять янауларыннан зыян күргән балаларны социаль-психологик реабилитацияләүнең нәтиҗәле системасын булдыру, шул исәптән тиешле үзәк булдырку турындагы мәсьәләне карарга;

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика һәм муниципаль комиссияләргә, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы, Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм башка органнар – балигъ булмаганнар сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары белән берлектә:

имин булмаган гаиләләрдә, ата-аналарны алмаштыручы (опекуннарда, тәрбиягә бала алган) гаиләләрдә яшәүче, административ күзәтү астында торучы үги аталары белән бергә яшәүче, аналары белән бергә яшәүче ирләре булган гаиләләрдә, социаль приютларда һәм балалар йортларында яшәүче “хәтәр төркемгә” кергән балаларны ачыклауны оештыру буенча килештерелгән чаралар уздыруны тәэмин итәргә;

баланың куркыныч астында булуы турында теләсә нинди хәбәр яисә мәгълүмат алыну очрагына Татарстан Республикасының социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар турында бердәм белешмәләр банкын булдыру тәртибендә каралган сигнал карталарын катгый рәвештә булдыруны тәэмин итәргә,

көч куллану корбаннары булган балаларга квалификацияле ярдәм күрсәтүне һәм аларны реабилитацияләүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына ведомство балалар оешмаларында Россия Федерациясе хезмәт кодексының 331, 351.1 статьяларының балигъ булмаганнар катнашындагы педагогика эшчәнлегенә һәм башка хезмәт эшчзнлегенә хөкем ителүе булган затларны кертүне тыю турындагы таләпләренең үтәлешен тәэмин итәргә;

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, профилактикалау системасы субъектлары органнары белән берлектә, балаларга карата рәхимсезлек күрсәтүгә каршы тору, көч куллануны булдырмау турында, балага карата көч кулланган өчен җаваплылык турында, балаларның үзаңын үстерү, аларның абруен үстерү турында, балаларга һәм гаиләләргә ярдәм итүче социаль хезмәтләрнең һәм учреждениеләрнең эшчәнлеге турында массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуда ярдәм итәргә.

### *3.2.3. Тискәре мәгълүматтан яклау хокукын тәэмин итү*

Бүгенге гипермәгълүмат киңлеге шартларында балигъ булмаганнарга мәгълүматның тискәре йогынтысы арта бара, бигрәк тә балаларны хокукка каршы этәрә торган, суицидаль хәлләрне пропагандалалый торган хокукка каршы гамәлләр. Әлеге вәзгыять балаларны тискәре мәгълүмат агымыннан яклау хокукын тәэмин итү буенча чаралар күрүне таләп итә.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге предметы булып балаларның сәламәтлегенә һәм (яисә) физик, психик, рухи, әхлакый үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау өлкәсендә хокук бозу мәсьәләләре калды.

Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм (яисә) үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклауга бәйле мөнәсәбәтләр “Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында” 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 436-ФЗ номерлы Закон) белән җайга салына. Аның гамәли көче Россия Федерациясе территориясендә алда телгә алынган барлык чыганакларның продукцияләре әйләнеше өлкәсендәге мөнәсәбәтләргә кагыла.

Федераль закон нигезендә балаларны аларның сәламәтлегенә һәм (яисә) үсешенә зыян китерә торган мәгълүматка түбәндәге мәгълүмат керә:

1) балаларны аларның гомеренә һәм (яисә) сәламәтлегенә куркыныч яный торган, шул исәптән үз сәламәтлегенә зыян китерә торган, үз-үзен үтерүгә этәрә торган гамәлләргә җәлеп итә итүче гамәлләр кылуга китерә торган мәгълүмат;

2) балаларда наркотик чаралар, психотроп һәм (яисә) миңгерәткеч матдәләр, тәмәке әйберләре, алкогольле һәм спиртлы продукция кулланырга, комарлы уеннарда катнашырга, фахишәлек белән шөгыльләнергә, сукбайлыкта, теләнче булып йөрергә теләк уята торган мәгълүмат;

3) Федераль законда каралган очраклардан тыш, кешеләргә яисә хайваннарга карата рәхимсезлек күрсәтү һәм көч куллануны аклый торган мәгълүмат;

4) гаилә кыйммәтләрен кире кагып, гадәти булмаган сексуаль мөнәсәбәтләрне пропагандалый һәм ата-аналарга һәм (яисә) гаиләнең башка әгъзаларына ихтирамсызлык уята торган мәгълүмат;

5) законга каршы гамәлләрне аклый торган мәгълүмат;

6) сүгенү сүзләре булган мәгълүмат;

7) порнография чалымнары булган мәгълүмат;

8) законга каршы гамәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән балигъ булмаган бала турында, аның фамилиясен, исемен, атасының исемен, фотосурәтен, аның ата-аналарын, законлы вәкилләрен, туган көнен, аның тавышының аудиоязмасын, яшәү урынын яисә вакытлыча тору урынын, уку яисә эшләү урынын күрсәтеп бирелгән мәгълүмат яисә мондый балигъ булмаган баланы турыдан-туры яисә читләтеп булса да ачыкларга ярдәм итә торган мәгълүмат.

Билгеле бер яшьтәге категориядәге балалар арасында тарату чикләнгән мәгълүматка түбәндәгеләр керә:

1) рәхимсезлекне, физик һәм (яисә) психик көч куллануны, җинаятьне яки җәмгыятькә каршы башка гамәлләрне күрсәтә торган рәсемнәр һәм тасвирлаулар;

2) балаларны куркыта яки аларда паника уята торган мәгълүмат, шул исәптән көч кулланып үтерүдә кешене түбәнчелеккә төшереп күрсәтә торган рәсемнәр яки тасвирлаулар, авырулар, үз-үзеңне үтерү, бәхетсезлек очраклары, һәлакәтләр, афәтләр һәм (яисә) аларның нәтиҗәләре;

3) ир һәм хатын арасындагы җенси мөнәсәбәтләрне күрсәтә торган рәсемнәр яки тасвирлаулар;

4) тыелган сүгенү сүзләре һәм гыйбарәләр.

Шул ук вакытта, гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым игътибарына Ю.И.Ковальнең «Вода с закрытыми глазами» хикәясе эләкте, ул гомуми белем бирү мәктәпләренең 3 нче сыйныф укучылары өчен Н.А. Чуракованың «Литературное чтение» (“Әдәби уку”) уку әсбабында урнаштырылган, 1 өлеш (М.: Академкнига/Учебник, 2013. – 200 бит. – (Перспективалы башлангыч мәктәп).

Бу хикәядә “үләм” дигән сүзнең еш очравы игътибарны җәлеп итә, чөнки бу кечкенә балаларның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян салырлык тискәре йогынты ясарга мөмкин. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хикәя текстына эксперт тикшерүе уздырырга тәкъдим итте. Бу эксперт бәяләвен «Татарстан Республикасының мәгарифне үстерү институты» өстәмә белем бирү буенча дәүләт автоном белем бирү учреждениесе ясады. Эксперт бәяләмәсе бу текстта кече яшьтәге мәктәп балаларында үлем турында фикер тудырырга, хикәянең баш героинясына охшарга тырышу уятырга мөмкин дип күрсәтә.

Балаларны тискәре мәгълүмат агымыннан яклау хокукын тәэмин итү максатларында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкил А.Ю. Кузнецовага Ю.И.Ковальнең «Вода с закрытыми глазами» хикәясен гомуми белем бирү мәктәпләренең 3 нче сыйныф укучылары өчен Н.А. Чуракованың «Литературное чтение» (“Әдәби уку”) уку әсбабынннан төшереп калдыру үтенече белән Россия Федерациясе Мәгариф министры адресына мөрәҗәгать җибәрүне үтенде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил игътибарын 2018 елда шулай ук рус әдәбияты буенча Бөтенроссия олимпиадасының мәктәп этабында 10 нчы сыйныф укучыларына Алексей Слаповскийның «Скрипка Страдивари» хикәясе тикшерү өчен тәкъдим ителүе турындагы мәгълүмат җәлеп итте, ул хикәядә әдәпсез гыйбарәләр бар.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил фикере буенча, рус әдәбияты буенча Бөтенроссия олимпиадасының мәктәп этабында 10 нчы сыйныф укучылары өчен биремнәр әзерләгәндә һәм җибәргәндә Федераль закон белән тыелган, балаларга тискәре йогынты ясый торган мәгълүматка карый торган нормаларның бозылуы күренә. Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгының «Республика олимпиада

үзәге” ДАМУ (ГАОУ) директоры адресына законны бозу һәм аны төзәтү буенча чаралар күрү, шулай ук киләчәктә Федераль закон таләпләренең үтәлешенә контрольне көчәйтү; мәсьәләне караганда законнар таләпләрен бозуда гаепле затларны җаваплылыкка тарту һәм олимпиада биремнәрен төзегәндә шундый биремнәр сайлаган педагог-экспертны эштән азат итү турында бәяләмә җибәрелде. Моннан тыш, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 10-11 сыйныф укучылары өчен Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тәкъдим иткән Алексей Слаповскийның «Скрипка Страдивари» хикәясен әдәбият исемлегеннән төшереп калдыру турындагы тәкъдим белән Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгына мөрәҗәгать итү инициативасын белдерде.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең тикшерү предметына аның муниципаль районнарга визитлары кысаларында республиканың гомуми белем бирү оешмаларында мәгълүмат иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре керде. 10 муниципаль районның 11 гомуми белем бирү оешмасында интернет– ресурсларның контент фильтрациясе булмавы билгеләнде, бу балаларны мәгълүмат иминлеге белән тәэмин итү өлешендә контрольнең булмавын күрсәтә. Гамәлгә куючылар адресына ачыкланган хокук бозулар һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү турында тиешле бәяләмәләр җибәрелде.

Шул ук вакытта, балаларның иг иминлеге аспектының мөһимлеген исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмаларында мәгълүмат иминлеген оештыру һәм балалар оешмаларында контент фильтрация һәм антивирус яклавы мәсьәләләре Татарстан Республикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координация комитеты утырышында каралды, аның йомгаклары буенча тиешле системалы чаралар эшләнде һәм гамәлгә ашырырга тәкъдим ителде

2018 ел Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 апрелендәге 1739-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган “2017 – 2019 елларга медиакиңлектә балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планы («юл картасы»)” кысаларында республикада балаларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча системалы чаралар комплексын гамәлгә ашыруның икенче елы булды. “Юл картасын” гамәлгә ашыру барышын Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координация комитеты әгъзалары да карады.

Балаларны мәгълүмат иминлеге белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлекне көчәйтү максатларында, мәгълүмат–телекоммуникация ресурсларын һәм Hi-Tech – җайланмаларны кулланып, балигъ булмаганнарга карата әзерләнә, кылына, кылынган хокукка каршы гамәлләр өлешендә оператив әһәмиятле мәгълүмат белән алмашу өчен 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының «К» Бүлеге белән хезмәттәшлек итү турында беркетмә имзаланды. Әлеге хезмәттәшлек конкрет проблемалы вәзгыятьләрдә балаларның һәм яшүсмерләрнең иминлегенә бәйле вәзгыятьләрне (шул исәптән гражданнар мөрәҗәгате буенча) ел дәвамында оператив хәл итәргә ярдәм итте.

## 3.3. Баланың сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешкә хокукын тәэмин итү

2018 елда Татарстан Республикасының балалар сәламәтлеген саклау өлкәсен үстерү өлешендә шуны билгеләп үтәргә кирәк, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2017 елдагы нотыгында күрсәтелгән тәкъдимнәрнең күпчелеге Татарстан Республикасы Президентының 28.04.2018 №ПР-110 йөкләмәле иесмлеге кысаларында уңай хәл ителде һәм хупланды:

балаларга психиатрия ярдәме системасын камилләштерү максатларында «Акад. В.М.Бехтерев ис. Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе территориясендә махсуслаштырылган балалар үзәген төзүгә старт бирелде, аңа балалар өчен тәүлеклек һәм көндезге стационар, диспансер-поликлиника бүлекчәсе һәм сөйләм үзәге керә;

“Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе һәм “Татарстан Республикасы Инвестиция үсеше” Агентлыгының уртак эше нәтиҗәсендә балалар реабилитация үзәген төзүгә нигез салынды;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саул министрлыгы тарафыннан балаларга онкология һәм гематология ярдәме күрсәтү концепциясе эшләнде, ул “Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе территориясендә Балалар онкология, гематология һәм хирургия үзәген төзүне дә үз эченә ала. «Татарстан Республикасының балалар сәламәтлеген саклау» төбәк программасы проекты югарыда күрсәтелгән үзәкне төзүне финанслауны күздә тота: 2019 елга – 800,0 млн. сум, 2020 елга – 800,0 млн. сум;

өй шартларында үпкәләрнең ясалма вентиляциясен булдыруны тәэмин итә торган «өй стационары» технологиясе буенча балаларга паллиатив ярдәм күрсәтү системасы алга таба үсеш алды.

### *3.3.1. Балалар үлеменә гомуми анализ*


Балаларның сәламәтлек торышын характерлый торган күрсәткечләрнең берсе ***балалар үлеме*** дәрәҗәсе була.

Әлеге бүлектә балалар үлемен анализлау нигезен 2019 елның 1 мартына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан ясалган якынча (оператив) белешмәләр тәшкил итә.

2018 елда республикада балалар үлеме кимеде һәм 10000 балага 4,4 очракны тәшкил итте. Бу 2017 ел күрсәткеченә (5,26 очрак) һәм соңгы 10 елда иң түбән күрсәткеч. 2018 елда барлыгы 365 бала үлде, бу, 2017 ел белән чагыштырганда, 54 балага кимрәк.

*48 нче диаграмма*


***2009 – 2018 елларда Татарстан Республикасында балалар үлеме (кеше)***




Балалар үлеме структурасын анализлаудан күренгәнчә, аларның төп өлешен (60%лап) 1 яшькә кадәргә балалар, ягъни сабыйлар үлеме тәшкил итә.

*49 нчы диаграмма*

***2014 – 2018 елларда балалар үлеменең яшь буенча бүленеше (кеше)***




Соңгы биш елдагы балалар үлеме сәбәпләре түбәндәге таблицада бирелде.

*13 нче таблица*


***2014–2018 елларда балалар үлеменең сәбәпләре***

| Сәбәпләре | 2014 ел | | 2015 ел | | 2016 ел | | 2017 ел | | 2018 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | кеше | % | кеше | % | кеше | % | кеше | % | кеше | % |
| **Авыру** | **483** | 82 | **427** | 83 | **383** | 82 | **332** | 79 | **291** | 80 |
| **Тышкы сәбәпләр** | **108** | 18 | **86** | 17 | **85** | 18 | **87** | 21 | **74** | 20 |
| **Барысы** | **591** | | **513** | | **468** | | **419** | | **365** | |

Халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм җәмгыять иминлегенең торышын, сәламәтлек саклау системасының сыйфаты мәсьәләләрен дә кертеп, характерлый торган мөһим күрсәткечләрнең берсе – Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы стандарлары буенча – ***сабыйларның үлем дәрәҗәсе.*** Хисап чоры күрсәткечләре буенча, республикада соңгы елларда сабыйлар үлеме кимүнең уңай тенденциясе саклана, ул, 2017 ел белән чагыштырганда, 17 %ка кимеде: 1 яшькә кадәр 208 бала үлде, бу исән туган 1000 балага 4,47 очрак (2017 елда – 5,07).

*50 нче диаграмма*

***2014 –2018 елларда сабыйлар үлеме (бер яшькә кадәр)***




Сабыйларның 50%ы диярлек (1 яшькә кадәрге балалар) баштагы беренче атнада үләләр һәм иртә неонаталь үлемне тәшкил итәләр (50 нче диаграмма).

2018 елда ***перинаталь үлем*** очраклары – үле туган балалар һәм туганнан соң *(иртә неонаталь үлем)* 7 тәүлек булганчы үлгән балалар саны 2017 ел дәрәҗәсендә калды – 482 очрак.

*51 нче диаграмма*

***2014–2018 елларда Татарстан Республикасында перинаталь үлем***




Соңгы елларда перинаталь үлем дәрәҗәсе тотрыклы кала. Бу республикада күрелгән чараларның һәм кабул ителгән карарларның нәтиҗәсе булып тора. Шулай да, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының игътибарын сабый балаларга медицина ярдәме күрсәтүдә махсуслаша торган неонатологлар (тәэмин ителеш – 25,6% (123 белгеч), анестезиолог-реаниматологлар, шулай ук яңа туган балалар өчен реанимация койкалары җитешмәвенә юнәлтергә кирәк. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бала тудырту хезмәтләренең эшчәнлеген структура һәм кадрлар белән тәэмин итү ягыннан камилләштерү чараларын күрергә тиеш, дип саныйбыз.

### *3.3.2.Балалар сәламәтлеге торышына гомуми анализ*

Ел саен балаларга уздырыла торган ***профилактик тикшерүләр*** балалар сәламәтлеге торышын билгеләргә мөмкинлек бирә. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, мондый тикшерүләр нәтиҗәләре балаларның сәламәтлеге торышын түбәндәге төркемнәргә бүләргә ярдәм итте.

*52 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда балигъ булмаганнарның сәламәтлеге торышын төркемнәргә бүлү***



Гадәттә, медицина тикшерүе үткән балаларның гомуми саныннан күбесенең сәламәтлеге икенче төркемгә карый – 65,9%. Икенче урында – сәламәтлеге беренче төркемдәге балалар, өченче урында сәламәтлеге өченче төркемдәге балалар. Гомумән, соңгы елларда сәламәтлеге беренче төркемдәге балалар тартты.

***Балалар авыруларын анализлау*** балигъ булмаганнарның сәламәтлеге торышын бәяләүнең төп критерийларыннан берсе. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының оператив белешмәләре нигезендә соңгы биш елда балалар авыруларын динамикада анализлау түбәндәге таблицада бирелде.

***14 нче таблица***

***2014 – 2018 елларда балаларда беренче мәртәбә ачыкланган авырулар***

| 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2017 елга карата % | *Беренче мәртәбә ачыкланган авырулар* |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 93247 | 99007 | 100447 | 100937 | 105697 | +4,8% | Җәрәхәтләнүләр, агуланулар һәм тышкы сәбәпләрдән килгән кайбер башка зыяннар |
| 22780 | 25164 | 25865 | 24065 | 24128 | +0,26% | Нерв системасы авырулары |
| 2 778 | 3 129 | 3012 | 2 802 | 2 279 | -18,6% | Психик тайпылышлар |
| 100 | 100 | 107 | 128 | 113 | – 11,7% | Шешләр (Яман шеш авырулары) |
| 22 | 25 | 26 | 34 | 46 | +35,2% | Сирәк очрый торган (орфан) авырулар |
| 134 | 161 | 157 | 126 | 168 | +33% | Шикәр диабеты, I тип |
| 12 | 10 | 7 | 12 | 7 | -41,6% | Менингокок инфекциясе |
| 37 | 20 | 13 | 18 | 19 | +5,5% | Гонокок инфекциясе |
| 55 | 45 | 44 | 26 | 24 | -7,7% | Трихомоноз |
| 17 | 12 | 11 | 8 | 7 | -12,5% | Сифилис (барлык рәвешләре) |
| 13 | 23 | 14 | 10 | 9 | -10% | ВИЧ (барлык рәвешләре) |
| 67 | 84 | 75 | 46 | 40 | -13% | Кискен гепатит |
| 67 | 70 | 67 | 41 | 33 | -19,5% | Туберкулез (актив рәвеше) |
| 364 | 348 | 255 | 210 | 163 | -22,3% | Корчаңгы |
| 1140 | 1309 | 1207 | 901 | 1063 | +17% | Педикулез (бет) |
| 19 | 11 | 34 | 17 | 6 | -64% | Бактериаль дизентерия |

Республикада ел саен имгәнүләр, агуланулар һәм кайбер башка тышкы сәбәпләр аркасында 100 меңләп балалар авырган очраклар ачыклана. 2018 елда аларның саны 2017 елга караганда 4 760ка артты.

2018 елда нерв системасы белән авыручылар узган елгы дәрәҗәдә калды һәм ул 24 128 кеше тәшкил итте.

Балалар арасында психик тайпылышларның беркадәр кимүе күзәтелә (523 очракка). Шулай да, вәзгыять бик үк тынычланырлык түгел, авыручылар саны – 2 279 кеше.

Яман шеш авырулары белән авыручы балалар саны әзрәк – 15 балага – кимеде, 128дән 113 кеше калды.

2018 елда 46 балада балада сирәк очрый торган (орфан) авыруы ачыкланды, ә 168 балада беренче мәртәбә 1 типтагы шикәр авыруы барлыгы ачыкланды.


Социаль әһәмиятле авыруларда түбәндәге үзгәрешләр булды: корчаңгы авыруы белән авыручылар кимеде (47 кешегә), туберкулезның актив рәвеше белән – (8 кешегә кимеде), трихомоноз белән – (2 кешегә), сифилис белән – (1 кешегә), ВИЧ белән – (1 кешегә).

Балигъ булмаганнарның һәм яшүсмер кыз балаларның ***йөклелек очраклары*** аерым игътибар таләп итә. Статистика мәгълүматлары балигъ булмаганнар арасында йөклелек очракларының тотрыклы рәвештә кимүен күрсәтә. Мәсәлән, 2018 елда 2017 елдагыга ка-

раганда 25кә, ягъни 10 %ка кимегән, 2018 елгы күрсәткеч (216 кыз) соңгы еллардагы иң түбән күрсәткеч. 2011 ел белән чагыштырганда, йөккә узган кызларның саны өч тапкырга якын кимеде (2011 елда – 599 очрак, 2018 елда – 216).

*53 нче диаграмма*


***2011–2018 елларда балигъ булмаганнар арасында йөклелек статистикасы***




Ел саен балигъ булмаганнар арасында абортлар саны йөклелек очракларына параллель рәвештә кими. Шул ук вакытта, балигъ булмаганнарның йөклелек очракларының 30-40 %тан артыгы аны өзү (аборт) белән тәгәлләнә. 2018 елда 216 очракның 152сендә бала туу белән тәмамланган, 64 очракта – аборт белән. Абортлар өлеше – 29%, бу соңгы елларда иң түбән күрсәткеч (2017 елда – 39%, 2016 елда – 31%,), 2015 елда – 33%, 2014 елда – 32%).

*54 нче диаграмма*

***2014–2018 елларда балигъ булмаганнар арасында йөклелек һәм бала табу статистикасы***




Югарыда китерелгән анализның республикада балигъ булмаганнар арасындагы йөклелек очраклары һәм балаларның венерик авырулар белән авыру очраклары динамикасының уңай үзгәрешен раславын танырга кирәк. Шулай да балалар тормышында мондый хәлләр булмасын өчен без профилактика эшен дәвам итәргә тиеш. Профилактика эшенең бер варианты буларак, балалар арасында агарту эшләре алып бару нәтиҗәле булыр иде. Аны республиканың гомуми белем бирү учреждениеләрендә “Гаилә тормышы” дәресе кысаларында оештырырга мөмкин. Кызганычка каршы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, белем бирү учреждениеләренең әлеге эшчәнлек юнәлешендәге проблемалары, беренчедән, педагогларның әхлакый тәрбия, укучыларга женси белем бирү мәсьәләләрендә һөнәри

компетенцияләренең түбән дәрәҗәдә булуга, профилактика эшен оештыруда заманча интерактив технологияләрдән файдалана белмәвенә бәйле.

Балалар сәламәтлеге өлкәсендә социаль әһәмияткә ия тагын бер кискен проблема – ***балалар наркоманиясе һәм алкогольгә*** бәйлелек игътибар үзгендә калырга тиеш.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, нарколог ярдәменә мохтаҗ балалар саны 2018 елда 2017 елдагыга караганда 71 кешегә кимеде һәм 288 кеше тәшкил итә. Шул ук вакытта наркология ярдәме таләп ителә торган балаларның саны кимемәде, ул 69 % дәрәҗәсендә калды.

*15 таблица*

***2014 – 2018 елларда балигъ булмаганнарга наркология ярдәме күрсәтүнең торышы***

| Күрсәткеч | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Нарколог ярдәменә мохтаҗ балалар саны | 491 | 518 | 437 | 359 | 288 |
| Наркология хезмәте белән тәэмин ителгән балалар саны | 309 | 336 | 301 | 247 | 201 |
| Балигъ булмаганнарга наркология ярдәме күрсәтү оештырылган медицина оешмалары саны, шул исәптән: | 38 | 37 | 34 | 32 | 30 |
| амбулатор | 38 | 37 | 34 | 32 | 30 |
| стационар | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Балалар наркологлары (кеше/% тәэмин ителеш) | 26/57% | 23/51% | 21/46% | 21/46% | 24/52% |


Республикада балалар наркологлары белән тәэмин ителешнең 52% тәшкил итүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына балаларга нарколог хезмәте күрсәтү системасын тиешле дәрәҗәдә булдыру һәм тиешле кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсен карарга кирәк, дип саныйбыз

Балалар сәламәтлеге торышын билгели торган критерийларның берсе – ***балаларның инвалидлык дәрәҗәсе.***

Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе белешмәләренә караганда, 2019 елның 1 гыйнварына республикада 15 243 инвалид бала яши, бу барлык балаларның 1,8 %ы. 2016 ел белән чагыштырганда, бу шул дәрәҗәдә диярлек.

*55 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда Татарстан Республикасында инвалид балаларның гомуми саны***




Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының “Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча медик-социаль экспертиза баш бюросы” ФКУ (алга таба – Баш бюро) белешмәләре буенча, 2018 елда инвалидлык алу өчен 6 671 бала мөрәҗәгать иткән, бу, 2017 ел белән чагыштырганда, 3,5 %ка кимрәк (2017 елда – 6 912 бала). Шуларның 6 153е яисә 92 %ы инвалидлык алды (2014 елда – 91%, 2015 елда – 85%, 2016 елда – 86%, 2017 елда – 91,7%).

Баланы инвалид дип танудан баш тарту очраклары да кимеде. 2018 елда 518 очракта баш тарту булган, ягъни гомуми саннан 7,8 % ( 2014 елда – 9%, 2015 елдв – 15%, 2016 елда – 14%, 2017 елда – 8,3%).

*56 нчы диаграмма*

***2014 – 2018 елларда балаларга инвалидлык бирелү (бирелмәү) турында белешмәләр***





2018 елда “Инвалид бала” категориясе беренче мәртәбә тикшерү узган балага инвалидлык билгеләү 518 очракның 281ендә кире кагылган, 237 очракта – кабат мөрәҗәгать иткәндә кире кагыла.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, кабат тикшерү узган барлык 237 очракта да кире кагу тулысынча реабилитациялү белән аңлатыла (2014 елда – 398, 2015 елда – 770, 2016 елда – 540, 2017 елда – 235). 2018 елда мондый кире кагулар өлеше 46% тәшкил итә.

*57 нче диаграмма*

***2014–2018 елларда балалар инвалидлыгын билгеләүне кире кагу турында белешмәләр***





Баланы инвалид дип танудан баш тарту турында чыгарылган 518 карарның 207сенә (40%) югарырак инстанцияләргә – Баш бюрога яисә “Федераль медик-социаль экспертиза бюросы” федераль дәүләт бюджет учреждениесенә шикаять белдерелде. Моннан 193 очракта (93%) карар үзгәрешсез калган.

Инвалид дип танылган балаларның гомуми санынннан 1 850 балага (30%) «инвалид бала» категориясе беренче мәртәбә бирелгән, 4 303 балага (70%) – кабат тикшерү узган-

нан соң. Беренче мәртәбә тикшерү узганнан соң инвалид дип танылган балалар саны 2017 ел белән чагыштырганда 12%ка артты.

*58 нче диаграмма*

***2014–2018 елларда балалар инвалидлыгы күрсәткечләре***




Балалар беренче мәртәбә инвалидлык билгеләнү дәрәҗәсе 2018 елда 2%ка артты һәм ул 10 000 балага 22,3 бала булды. Кабат инвалидлык билгеләү дәрәҗәсе кимегән һәм ул 10 000 балага 52 бала тәшкил итә.

Югарыда китерелгән 2017 – 2018 елларга анализдан күренгәнчә, 2018 елда кимү түбәндәгечә булган:

тикшеренүгә җибәрелгән балалар саны (3,5%ка);

инвалид дип танылган балалар саны (2,9%ка);

инвалидлыгы кабат расланган балалар саны (8,3%ка).

инвалидлык бирү кире кагылган балалар саны (9,6%ка).

инвалидлык бирү кире кагылуга шикаятьләр саны (4,2%ка);

Шул вакытта арткан:

инвалидлыкны беренче тапкыр алган балалар саны арткан (12%ка);


Шуны билгеләп үтәргә кирәк, 2018 елда баланың инвалидлыгын танудан баш тарту медик-социаль экспертиза бюросы органнары карарлары белән килешмәү хакындагы мәсьәләләр буенча гомуми мөрәҗәгатьләр 10 булды. Барлык очраклар буенча, Медик-социаль экспертизасының баш бюросы һәм Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил арасындагы килешүгә таянып, Медик-социаль экспертизасының баш бюросы җитәкчесе Р.Х.Низамов адресына кабул ителгән карарларны яңадан карау һәм мөрәҗәгать итүчеләргә аңлатмалар бирү үтенече белән мөрәҗәгать җибәрелде.

Беренче мәртәбә инвалидлык бирү вәзгыяте аерым бәяләүне таләп итә.

Республика муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча беренче тапкыр инвалид дип танылган балалар саны түбәндәге диаграммада күрсәтелде.

*59 нчы диаграмма*

***2018 елда республика муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча балаларның беренче тапкыр инвалид дип танылу дәрәҗәсе (10000 балага)***




Бу күрсәтекеч уртача республика күрсәткеченнән түбәндәге районнарда югарырак: Балтач – (22,7), Питрәч – (22,8), Алабуга – (22,9), Мөслим – (24,1), Тштеш – (25,2), Биектау – (25,6), Әтнә – (25,6), Чүпрәле – (26,0), Актаныш – (26,2), Сарман – (26,4), Саба – (28,9), Лениногорск – (29,0), Арча – (30,9), Нурлат – (31,6), Менделеевск – (32,0), Мамадыш – (32,3), Югары Ослан – (34,0), Әгерҗе – (35,0), Кама Тамагы – (37,2), Чирмешән – (39,7) муниципаль районнарында һәм Чаллы шәһәрендә – (25,4).

Беренче тапкыр инвалид булып танылган балалар күрсәткечләре 2018 елда 2017 ел белән чагыштырганда кайбер районнарда кинәт кенә артып китте:

Югары Ослан районында (3,4тән 34,0 кадәр);

Кама Тамагы районында (14,4 до 37,2 кадәр);

Чирмешән районында (19,5тән 39,7 кадәр);

Тәтеш районында (12дән 25,2 кадәр);

Әтнә районында (16,5тән 25,6 кадәр);

Чүпрәле районында (13,3тән 26,0 кадәр);

Актаныш районында (13,6дан 26,2 кадәр);


Лениногорск районында (18,9дан 29,0 кадәр).

Балаларны беренче тапкыр инвалид дип тану күрсәткечләре Менделеевск районында (2017 елда – 27,5; 2018 елда – 32,0), Әгерже (2017 ел – 27,2; 2018 ел – 35,0) һәм Сарман (2017 ел – 27,2; 2018 ел – 26,4) муниципаль районнарында тотрыклы тора.

Беренче тапкыр инвалид булып танылган балалар яшь төркемнәре буенча түбәндәгечә бүленде.

*60 нчы диаграмма*

***2014 – 2018 елларда балаларны беренчел тикшерү белешмәләре (яшь категорияләре буенча)***




Югарыда китерелгән белешмәләр күрсәткәнчә, соңгы биш елда тикшерү нәтиҗәләре буенча инвалидлык беренче тапкыр билгеләнгән иң күп очрак 0дән 3 яшькә кадәр булган балалар арасына туры килә.

2018 елда балалар инвалидлыгының башлангыч сәбәбе булган авырулар структурасын анализлау түбәндәге диаграммада күрсәтелә.

*61 нче диаграмма*

***2018 елда балаларның беренчел инвалидлыгының авыру төрләре структурасы***




2014 – 2018 елларда балалар арасында авырулар класслар буенча беренче инвалидлык түбәндәге таблицада күрсәтелә.

*16 нчы таблица*

***2014 – 2018 елларда балаларның беренчел инвалидлык сәбәпләренең авырулар класслары буенча структурасы (кеше)***

| Сәбәпләр | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Психика какшау һәм үз-үзен таркау тоту | 440 | 445 | 471 | 439 | 550 |
| Нерв системасы авырулары | 356 | 350 | 312 | 324 | 316 |
| Тумыштан килгән аномалияләр (үсештәге кимчелекләр), деформацияләр һәм хромосомаларның бозылуы | 475 | 335 | 198 | 276 | 267 |
| Эндокрин система авырулары, туклану һәм матдәләр алмашы бозылу | 163 | 149 | 167 | 146 | 201 |
| Шешләр | 93 | 84 | 83 | 94 | 97 |
| Күз һәм күрү аппараты авырулары | 81 | 82 | 71 | 71 | 78 |
| Колак авырулары | 55 | 65 | 69 | 65 | 69 |
| Сөяк-мускул һәм тоташтыргыч тукымалар авырулары | 107 | 72 | 53 | 82 | 86 |
| Сидек юллары һәм җенес органнары авырулары | 36 | 26 | 26 | 13 | 21 |
| Җәрәхәтләр, агуланулар һәм башка тышкы сәбәпләр | 31 | 19 | 25 | 20 | 18 |
| Перинаталь чорда барлыкка килә торган авырулар | 20 | 23 | 16 | 29 | 33 |
| Кан ясау системасы авырулары | 17 | 16 | 15 | 17 | 27 |
| Ашказаны органнары авырулары | 19 | 18 | 12 | 18 | 25 |
| Сулыш органнары авырулары | 23 | 13 | 8 | 6 | 9 |
| Туберкулез | 1 | 1 | 2 | 0 | 0 |
| **Барлыгы** | **1982** | **1754** | **1567** | **1642** | **1 850** |

2015 елдан башлап балаларның инвалидлык структурасында беренче урынны психик яктан какшау һәм үз-үзен таркау тоту алып тора. Гомуми структурада бу чорда аларның өлеше 30% тәшкил итә. 2018 елда бу класс буенча 550 кеше инвалид булып таныла, 2017 елда 439 кеше иде (11 кешегә артыграк).

Икенче урынны элеккге еллар кебек нерв системасы авырулары алып тора, бу юнәлештәге интенсивлык күрсәткече гомуми структурада 17%. тәшкил итә. Әлеге класс буенча инвалид дип танылган балалар саны узган еллар дәрәҗәсендә дирлек калды (2016 елда – 312 кеше, 2017 елда – 324 кеше).

Өченче урыннны тумыштан килгән аномалияләр (үсештәге кимчелекләр), деформацияләр һәм хромосомаларның бозылуы били. Гомуми структурада аларның өлеше 14% тәшкил итә. Шулай ук әлеге сәбәпләр аркасында беренче тапкыр инвалидлык алган очракларның шактый артуы ***балалар үсешен пренаталь (бала тудырганчыга кадәр) диагностикалу һәм неонаталь скрининг буенча өстәмә чаралар күрүне*** таләп итә.

Дүртенче урында эндокрин система авырулары, матдәләр алмашы, ашказаны авырулары буенча инвалидлык бирү очракларының 2017 елга караганда артуын билгеләп китәргә кирәк.

Шулай итеп, республикада 2018 елда балалар авыруларын һәм инвалидлыгын анализлап, якын киләчәктә Татарстан Республикасы балалар сәламәтлеген саклау системасын үстерүдә төп бурычлар түбәндәгеләр кала:

балаларның тышкы сәбәпләр аркасында килеп чыга торган авыруларын профилактикалау буенча нәтиҗәле чаралар эшләү һәм кабул итү;

балаларны медицина тернәкләндерүе системасын үстерү, шул исәптән балалар тернәкләндерү үзәген эшләүне дәвам итү;

балаларга психиатрия ярдәме күрсәтү системасын үстерү;

балаларга наркология ярдәме күрсәтү системасын үстерү;

балалар үсешен пренаталь (бала тудырганчыга кадәр) диагностикалу һәм неонаталь скрининг буенча өстәмә чаралар эшләү;

балалар инвалидлылыгының сәбәпләрен анализлау.

### *3.3.3. Балаларның сәламәтлеккә хокукларын тәэмин итүнең проблемалы аерым мәсьәләләре*

Сәламәтлек саклау мәсьәләләре гражданнардан кергән барлык мөрәҗәгатьләр өлешендә бик аз (2018 елда – 7%, 2017 елда – 5,6%) булса да, аларны карау Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым контролендә тора.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил году ***Татарстан Республикасында балаларга сурдология ярдәменең торышын тикшерде.*** Кохлеар имплантациясен кичергән бер бала анасының мөрәҗәгать итүе моңа сәбәп булды.

Әлеге мәсьәләне тикшерү барышында Татарстан Республикасында балаларга сурдология ярдәме күрсәтү түбәндәге норматив хокукый актларга нигезләнеп башкарылуы билгеләнде:

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Сурдология–оториноларингология профиле буенча халыкка медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 09.04.2015 № 178н боерыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Сурдология–оториноларингология профиле буенча халыкка медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турында» 14.10.2015 № 2136 боерыгы.

«Сурдология–оториноларингология профиле буенча махсуслаштырылган медицина-санитарная ярдәме “Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 нче консультация поликлиникасында сурдология бүлегендә һәм «Ишетүне реабилитацияләү үзәге» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе базасында (Чаллы шәһәре) күрсәтелә.

Шулай да, кохлеар имплантациясе кичерүгә бәйле балаларга реабилитация хезмәтләре күрсәтүдә җитешсезлекләр бар әле.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, сурдолог–оториноларинголог табибында 319 бала диспансер исәбендә тора, аларның барысына да кохлеар имплантациясе куелган. Имплантны операциядән соң план буенча даими көйләү һәм реабилитацияләү федераль үзәкләр базасында операция ясалган урында һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Ишетүне реабилитацияләү үзәге» Федераль дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе базасында юллама буенча башкарыла. Әмма бүген бу гражданнар өчен аерым кыенлыклар тудыра.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына кохлеар имплантациядән соң балаларны реабилитацияләүне оештыру буенча 2018 елда түбәндәге оешмалар базасында башланган эшне ахырына җиткерү зарурлыгына игътибар итәргә кушты: “Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Е.Г.Ласточкина ис. Казан

интернат-мәктәбе” дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе базасында, «Ишетми торган инвалид балаларга «ГоворУши» ярдәм итү үзәге” АНО (Казан шәһәре) йә мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен гамәлдәге дәүләт реабилитация үзәкләре.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына ***инвалид балаларны дарулар белән тәэмин итү*** мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр килү дәвам итте.

Бер төркем мөрәҗәгатьләрдә инвалид балаларга аерым төр дарулар алу проблемасы чагылдырылган иде. Мондый мөрәҗәгатьләр буенча тикшерү нәтиҗәләре нинди дә булса хокук бозуларның булмавын күрсәтте, чөнки Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан бирелә торган препаратларда балаларга кирәкле матдәләр бар һәм алар билгеләнгән тәртиптә алынган. Ата-аналар үзебездә җитештерелгән дарулардан канәгать түгел иде. Кайбер мондый мөрәҗәгатьләр хәйриячеләр акчаларына хәл ителде.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гомер озынлыгына тәэсир итә торган яисә инвалидлыкка китерә торган ***сирәк (орфан) авыруыннан*** – интегүче балаларның ата-аналары мөрәҗәгать итте.

2018 елда сирәк (орфан) авыруыннан интегүче балаларны дарулар белән тәэмин итү буенча йөкләмәләрне үтәү законнар нигезендә җайга салына. Мәс «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль закон белән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына гражданнарны дарулар белән тәэһмин итүгә бәйле оештыру-идарә вәкаләтләре бирелде, шулай ук бюджеттан финанслау буенча финанс бурычлары йөкләнде. Шул ук вакытта, сирәк (орфан) авырулары (гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, яман шеш авырулары, кан, тукымалар авырулары, таралган склероз авырулары белән авыручы затларны, органнарны һәм (яисә) тукымаларны трансплантацияләгән затларны дару препаратлары белән тәэмин итүне оештыру федераль үзәккә йөкләнгән. 2018 елда дәвалау өчен препаратлары өчен федераль бюджет исәбенә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан сатып алына торган сирәк (орфан) авырулары исемлеге чыгымнарны тагын да күбрәк таләп итә торган биш исемгә тулылындырылды, бу авырулар: гемолитико-уремический синдром, системалы башлангыч белән яшүсмерләр артриты (юношеский артрит с системным началом), I, II һәм VI типлардагы мукополисахаридоз (Федераль закон, 3 август, 2018 ел № 299-ФЗ). Бу үзгәрешләр 2019 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керде.

Югарыда бәян ителгәннәргә карамастан, башка сирәк (орфан) авыруларыннан интегүче затларны дару препаратлары белән тэмин итү буенча Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына финанс йөкләнеше шактый. Мәс., Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2018 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчалары 137 бала дарулар белән тәэмин ителде, 86 бала – махсус ашамлыклар белән. 2018 елда сирәк авырулар белән авыручы балалар өчен дарулар алуга бүленгән бюджет ассигнованиеләре 127, 86 млн. сум булды. Әмма, дарулар белән тәэмин итү хакы югары булганга күрә, бу финанслау күләме җитәрлек түгел.

Шуны истә тотып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, сирәк (орфан) авырулардан интегүче балаларны дарулар белән, шул исәптән федераль бюджет ассигнованиеләре исәбеннән дәвалауны адреслы финанслауны оештыру аша киңәйтү исәбенә тәэмин итү максатында, Россиянең барлык төбәкләре өчен гомуми принципиаль чишелешләрне хәл итү буенча федераль үзәк белән эшләүне дәвам итәргә кирәк, дип саный.

Балалар сәламәтлеген саклау күзлегеннән караганда***, балаларга профилактик вакцина ясау һәм туберкулез диагностикасы уздыру*** бик мөһим.

Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белешмәләре нигезендә, 2018 ел йомгаклары буенча профилактика вакцинасыннан 58 571 очракта ата-аналар баш тарткан.

*17 таблица*

***2018 елда балаларга профилактик вакцина ясаудан баш тарту статистикасы***

| **Профилактик вакцина** | | **Баш тартулар саны** | **Яңадан каралганнар саны** |
|---|---|---|---|
| Профилактик вакцина, шул исәптән: | Бума ютәл | 5586 | 2193 |
| | полиомиелит | 8933 | 2891 |
| | кызамык | 10055 | 2873 |
| | Эпидемиологик паротит | 9589 | 2810 |
| | В гепатиты вирусы | 12542 | 3394 |
| **Барысы** | | **58571** | **17861** |

30% яисә 17 861 җаш тарту очрагы кабат каралган.

Профилактик вакцина ясауга каршы чыгу йогышлы авырулар артуның төп сәбәпләреннән берсе. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белешмәләреннән күренгәчә, 2018 елның ноябрендә Лаеш районының Сокуры авылында эпидемик паротит белән авырган 5 очрак теркәлгән, шул исәптән ата-аналары баш барту аркасында прививка ясатылмаган өч мәктәп баласы.


2018 елның октябрь – сентябрендә Чаллы шәһәрендә кызамык авыруына бәйле вәзгыять тә массакүләм мәгълүмат чараларында киң шау-шу куптарды. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белешмәләреннән күренгәчә, 10 бала авырган, аларның дүртесе генә прививка яшенә җитмәгән булган. Барлык авырган балаларга да ата-аналары баш барту аркасында прививка ясатылмаган була.

Бүгенге көндә ***туберкулез*** авыруы социаль куркыныч авыруларның берсе, аны профилактикалау авыруны кисәтүдә зур әһәмияткә ия. Туберкулездан профилатикалауга каршы чыгу да борчу уята. Туберкулез йоктыру куркынычын бәяләп бетермәү көтелмәгән нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Туберкулин диагностикасы ясалмаган бала чирнең башлангыч стадияләрдә табылуына һәм үз вакытында күрсәтелгән медицина ярдәменә өметләнә алмый, димәк, башка балалар өчен авыру йоктыру куркынычы туа.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләренә караганда, 2018 елда балалар арасында актив формада табылган туберкулез белән авыручылар 33 очрак булган (2017 елда – 41 очрак).

*62 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда балалар арасында туберкулез авыруы беренче тапкыр табылган очраклар (кеше)***



Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2018 елда туберкулезны диагностикалау вакцинасыннан 902 баш тарту очрагы булган.

Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белешмәләреннән күренгәчә, 2018 елда балаларга вакцина ясаудан һәм туберкулин диагностикасыннан баш тарту 9 158 очракта булган. Ата-аналары баш тарткан балаларның 51%ы (4647 кеше) альтернатив ысуллар белән (T-spot, квантифероновый тест, рентгенография, диаскинтест) тикшерелде. Балаларның 49%ы (4511 кеше) тикшерелмәгән килеш калды, бу барлык балалар саныннан 0,6% тәшкил итә.

Тикшерелмәгәннәр арасыннан 70 %ы (3154 бала) – тәртипсез балалар, 30% (1357 бала) – белем бирү оешмаларында укучылар (мәктәпләрдә – 1009 бала, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында – 344 бала, һөнәри белем бирү оешмаларында – 4 кеше).

Шуны әйтергә кирәк, туберкулезга тикшерелмәгән мәктәпкәчә яшьтәге балаларның күпчелеге шәхси балалар оешмаларына йөриләр. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белешмәләреннән күренгәчә, 2018 елның ноябрендә шәхси мәктәпкәчә оешмаларны күчмә тикшерү кысаларында «БИБИГОН» мәктәпкәчә яшьтәге балаларны үстерү үзәге тикшерелде, анда 51 баланың 21ендә (41%) туберкулезга тикшерү уздырылмаган.

Кайбер районнарда туберкулезга тикшерелмәгән балалар саны республика күрсәткечләреннән югарырак, мәс., (барлык балаларның 0,56%): Алабуга – (2,5%), Кукмара – (1,1%), Мөслим – (0,97%), Аксубай – (0,86%), Менделеевск – (0,7%), Түбән КАма – 0,9%), Нурлат – (0,6%), Баулы – (0,7%), Зеленодольск – (0,77%) муниципаль районнары, Казан шәһәре – (0,67%).

Туберкулезга каршы профилактик чаралардан баш тартуны урыннарда кабат карау эше Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе тарафыннан уздырылган анализ буенча болайрак тора. 2018 елның 1 октябренә профилактика вакцинасынннан баш тарту сәбәпләре түбәндәгечә бүленде: 53,3% яисә 1536 очрак – “диами баш тартучылар”, 24,3% яисә 699 очрак – «бер мәртәбә баш тартучылар», 22,3 % яисә 644 очрак – «дини инанулар буенча баш тартучылар». Күпчелек очракта профилактик вакцина ясаудан һәм туберкулин диагностикасыннан баш тартуының сәбәбе булып, кагыйдә буларак, баланың әлеге гамәлләрдән соң өзлегеп китүеннән курку тора. Ләкин, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләрен караганда, балаларда профилактик вакциналардан соң өзлегүләр бик сирәк очрый.

Баш тартулар проблемасы балаларның сәламәтлек саклауга һәм белем алуга хокукларын тәэмин итү ягыннан җитди әһәмияткә ия. Ата-аналарның профилактик вакцина ясаудан һәм туберкулин диагностикасыннан баш тартуы баланың белем алу хокукын гамәлгә ашыруга турыдан-туры йогынты ясый, чөнки бу гамәл аркасында бала мәгариф учреждениеләренә кертелмәскә мөмкин. Әмма Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бу хактагы дәлилләнгән хокукый позициясе адагы елларда бәян ителгәнчә, үзгәрешсез кала: профилактик вакцина ясау һәм туберкулин диагностикасы, беренче чиратта, баланың сәламәтлеген саклауга хокукын тәэмин итүгә юнәлдерелгән, ата-аналарның профилактик чаралардан баш тартуы принципиаль рәвештә баланың белем алуга хокукын чикләү өчен сәбәп була алмый.

Балалар арасында йогышлы авыруларны профилактикалау максатларында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсенә, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә бергәләп, профилактик вакцина ясауның

һәм туберкулин диагностикасы үткәрүнең максатка ярашлы һәм зарури булуы турында балаларның законлы вәкилләре белән агарту, аңлату һәм профилактик эш алып баруны дәвам итәргә тәкъдим итә.

Балалар сәламәтлеген саклауның торышында мөһим күрсәткечләрнең берсе – балаларга медицина ярдәме күрсәтү өлкәсендә ***белгечләр белән тәэмин ителеш*** мәсьәләсе.

Аларны өйрәнү һәм анализлау Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә аерым урын алып тора. Анализдан күренгәчә, аеруча педиатрлар, балалар психотерапевтлары һәм психиатрлары, неонатологлар, наркологлар җитешми. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре түбәндәге таблицада китерелә.

*18 нче таблица*

***Балаларга медицина ярдәме күрсәтү өлкәсендә белгечләр белән тәэмин ителешнең торышы (кеше, %)***

| Белгечләр | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Педиатрлар | 1 166/15% | 1 178/14,8 | 1 183/14,5% | 1 229/15,1% | 1 273/15,4% |
| Балалар психиатрлары | 17/0,23% | 15/0,19% | 19/0,23% | 21/0,26% | 22/0,27 |
| Балалар наркологлар | 26/57% | 23/51% | 21/46% | 22/48% | 24/52% |
| Неонатологлар | 122/21,7% | 120/21,3% | 115/20,8% | 122/22,1% | 123/26% |

Белешмәләрдән күренгәнчә, педиатрия хезмәтен кадрлар ягыннан камилләштерү, аерым алганда, җитәрлек санда неонатологлар белән тәэмин итү, балалар психиатриясе һәм наркологиясе системасын үстерү буенча өстәмә чаралар күрү таләп ителә.

Балалар сәламәтлеген саклау өлкәсендә тагын бер мөһим мәсьәлә – балаларга медицина ярдәме күрсәтүче ***учреждениеләр белән тәэмин ителеш.*** Бу күзлектән караганда, балалар поликлиникаларында балаларга (табибка кадәр һәм башлангыч махсус медик-санитар ярдәм) башлангыч медик-санитар ярдәме күрсәтүне оештыру мәсьәләсе аеруча мөһим.

Мәс., 2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең өйрәнү предметына Казан шәһәре Киров районының "Салават Күпере" торак районында яшәүче балаларга оешкан төстә башлангыч медик-санитар ярдәме күрсәтелмәү мәсьәләсе эләкте. 2018 елның 28 маенда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына "кайнар линия" буенча гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр бу мәсьәләне карау өчен сәбәп булды.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры адресына әлеге хоук бозуларны төзәтү буенча оператив чаралар күрергә кирәклеге турында мөрәҗәгать җибәрелде.

Агымдагы елның 1 февраленнән бүгенге көнгә "Салават Күпере" торак районында «4 нче балалар шәһәр поликлиникасы» муниципаль сәламәтлек саклау учреждениесе базасында башлангыч медик-санитар ярдәм (табиб-педиатрлар тарафыннан) оештырылган. Шуалай булса да, гражданнар "аерым" белгечләргә барыбер Юдинодагы шул поликлиникага мөрәҗәгать итәргә мәҗбүрләр. Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына "Салават Күпере" торак районында яшәү урынына якынрак принцип буенча "аерым" белгечләрнең медицина ярдәмен оештыру буенча тиз арада чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

### *3.3.4. Балаларның ялы һәм аларны савыктыру*

Балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру сәламәтлек саклау өлкәсенең өстенлекле юнәлешләренең берсе буларак билгеләнгән.

Татарстан Республикасында балалар ялын һәм аларны савыктыруны оештыру түбәндәгеләр кысаларында башкарыла:

“2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культураны, спортны, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген күтәрү” дәүләт программасын раслау турында” 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган “2014 – 2020 елларга балаларның һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру” ярдәмче программасы;

“Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында” 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында нигезләмә;

«Татарстан Республикасы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыруга норматив чыгымнарны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 18 сентябрендәге 692 номерлы карары;

“Балаларның һәм яшьләрнең ялы, аларны савыктыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфат стандартын раслау турында” 2015 елның 3 мартындагы 130 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Балаларның һәм яшьләрнең ялы, аларны савыктыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфат стандарты;


Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары белән ел саен раслана торган балалар өчен җәйге стационар савыктыру лагерьларына капиталь ремонт ясау программалары.

Балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялы, аларны савыктыру системасын үстерү, аның ***инфраструктурасын үстерүгә ярдәм итү*** максатларында республикада 2013 елдан бирле балаларның стационар җәйге савыктыру лагерьларын капиталь ремонтлау программасы гамәлгә ашырыла, ул ел саен Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары белән раслана. Мәсәлән, 2018 елда савыктыру лагерьларын җәйге сезонга әзерләү барышында 15 дәүләт һәм муниципаль балалар савыктыру лагерьларында капиталь ремонт һәм реконструкция эшләре үткәрелде. Биш ел эчендә 72 шәһәр чите стационар лагеренда ремонт ясалды, гомуми лагерьларның 58%ын тәшкил итә. 2018 елда шулай ук 7 яңа объект төзелде, болар – Казан шәһәренең «Чайка», «Пионер», «Молодежный» балалар савыктыру лагерьларында, Лаеш районының «Липки» лагеренда, Питрәч районының «Чайка» лагеренда, Әлмәт муниципаль районының «Березка» савыктыру комплексында йокы корпуслары, клублар һәм медицина корпусы.

2018 елда балаларны савыктыру чорында 1836 лагерьда алар өчен барлык төр ял оештырылды (көндезге лагерьлар киму аркасында лагерьлар саны беркадәр кимеде).


*63 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда балалар өчен ял һәм савыктыру учреждениеләре челтәре структурасы (оешма рәвеше)***




*64 нче диаграмма*

***2014 –2018 елларда Татарстан Республикасында балалар өчен шәһәр яны ял итү лагерьлары челтәре структурасы*** *(милек рәвешләре буенча)*





2018 елгы җәйге савыктыру кампаниясе чорында 219 752 кеше ял итте, бу 2017 елдагыга караганда 1 243 балага күбрәк. 2018 елда балаларны һәм яшьләрне савыктыруны финанслауга 1 654,7 млн. сум акча бирелде, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1495,2 млн.сум, предприятиеләр акчаларыннан һәм ата-аналар кертемнәреннән – 159,5 млн. сум.

Җәйге чорда 183 851 бала ял итте, бу 2017 елгы җәйге кампаниягә караганда 15 043 кешегә күбрәк.

*65 нче диаграмма*

***2018 елда төрле рәвештә ял иткән балалар саны***




Җәйге савыктыру кампаниясен әзерләү һәм уздыру чорында балалар ялын оештыру күп ***контроль-күзәтчелек органнары һәм ведомстволары тикшерүе аша уза.***

2018 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре, Вәкаләтле вәкилнең иҗтимагый ярдәмчеләре тарафыннан Татарстан Республикасының 13 муниципаль районында 44 ял итү оешмасында, шул исәптән 30 мәктәп яны лагеренда, 8 шәһәр чите савыктыру лагеренда, 4 палата лагеренда, 2 хезмәт һәм ял итү лагеренда тикшерү уздырдылар. Балаларның җәйге ялын һәм савыктыруны оештыру эшчәнлеген тикшерү йомгаклары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә игътибар итәргә кирәк дип саный.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына балалар ялы һәм савыктыру программасында катнашучы Татарстан Республикасының ***Гамәлдәге лагерьлары реестрын*** булдыруны һәм яңартуны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә.

Балаларның шәһәр чите лагерьларыннан ***башбаштакланып китүләрен*** профилактикалау мәсьәләсе аерым игътибар таләп итә. 2018 ел йомгаклары буенча шундый 8 очрак теркәлгән:

Зеленодольск муниципаль районында «Пионер» БСЛ (ДОЛ) (1 очрак);

Минзәлә муниципаль районында «Полянка» БСЛ (ДОЛ) (6 очрак);

Чистай муниципаль районында «Березка» БСЛ (ДОЛ) (1 очрак).

Башбаштакланып китеп йөрүнең балигъ булмаганнарга карата да, шулай ук аларның үзләре тарафыннан да җинаять кылуга яки хокук бозуга китерергә мөмкинлеген аңлап, булачак вожатыйларны тиешенчә әзерләү нигезенә салынырга тиеш. Бу Вожатыйлар мәктәбе кысаларында аерым белем модуле булырга мөмкин. Балигъ булмаганнарның башбаштакланып китеп йөрүе психологик (баланың шәхси үзенчәлекләре чагылу, якын кешеләр белән элемтәләр булмау), , социаль (олылар һәм яшьтәшләре белән үзара аңлашылмый торган мөнәсәбәтләр, үз-үзен инандыру, физик яисә психик көч куллану, лагерьда кызык булмау), медицин характерындагы («дромомания» диагнозы) сәбәпләре аркасында булса, Вәкаләтле вәкил тиешле квалификацияле белгечләрне алар белән шөгыльләнергә җәлеп итүне максатка ярашлы дип саный.

Кызганычка каршы, җәйге савыктыру кампаниясе йомгаклары буенча балалар ***җәрәхәтләнгән*** 78 очрак ачыклана (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча. Бу 2017 ел белән чагыштырганда күбрәк (2017 елда – 45 очрак).

Шул ук вакытта узган җәйге кампания чорында ***йогышлы авырулар*** һәм балигъ булмаганнар тарафыннан яисә аларга карата ***җинаять кылулар*** бер очрак та теркәлмәгән.

Лагерьларда балаларның дөрес ***туклануын оештыру*** лагерь җитәкчелеге тарафыннан даими контрольдә булырга тиеш. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсенең һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль эшчәнлеге нәтиҗәсендә санитария-

эпидемиология иминлеге өлкәсендә ел саен хокук бозу очраклар ачыклана. Мәс., административ хокук бозулар турында Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе тарафыннан 1383 беркетмә төзелгән, 4052,3 мең сумга штраф салынган, 20 материал судка тапшырылган. “Ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен Минзәлә интернат-мәктәбе” бәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең «Полянка» шәһәр яны савыктыру лагере эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору турында күрсәтмә бирелгән.

Балаларны яхшы ял иттерү профессиональ ***тәрбияләү эшен*** дөрес оештыруга да бәйле. Лагерьларда балалар торганда гамәлгә ашырыла торган программаларның ни дәрәҗәдә кызык булуына балалар битараф кала алмый. Алар кызыклы да, мавыктыргыч та, ниндидер белем дә өсти торган булырга тиеш. Биредә музыкага бәйле чаралар гына күздә тотылмаска тиеш. Шуңа бәйле рәвештә, тәрбиячеләр, вожатыйлар һәм башка белгечләр әзерләү кысаларында түбәндәгеләргә игътибар итәргә тәкъдим ителә:

балаларны аларның сәламәтлегенә, физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турындагы законнар таләпләрен үтәү өлешендә методик эшне көчәйтүгә; («Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль закон);

эшләнгән һәм үтәлергә тәкъдим ителүче программаларны, шул исәптән профильле программаларны, алдан бәяләү буенча эшне дәвам итү.

Лагерьларны ***авыр тормыш хәлендә калган балалар белән*** эшләү өчен педагогик кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсе дә аерым игътибар итүне таләп итә. Шул хәлдән чыгару максатында, лагерьларда шундый балалар белән эшләү өчен махсус реабилитацияләү, психологик программалар булырга тиеш.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы. Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы, җирле үзидарә органнары һәм лагерьлар җитәкчеләре белән уртак эш алып барырга кирәк, дип саныйбыз.

2018 елда ***ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, опекадагы балаларның, шул исәптән гаилә тәрбиясенә алынган балаларның*** ялын һәм аларны савыктыруны оештыру мәсьәләсе дә актуаль булды. Җәйге савыктыру кампаниясен оештыруны тикшерү йомгаклары буенча шуны әйтергә кирәк, югарыда күрсәтелгән категория балаларны оешкан төстә ял итүгә җәлеп итүдә җитешсезлекләр бар әле. Бу вәзгыять, аерым алганда, тәрбиягә алган ата-аналарның балаларны ял иттерүдә кызыксынулары булмау һәм опека һәм попечительлек оргннары ягыннан контроль җитәрлек булмау белән аңлатыла.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил игътибар иткән һәм системалы җитди шөгыльләнүне таләп итә торган мәсьәлә – ***инвалид балаларның, сәламәтлеге ягыннан чикле балаларның*** ялын оештыру мәсьәләсе.

Балаларның ялы һәм аларны савыктыру кампаниясе йомгаклары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ел саен сәламәтлеге мөмкинлекләре чикле балалар өчен ял һәм савыктыру системасын үстерү буенча алынган йөкләмәләрнең үтәлешен тәэмин итү чараларын күрү кирәклеге турындагы мәсьәләне күтәрә.

2018 елгы җәйге ял кампаниясе йомгаклары түбәндәгеләрне күрсәтте:

республиканың шул юнәлештәге оешмаларының – ял һәм савыктыру программасын оештыручыларның берсе дә инвалид балаларның, сәламәтлеге ягыннан чикле балаларның, шул исәптән ишетү, күрү, сөйләм бозылу, терәк-хәрәкәт функцияләре бозылган, акылга зәгыйфь балаларның санын белми;

эшли торган лагерьларның инфраструктура торышы сәламәтлеге чикле балаларның ялын һәм аларны савыктыруны тиешле дәрәҗәдә оештыруны тәэмин итә алмый (Татар-

стан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, бары тик 10 лагерьның гына инфраструктурасы хәрәкәтләре чикле балалар тору өчен көйләнгән);

сәламәтлекләре чикле балалар өчен ял итүне оештыру буенча күрелгән чаралар гына (ишетү һәм күрү сәләте бозылган балалар – 188, дибет белән авыручылр – 50, интеллекты бозылга балалар – 170, аутистик спектры бозылган балалар – 11) җитәрлек түгел әле һәм алар гына инклюзив алым принципларында тиешле ялны оештырырга ярдәм итми.

Инвалид балаларны һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны тиешенчә ял иттерү һәм савыктыруны тәэмин итү буенча системалы һәм принципиаль карарлар эшләргә кирәк, дип саныйбыз.

## 3.4. Баланың яшәү һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукын үтәү

Баланың яшәү һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукы – аның төп хокукы.

Әлеге хокукның үтәлешен карау түбәндәге юнәлешләр буенча бирелә:

Төп тырышлык баланың үз гаиләсен саклап калуга юнәлдерелгән булуын исәпкә алып, гаиләдәге тәртипсезлекне бәяләү һәм аны булдырмау өчен профилактик чаралар күрү аеруча мөһим;

ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокуклары үтәлешен анализлау;

гаиләдә конфликтлар булганда бала хокукларының үтәлешен анализлау.


### *3.4.1. Гаиләдә иминлек булмау проблемалары*

***Беренчедән,*** гаиләдә иминлек булмауны бәяләү өчен Татарстан Республикасында гаиләдә иминлек булмауның масштабларын аңларга кирәк. Имин булмаган гаиләләргә балигъ булмаган балалары авыр тормыш хәлендә калган һәм социаль яклау органнары (ведомство, ведомствоара) исәбендә торучы гаиләләр керә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2018 ел азагына балигъ булмаган балалары булган һәм авыр тормыш хәлендә калган һәм социаль яклау органнарының ведомство исәбендә 5 476 гаилә торган, бу 2017 елга караганда 740 гаиләгә (16%ка) күбрәк. Бу гаиләләрдә ел ахырына барысы 10 033 бала яши иде, бу 2017 елга караганда 683 кешегә, ягъни 11,0%ка күбрәк. Бу барлык балалар санынннан 1,2% тәшкил итә (2017 елда – 1,1% иде).

*66 нчы диаграмма*


***2014 – 2018 елларда социаль яклау органнарының ведомство исәбендә торучы гаиләләр һәм аларда тәрбияләнүче балалар саны (кеше)***



Татарстан Республикасында Эчке эшләр министрлыгы белешмәләре буенча 2018 елда балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрдә ведомство исәбендә торучы гаиләләр саны 170кә (4%ка) кимеде 4 422 гаилә булды. Шул ук вакытта аларда яшәүче балалар саны 328 балага (7%ка) артты. Барлык балаларның гомуми санынннан мондый балалар өлеше кимеде һәм ул 0,5 % тәшкил итә. (2017 елда бу күрсәткеч 0,9% иде).

*67 нче диаграмма*


***2014 – 2018 елларда эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрендә ведомство исәбендә торучы гаиләләр һәм аларда яшәүче балалар саны** (кеше)*




«Социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне исәпкә алу һәм мониторинглау» бердәм мәгълүмат банкында (алга таба – Бердәм белешмәләр банкы) ведомствоара исәптә торучы гаиләләр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым игътибарында тора. 20178 елда социаль куркыныч шартларда булган 1 172 гаилә бердәм базага кертелде, аларда 2 406 балигъ булмаган бала яши. 2017 ел белән чагыштырганда мондый категориядәге гаиләләр 120гә (11%ка) артты. 2018 ел азагына Бердәм белешмәләр банкында 1 157 гаилә исәпкә куелган иде, аларда яшәүче балигъ булмаган балалар саны – 2 340. Барлык балалар санынннан мондый балалар 0,29% тәшкил итә (2017 елда – 0,26%).

*68 нче диаграмма*

***2014–2018 елларда социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнең һәм аларда тәрбияләнүче балаларның саны***




Гомумән, 2018 ел ахырына Татарстан Республикасында төрле дәрәҗәдә имин булмаган гаиләләр түбәндәгечә исәпкә алынган:

7 582 гаилә (2017 елда – 8 223 гаилә, 2016 елда – 9  905 гаилә);

12 897 бала, яки балаларның гомуми санынннан 1,5% (2017 елда -14 183 бала яки 1,7%, 2016 елда – 16 087 бала яки 2%).

Шулай итеп, ***соңгы еллардагы имин булмаган гаиләләр мониторингы төрле рәсми исәпләрдә торучы гаиләләрнең һәм аларда яшүче балаларның саны кимүен күрсәтә.*** 2017 ел белән чагыштырганда, мондый гаиләләр 23,5%ка кимрәк, ә шундый шартларда яшәүче балалар саны 20%ка кимегән.


***Икенчедән,*** органнарның – профилактикалау системасы субъектларының төп бурычлары – мондый гаиләләрнең проблемаларын алданрак ачыклау, аларга нәтиҗәле һәм реаль реабилитацияләү ярдәме күрсәтү. Мондый эшчәнлекнең максаты бала өчен аның үз гаиләсен саклап калудан гыйбарәт.

Һичшиксез, мондый эшчәнлекнең төп һәм ахыргы нәтиҗәсе – ата-аналарының икесе дә, яисә берсе ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү аркасында гаиләсен югалткан балалар санын киметү булырга тиеш.

Шуны танырга кирәк, ел саен ачыклана торган ата-аналары ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның (алга таба – ятим балалар) саны кими. 2017 ел белән чагыштырганда, ачыкланган ятим балаларның гомуми өлешендә мондый балалар саны да кимегән: ел дәвамында 60%тан 49% калган.

*69 нчы диаграмма*

***2014 –2018 елларда ачыкланган ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның саны (кеше)***




Бу күпмедер дәрәҗәдә урыннарда органнарның – профилактикалау системасы субъектларының шундый имин булмаган гаиләләр белән нәтиҗәле эшләвен күрсәтә.

Имин булмаган гаиләләр белән эшләүнең торышын тасвирлау **имин булмаган гаиләләрне алданрак ачыклаудан** гыйбарәт. Югарыда күрсәтелгән статистикадан күренгәнчә, төрле төрдәге исәпкә алынган (Татарстан Республикасы буенча ЭЭМында исәпкә алынудан тыш) гаиләләр һәм аларда яшәүче балалар саны 2018 елда артты. Бу органнарның – профилактикалау системасы субъектларының имин булмаган гаиләләрне алдан ачыклау эшенең активлашуын күрсәтә. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дә үзенең еллык докладларында да, районнарга эш визитлары вакытында да ел саен шуңа өнди иде.

Шул ук вакытта, 2018 елда «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасы аша җибәрелгән ***сигнал карталары*** саны артты, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасы бердәм белешмәләр банкын булдыру турын-

да” 2010 елның 22 апрелендә 294 номерлы карары белән расланган «Социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасы бердәм белешмәләр банкын булдыру регламенты”нда (алга таба – Регламент) каралган. Ел дәвамында сигнал карталары 3 797 гаиләгә җибәрелгән, шулардан 1 172 гаилә исәпкә куелган, бу җибәрелгән сигнал карталарының 31%ын тәшкил итә (2017 елда 3 189 сигнал картасы җибәрелгән иде), шул исәптән:

эчке эшләр органнары – 1 472 сигнал картасы (җибәрелгән сигнал карталарының 39%) (2017 елда 1 612 сигнал картасы яисә 51%);

мәгариф идарәсе органнары – 611 сигнал картасы (16%), (2017 елда – 333 сигнал картасы яисә 10,4%);

сәламәтлек саклау идарәсе органнары – 581 сигнал картасы (15,5%), (2017 елда – 391 сигнал картасы яисә 12%);

социаль яклау органнары һәм учреждениеләре – 535 сигнал картасы яисә 14% (2017 елда – 372 сигналь картасы яисә 11,5%);

опека һәм попечительлек органнары – 300 сигнал картасы (8%), (2017 елда – 252 сигнал картасы яисә 8%);

җинаятькә-башкару инспекциясе – 154 сигнал картасы (4%), (2017 елда – 107 сигнал картасы яисә 3,4%);

авыл җирлекләре башлыклары – 43 сигнал картасы (1%), (2017 елда – 24 сигнал картасы яисә 1%);

яшьләр эшләре һәм спорт органнары – 15 сигнал картасы (0,5%), (2017 елда – 9 сигнал картасы яисә 0,3%);

башка органнар һәм гражданнар хәбәрләре – 80 сигнал картасы яисә 2% (2017 елда – 89 сигнал картасы яисә 2,4%).

Сукбайлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау системасы субъектларының имин булмаган гаиләләрне ачыклау активлыгын анализлаудан күренгәнчә, 2017 елданы кебек үк, эчке эшләр органнары булды. Сигнал карталарын мәгълүмат системасына җибәрү активлыгын мәгариф идарәсе органнары, сәламәтлек саклау органнары, җинаять-башкару инспекциясе арттырды. Ә менә опека һәм попечительлек органнарының активлыгы җитешми. Гадәттәгечә, сигнал карталарын тутыру буенча авыл җирлекләре башлыкларының, яшьләр эшләре һәм спорт, опека һәм попечительлек органнарының активлыгы түбән булды. Мәдәният органнары һәм учреждениеләре дә ел буена бер сигнал картасы да җибәрмәгәннәр.

Шул ук вакытта, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан профилактика субъектлары органнарының эшчәнлеген гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча конкрет хәлләрне карау кысаларында анализлаудан күренгәнчә, гаиләләрнең начар яшәү шартларын вакытында ачыкламау, алар белән профилактик чаралар уздырылмау күренә, аерым очракларда – балалар гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янау. Эшкә мондый салкын караш Алексеевск муниципаль районында гаиләгә алган баланың фаҗигасе белән тәмамланды. Күп органнар (опека һәм попечительлек органнары) белә торып, аны бернинди исәпкә дә куймыйлар. Шуңа күрә профилактика субъектлары органнарының имин гаиләләрне ачыклау һәм аларга вакытында ярдәм итүне оештыру эшен арттыру актуаль булып кала. Бүген имин булмаган гаиләләрне ачыклау вазыйфаи затның да хокукы да, шулай ук аның бурычы да.

Балалары социаль приютларга урнаштырылган гаиләләр белән эшләү яхшы якка үзгәрде дип әйтергә була. Соңгы елларда бу эш шактый актив башкарылды. 2018 ел йомгаклары буенча мондый очраклар аерым муниципаль районнар эшендә күренә (Арча, Менделеевск, Теләче районнарында).

***Мисал.*** *«Камские зори» социаль приютында торучы балаларны реабилитацияләү буенча индивидуаль программаларны анализлаудан күренгәнчә, Менделеевск муниципаль районында яшәүче һәм приютка урнаштырылган К., Л., Б.ның ата-аналарына карата Менделеевск муниципаль районы дежур ЭЭБнең (ОВД) акты нигезендә аларны ата-ана хокукыннан мәхрүм итү эше оештырылган. Шул ук вакытта гаилә турындагы белешмәләр ведомствоара исәптә булмаган һәм бу гаиләләрне реабилитацияләү эше тиешенчә алып барылмаган.*

***Мисал****: Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Теләче муниципаль районына визиты кысаларында Р. гаиләсендәге проблема ачыкланды. Балигъ булмаган бала Р. 2018 елның апреленнән бирле Саба муниципаль районының “Балалар һәм яшүсмерләр өчен Тургай”социаль приюты” ДКУендә тора. Ә Теләче муниципаль районының имин булмаган гаиләләрне профилактикалау хезмәтләренә баланың приютка урнаштырылуы турында хәбәр ителмәгән, сәбәпләре ачыкланмаган, баланың гаиләсе белән реабилитация эше оештырылмаган.*

***Дүртенчедән,*** соңгы алты елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибар үзәгендә ***хәтәр төркем гаиләләр белән реабилитацияләү эшенең сыйфаты*** булды. Республика буенча тулаем бу эшне оештыруда уңай үзгәрешләр булуын әйтергә кирәк.

1. Социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне реабилитацияләүнең индивидуаль программаларын (алга таба – ИТР) анализлау районнарда элеккечә үк ИПРны эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга *формаль карау* күзәтелгәнен күрсәтә.

Шулай итеп, ата-аналар алкоголь куллануга бәйле ведомствоара исәпкә куелган гаиләләрне реабилитацияләүнең индивидуаль программаларын эшләгәндә, реабилитациләү чаралары арасында алкогольдән дәвалау чаралары каралмаган, болардан башка бүтән реабилитация шарталарының нәтиҗәсе булмаячак.

***Мисал:*** *Социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнең шәхси эшләрен өйрәнгәндә, Арча муниципаль районында ведоствоара исәптә 11 гаиләнең торуы ачыкланды, аларның 10сы -спиртлы эчемлекләргә хирыслык буенча. Шул ук вакытта, күрсәтелгән категория гаиләләрен реабилитацияләүнең индивидуаль программаларында ата-аналарның алкогольгә бәйлелеген җиңүгә юнәлдерелгән нәтиҗәле чаралар юк. ИПР кысаларында мондый гаиләләр белән эшләүдә нарколог роле дә күренми.*

Балигъ булмаганнар яши торган гаиләләрне реабилитацияләү процессларына мәгариф, яшьләр сәясәте, мәдәният органнарының һәм учреждениеләрнең катнашуы да сизелми.

ИТРның реабилитация чараларын оештыруга балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр ягыннан контроль дә җитәрлек түгел. Бу түбәндәге муниципаль районнарда күзәтелә:

Арча муниципаль районы;
Әтнә муниципаль районы;
Югары Ослан муниципаль районы;
Чүпрәле муниципаль районы;
Зәй муниципаль районы;
Кукмара муниципаль районы;
Балык Бистәсе муниципаль районы;
Спас муниципаль районы;
Питрәч муниципаль районы;
Теләче муниципаль районы;
Тукай муниципаль районы;
Чирмешән муниципаль районы;
Ютазы муниципаль районы;
Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары.

Шуңа бәйле рәвештә, күрсәтелгән муниципалитетлар адресына хокукларның бозылуы һәм аларны төзәтү чараларын күрү турында бәяләмәләр җибәрелде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча уздырылган тикшерү чаралары кысаларында ачыкланган нәтиҗәләрдән күренгәнчә, социаль авыр хәлдә буларак ведоствоара исәптә торучы гаиләләр үзләренә карата уздырыла торган реабилитация чарараларыннан хәбәрдар булмаганнар һәм комиссия күрсәтмәләрен үтәмәгән өчен нинди җаваплылык каралуын белмәгәннәр. Шуңа бәйле рәвештә, гамәлдәге Регламентка социаль авыр хәлдәге исәпкә куелган гаиләләрне ИПР нигезләмәләре белән таныштыру өлешендә үзгәрешләр кертергә кирәк, дип саныйбыз. Һичшиксез, бу гаиләгә карата реабилитация эшчәнлеген башкаруның нәтиҗәлелеген арттырыр.

2. Соңгы елларда ***социаль авыр хәлдәге гаиләләрнең ведомствоара исәптә тору вакытын кыскартуга*** ирешеп булды. Кайчакта, кагыйдә буларак, формализм һәм тәкъдим ителүче реабилитация ярдәменең нәтиҗәле булмавы гына бу вакытны сузуга гаепле була. Нәтиҗәдә мондый гаиләләрдә балалар интегә. 2012 – 2013 елларда конкрет вәзгыятьләрне анализлау барышында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәте тарафыннан ведомствоара исәптә җиде елга кадәр торучы гаиләләр ачыкланды, боларга карата бернинди эш тә эшләнмәгән. Реабилитация срокларын кыскарту – үзмаксат түгел. Иң мөһиме – гаиләгә кризистан нәтиҗәле реаль чыгу юлларын һәм ярдәм тәкъдим итеп, балаларның имин булмаган гаилә хәлендә булу срокларын киметү.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2018 елда ведомствоара исәптә торган 960 гаиләнең тернәкләндерү срогы 1 елга кадәр сузылды, 1 елдан 2 елга кадәр – 180 гаилә һәм 2 елдан артыкка – 17 гаилә (2017 елда – 53 гаилә). Шуны да әйтергә кирәк, 2017 ел белән чагыштырганда, тернәкләндерү срогы 1 елдан кимрәк булган гаиләләр саны 43 гаиләгә (18%ка) кимеде.

Шулай да, реабилитацияләү срокларын сәбәпсез сузуның аерым очраклары бар әле.

***Мисал:*** *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Питрәч муниципаль районына визиты кысаларында социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнек индивидуаль реабилитацияләү программаларына (ИПР) анализ ясаудан күренгәнчә, балаларны Питрәч муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Шатлык» социаль приютында тоту өчен нигез юк. Әлеге анализ гаилә иминлеген профилактикалау өлкәсендә ведомстоара эшне оештыру тиешенчә куелмаган булуын күрсәтә. Нәтиҗә буларак, ике гаилә 2016 елдан бирле ведомствоара исәптә тора.*


Социаль приютлардагы балигъ булмаганнарны социаль реабилитацияләүнең уртача соргын киметү тенденциясе саклаып кала. 2018 елда бу күрсәткеч 4,8 ай булды (2017 елда – 4,9), 300 бала 6 айдан 1 елга кадәр булды (2017 елда – 367 бала), приютта 1 елдан артык 24 бала торды (2017 елда – 14 бала). Безнең фикеребезчә, социаль приютларда яшәүче балигъ булмаганнарның тормышларын алга таба яхшырту бурычларын тиз арада хәл итүгә комачаулый торган төп сәбәпләргә, элеккечә, гаиләдә тернәкләндерү чараларын оештыруның һәм уздыруның нәтиҗә бирми торган һәм һөнәри дәрәҗәдә булмаган алымнарын куллану да керә.

3. Органнарның – профилактикалау субъектлары эшчәнлеге сыйфатындагы төп критерий – *ИПРны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре.*

2018 елда ведомствоара мәгълүмат системасында торучы гаиләләрне тернәкләндерүнең уңай нәтиҗәсе буларак исәптән төшерү кимемәдә, бу күрсәткеч 86% тәшкил итә (2017 елда – 84%). Уңай тернәкләндерүгә ирешмичә исәптән төшерелгән гаиләләр саны кимеде – 16,0%тан 14%ка кадәр.

*70 нче диаграмма*

***2014-2018 елларда гаиләләрне ведомствоара исәптән төшерү нигезләре динамикасы***





2018 елда социаль куркыныч хәлдәге гаилә буларак, шундый 10 гаилә кабат ведомствоара исәпкә куелган.

Реабилитациядән соң балаларның институциячел учреждениеләрдә җайлашу вәзгыятен бәяләү дә мөһим. Мондый вәзгыятькә анализ түбәндәге диаграммада күрсәтелә.

*71 нче диаграмма*

***2018 елда социаль приютларда тернәкледерелгәннән соң балаларның тормышка җайлашуы***




2018 елда махсуслаштырылган учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләрнең 80%тан артыграгы үз гаиләләренә кире кайтарыла, бу күрсәткеч 2017 елга караганда 4%ка күбрәк (2017 елда – 76%).

4. Тернәкләндерү эшен оештыруны бәяләүнең тагын бер критерийларыннан берсе – *ата-ана хокукларын чикләү* институтыннан файдалануның ни дәрәҗәдә уңышлы булуын бәяләү.

Гомуми практикада ата-ана хокукларын чикләү турында суд карары кабул ителү гаиләгә карата реабилитация эшенең тәмамлануы буларак кабул ителә. Чикләү чоры гаиләне реабилитацияләүне активлаштыруның соңгы шансы һәм ИПРның соңгы этабы буларак каралырга тиеш. Әмма Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы белешмәләре буенча, 2018 елда 217 гражданның суд карары белән ата-ана хокуклары чикләнде, ә шуннан соң алты ай узгач бары тик 25 ата-анага гына реабилитация эше йомгакларыннан соң суд карары белән бу хокуклар кире кайтарылды, ата-аналар 11% очракта үз балаларын тәрбияләү хокукларын кайтардылар, 2017 елда – 18 кеше (11%), 2016 елда – 17 кеше (11%).

***Мисал:*** *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Югары Ослан муниципаль районында эш визиты белән булганда бер хатынның өч баласы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 18 июлендәге карары белән, Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясы нигезендә, Югары Ослан судының 2017 елның 22 сентябрендәге карары белән гаиләдән тартып алынды. С.ның ата-ана хокуклары чикләнгән, балалар гаиләне алыштыручы гаиләгә бирелгән. Әмма балалар гаиләдән алынган вакыттан бу гаилә социаль куркыныч хәлдәге гаилә буларак ведомствоара исәпкә алынмаган, гаилә белән нинди дә булса реабилитация эше башкарылмаган.*

Республикада гаиләгә тәэсир итүнең соңгы чарасы буларак ата-ана хокукын чикләүне куллану бик үк алга китмәгән. 2018 елда ата-ана хокукларын чикләү буенча чаралар бөтенләй күрелмәгән, ә органнар – профилактикалау субъектлары тарафыннан түбәндәге муниципаль районнарда башта ук ата-ана хокукыннан мәхрүм итү мәсьәләсе куелган: Аксубай (3 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән, Апаста – (5 кеше), Арчада (3 кеше), Әтнәдә (4 кеше), Буада (9 кеше), Чүпрәледә (4 кеше), Кама Тамагында (7 кеше), Менделеевск районында (14 кеше), Питрәчтә (3 кеше), Спаста (7 кеше), Тәтештә (5 кеше), Сарманда (6 кеше), Чирмешәндә (1 кеше). Шул ук вакытта бу чара 2018 елда түбәндге муниципаль районнарда актив кулланылды: Әгерҗе, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Биектау, Түбән Кама, Нурлат, Чистай муниципаль районнарында.

***Бишенчедән,*** республикада гаилә иминлеге торышын бәяләүнең тагын берсе – *балаларны гаиләдән тартып алу.*

Россия Федерациясе законнары белән гаиләдән балалар тартып алуның балык очраклары һәм нигезләре билгеләнгән (опека һәм попечительлек органнары карары буенча, балигъ булмаганнарның эшләре буенча бүлекчәләр акты буенча, ата-аналар гаризасы буенча, балалар гаризалары буенча).

Балигъ булмаганнарны гаиләдән тартып алу законнарны бозып башкарылу практикасын анализлау максатларында һәм Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның 2017 елның 30 гыйнварындагы 4606-МР йөкләмәсен үтәү Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2017 елның 3 февралендәге 5 номерлы боерыгы белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында тиешле Эшче төркем төзелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Эшче төркем адресына 14 гражданннан мөрәҗәгать керде, 13 хәбәрдә Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан балаларны гаиләдән тартып алу фактлары турында, 1 хәбәр –ата-аналарны балаларын социаль приютка урнаштыруга мәҗбүр итү турында.

Тикшерү йомгаклары буенча гаиләдән балаларны тартып алуның 8 факты буенча алар законсыз алынган дию үзен расламады, балаларны алу законлы һәм балаларны яклау максатында, аларның мәнфәгатьләреннән чыгып башкарылган. Калган 3 факт буенча – Казанда, Биектау һәм Кама Тамагы муниципаль районнарында – мөрәҗәгать итүчеләрнең балалар законсыз алынды дигән дәлилләре расланды, биредә балаларның һәм аларның гаиләләренең хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылган. Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан районнар җитәкчелегенә балаларны социаль приютлардан кичекмәстән гаиләләренә кайтару турында тиешле таләпләр җибәрелде.

Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан ата-аналарны балаларын социаль приютка җибәрергә мәҗбүр итү факты буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан “аварийщик” гаиләләрдән балаларны тартып алу белән янау буенча кичекмәстән чаралар күрү һәм ата-аналарны балаларын социаль приютка урнаштыруга мәҗбүр итүне туктату турында

таләпләр җибәрелде.

Моннан тыш, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге кысаларында тагын өч муниципаль районда (Алексеевск, Мамадыш, Чистай) балаларны гаиләдән законсыз тартып алу фактлары ачыкланды. Шуңа бәйле рәвештә, күрсәтелгән районнар башлыклары адресына хокуклар бозылу һәм аларны бетерү турында тиешле бәяләмәләр җибәрелде.

Шуны да әйтергә кирәк, соңгы ике елда бу темага игътибарны арттыру нәтиҗәсендә яхшы якка да үзгәрешләр бар. Әгәр 2017 ел йомгаклары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балаларны гаиләдән алуны шуңа вәкаләтләре булмаган органнар карарлары буенча башкарылган очракларның күбрәк булуы ачыкланган булса, 2018 елда мондый очраклар берле-икеле генә булган.

Балаларны ата-аналардан тартып алу очракларыннан иң фаҗигалесе – алар балаларның гомеренә яисә сәламәтлегенә куркыныч янаган хәлдә алынган, мондый Тәртип Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясnда регламентлаштырылган.

Республикада ата-аналарыннан балаларын аларның гомеренә һәм сәламәтлегенә җитди һәм реаль куркыныч янаган хәлдә алу түбәндәге таблицада бирелде.

*19 нчы таблица*

| Күрсәткеч | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясында каралган нигезләр буенча гаиләдән алынган балалар саны | 99 | 122 | 63 | 50 | 59 |
| шулардан социаль-тернәкләндерү уздырылганнан соң ата-аналарына кире кайтарылган балалар саны | 39 (39,4%) | 24 (19,6%) | 23 (36,5%) | 13 (26%) | 6 (10%) |

Шуны әйтергә кирәк, соңгы өч елда республикада балаларны ата-аналарыннан тартып алу тартып алу вәзгыяте тотрыклырак, 2014 – 2015 еллар белән чагыштырганда,мондый очраклар саны икеләтә диярлек кимеде.

Моннан тыш, муниципаль хезмәтләрнең балалар тартып алынган гаиләләр белән эшен оештыруны тикшергәндә, еш кына бер орган да (опека һәм попечительлек органы да, муниципаль комиссияләр дә) үзләренең муниципаль районындагы шундый балалар турында тулы мәгълүматны белмәүләре ачыкланды. Балаларны үз ата-аналарыннан мөмкин кадәр азрак аеру яки бөтенләй булдырмау өчен муниципаль комиссияләр төрле сәбәпләр аркасында гаиләдән алынган балаларны комплекслы исәпкә алып барырга тиешләр.

Имин булмаган гаиләләр проблемаларын анализлау йомгаклары буенча шуны билгеләп үтәрә кирәк, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең, органнарның – республика һәм муниципаль дәрәҗәләрдә профилактикалау системасы субъектларының бергәләп һәм үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә, прокуратура органнары ярдәмендә республикада имин булмаган гаиләләр белән индивидуаль профилактик һәм реабилитация эшләрен оештыруда уңай үзгәрешләр барлыкка килде. Гаиләдәге һәм балалардагы имин булмаган хәлләрне җиңеләйтү эшен таба камилләштерү, активлаштыру һәм нәтиҗәле инновацион модельләр булдыру буенча өстәмә чаралар күрү максатларында әлеге хезмәттәшлек системалы һәм даими нигездә дәвам итәчәк.

### 3.4.2. Ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру

Федераль статистика хисабының 103-РИК Формасы белешмәләре буенча Татарстан Республикасында 2018 ел азагына ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның саны 11 136 кеше булды, бу барлык балалар санынннан 1,35% тәшкил итә, (2017 елда – 1,4%, 2016 елда – 1,5%). Бу соңгы 10 елда иң түбән күрсәткеч.

Республикада төрле сәбәпләр буенча ата-ана опекасыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру мәсьәләсендә тотрыклылык күзәтелә. 2 018 ел ахырына 10 488 бала гаиләгә урнаштырыла, бу барлык ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның (алга таба – ятим балалар) 94,2%ын тәшкил итә. Ятим балалар өчен дәүләт учреждениеләрендә 549 бала тәрбияләнде, бу барлык ягъни ятим балалар санынннан 4,9% тәшкил итә.

*72 нче диаграмма*


***2014-2018 елларда ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру***




2018 ел дәвамында 933 ятим бала ачыкланды. Бу соңгы 5 елда иң түбән күрсәткеч.

*73 нче диаграмма*

***2009 – 2018 елларда беренче мәртәбә ачыкланган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны (кеше)***



Статистика хисабын анализлаудан күренгәнчә, 2018 ел дәвамында төрле рәвештәге гаилә тәрбиясенә 868 бала тапшырылды, шулардан:

587 (67,6%) – туганнары опекасына (попечительлегенә);

194 (22,4%) – балалар алучы гаиләләргә;


87 (10%) уллыкка алыналар.

Гаиләгә тәрбиягә тапшырылган ятим балаларның төп өлешен беренче мәртәбә ачыкланган балалар тәшкил итә. 2018 елда гаиләләргә тапшырылган 868 ятим баланың 707е беренче мәртәбә ачыкланган балалар. Башкача әйткәндә, 2018 елда ачыкланган 933 ятим баланың 80%ы төрле рәвештә гаиләләр тәрбиясенә урнаштырылды.

2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында яшәүче ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру түбәндәге диаграммада бирелә.

*74 нче диаграмма*


***2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында яшәүче ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру***




Гаиләгә урнаштыруның төп рәвеше булып, гадәттәгечә, ***балаларны бушлай туганнары тәрбиясенә тапшыру*** кала. 2019 елның 1 гыйнварына 3 967 опекун гаиләсендә 4 945 бала тәрбияләнә.

*75 гче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда опекада (попечительлектә) тәрбияләнүче балалар саны***




2018 елда ***тәрбиягә балалар алган гаиләләр*** саны кимеде: 2017 елда – 1 556 гаилә булса, 2018 елда – 1 468. 2019 елның 1 гыйнварына 1 468 гаиләдә 2 733 алынган бала тәрбияләнә.

76 гаиләдә – 5 һәм аннан күбрәк балалар, 188 гаиләдә – 3–4 бала, 1 204 гаиләдә (82%) – 1–2 алынган бала тәрбияләнә.

*76 нчы диаграмма*

***2009 – 2018 елларда гаилә тәрбиясенә алынган балалар саны***





2017 – 2018 елларда гражданнар шикаятьләренә бәйле рәвештә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***күпбалалы гаиләләрдә*** балаларның хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруның торышын анализлый. Анализлау йомгаклары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гаилә тәрбясенә алынган ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокуклары тиешенчә үтәлүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов адресына республикада гаилә тәрбиясенә тапшырылучы балалар санын федераль кагыйдәләр нигезендә чикләү (тәрбиягә балалар алган гаиләдә балалар саны, үзләренекен һәм алынганнарны кертеп, 8 баладан артмаска тиеш) турындагы мәсьәләне карау тәкъдиме белән мөрәҗәгать җибәрде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең әлеге позициясен Татарстан Республикасы Президенты хуплады һәм бу позиция республиканың опека һәм попечительлек органнары эшчәнлегендә кулланырга тәкъдим ителде.

2018 елның 1 гыйнварына 2 605 гаиләдә 2 779 ***уллыкка (кызлыкка) алынган балалар*** тәрбияләнә иде. Шулардан 5 балалылар – 4 гаилә, 3 – 4 уллыкка алынган бала белән – 8 гаилә, 1 – 2 балалылар – 2 593 гаилә.

*77 нче диаграмма*


***2009–2018 елларда уллыкка (кызлыкка) алынган балалар саны***




2018 елда ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруның өстенлекле рәвеше – уллыка (кызлыкка) алуның кимүгә таба бару тенденциясе сакланып калды. 2018 ел дәвамында уллыкка тапшырылган балалар саны 2017 елга караганда 9 кешегә кимегән, барысы 87 бала уллыкка алынган (2017 елда – 96 бала). 2008 елдан башлап уллыка (кызлыкка) тапшырыла торган балалар саны өч мәртәбә диярлек кимеде.

*78 нче диаграмма*


***2009 – 2018 елларда уллыка (кызлыкка) алынган балалар саны***




Уллыка (кызлыкка) алу процедурасын башкарганда балаларны Россия гражданнары гаиләләренә урнаштыруга өстенлек бирелә. Шулай итеп, 2018 елда уллыкка алынган 87 баланың барысы да Россия Федерациясе гражданнарына тапшырылды.

*79 нчы диаграмма*

***2009 – 2018 елларда уллыкка (кызлыкка) алу***




Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә 2016 – 2017 еллардагы докладларында гражданнарны уллыкка (кызлыкка) балалар алуга, ***инвалид балаларны, сәламәтлеге чикле балаларны гаилә тәрбиясенә алуга*** кызыксындыру өчен өстәмә чаралар күрү мөмкинлеген карарга тәкъдим ителде. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле бер мәртәбәле өстәмә түләү турында» 2017 елның 13 июлендәге № 493 карары белән 2017 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле бер мәртәбә 200 мең сум күләмендә өстәмә түләү билгеләнде. 2018 елда республикада бу ярдәм чарасыннан 7 гаилә файдаланды (2017 елда да 7 иде).

«Балалы ражданнарга дәүләт пособиеләре турнда» 1995 елның 19 маендагы 81-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, җиде яшьтән зуррак булган, шулай ук абыйлы-энеле (апалы-сеңелле) балаларны уллыкка алганда 2017 елның 1 февраленнән һәр шундый бала

өчен 128 053, 08 сум пособие түләнә, ә 2019 елның 1 февраленнән – 133 559, 36 сум. Бу пособиедән 2018 елда – 7 гаилә, 2017 елда 7 гаилә файдаланды.

Кызганычка каршы, югарыда күрсәтелгән дәүләт ярдәмен күрсәтү дә республикада уллыкка алу вәзгыятен бик яхшыртмады.

2019 елның 1 февраленнән баланы гаилә тәрбиясенә алганда бер мәртәбә бирелә торган пособие 17 479, 73 сум тәшкил итә.

2018 елда 19 инвалид бала гаиләгә бирелде (2017 елда бу күрсәткеч – 45, 2016 елда – 39 бала иде), аларның 1се уллыкка алынды, ә 18е опекага һәм попечительлеккә тапшырылды, шул исәптән 11 – гаиләгә алу шартнамәсе буенча.

Ел йомгаклары буенча, ***ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда*** тәрбияләнүчеләр саны 10%ка артты (502дән 549га кадәр), шуннан 2018 ел ахырына тәрбиядә калучылар:

сабыйлар йортында – 67 бала (2017 елда – 52);

балалар йортларында – 219 бала (2017 елда – 189);

ятимнәр өчен VIII төрдәге интернат мәктәпләрдә – 66 бала (2017 елда – 62);

интернат йортларда – 197 бала (2017 елда – 199).

Башлыча, бу оешмаларда тәрбияләнүчеләрнең саны арту республика балалар йортларында тәрбияләнүче балалар саны артуга бәйле.

***Региональ банк белешмәләренә караганда,*** 2019 елның 1 гыйнварына ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган 648 бала исәпләнә, бу узган елга караганда 55 кешегә күбрәк (01.01.2018 ел башына – 593 бала иде) (9%ка арткан). Аларның яшь составы түбәндәге таблицада бирелә.

*20 нче таблица*

***2019 елның 1 гыйнварына ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында мәгълүматлар банкында булган балаларның яшь составы***

| Балаларның яше | Балаларның гомуми саны | Шулардан | | Инвалидлыгы булганнар | Сәламәтлек мөмкинлеге чикле булганнар |
|---|---|---|---|---|---|
| | | малайлар | кызлар | | |
| 0–3 ел | 57 | 36 | 21 | 9 | - |
| 3–5 ел | 38 | 20 | 18 | 16 | - |
| 5–7 ел | 37 | 21 | 16 | 13 | 14 |
| 7–10 ел | 71 | 45 | 26 | 37 | 40 |
| 10–14 ел | 168 | 105 | 63 | 88 | 110 |
| 14–18 ел | 277 | 168 | 106 | 122 | 154 |
| **Барысы** | **648** | **395** | **253** | **285** | **318** |

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләр банкын анализлау шуны күрсәтә: балалар саны 10 яшьтән 18 яшьтәгеләр исәбенә арткан. Болар күбрәк гаиләне алыштырган гаиләләрдән кире кайткан балалар. Инвалид балалар һәм сәламәтлек мөмкинлеге чикле булган балалар саны бик үзгәрмәде (2017 елда 283 һәм 304 иде).

2018 елда ***икенчел ятимлек*** вәзгыяте җитди проблемага – баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында карарлар юкка чыгарылды.

2018 елда баланы гаилә тәрбиясенә тапшыру турында карарларны юкка чыгару 2 мәртәбә артты. 97 бала “ятим балалар учреждениеләренә” кире кайтарылды. Аларның яртысыннан артыгы (97дән 54е) тәрбиягә алган гаиләрдән кайтучылар.

2017 елда баланы гаилгә тапшыру 19 очракка (76%ка) артты һәм барысы 44 очрак булды.

Шундый 97 (70%) карардан 68 очрак уллыкка алучылар, опекуннар һәм тәрбиягә бала алучылар инициативасы буенча туктатылды, шул исәптән: Казан шәһәрендә – 16 очрак, Әлмәт муниципаль районнарында – 8 очрак, Алексеевск, Әгерҗе, Зәй, Түбән Кама, Балык Бистәсе, Спас муниципаль районнарында – 3әр очрак, Аксубай, Әлки, Баулы, Мөслим, Нурлат, Яңа Чишмә муниципаль районнарында һәм Чаллы шәһәрендә – 2шәр очрак, Азнакай, Апас, Арча, Югары Ослан, Чүпрәле, Кукмара, Менделеевск, Минзәлә, Тукай муниципаль районнарында – 1әр очрак.

Шул ук вакытта, 97 карарның 25е (26%) бала алган ата-аналарның үз вазыйфаларын тиешенчә башкармауга бәйле кабул ителде, шул исәптән Казанда – 9 очрак, Алексеевск районында – 6 очрак (шул исәптән 3 очрак – балаларга карата мәрхәмәтсез булу), Әлмәт районында – 3 очрак, Югары Ослан районында – 2 очрак, Аксубай, Бөгелмә, Биектау, Лениногорск, Түбән Кама муниципаль районнарында – 1әр очрак.

Икенчел ятимлекнең торышы опека һәм попечительлек органнарының, ятим балаларны тәрбиягә алуга кандидат булган гаиләләрне әзерләү буенча хезмәтләрнең эш нәтиҗәлелеге төп күрсәткечләренең берсе булып тора.

2017 елның июленнән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым игътибарында кайбер районнарда (Әтнә, Нурлат, Спас) гаиләләрдә тәрбиягә алынган ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу һәм моны опека һәм попечительлек органнары тарафыннан тиешенчә тикшереп тормау очраклары булды.

Опека һәм попечительлек органнары эшчәнлегендәге проблемалы мәсьәләләр «2017 елда Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге турында”гы Докладта күрсәтелгән иде, анда опека һәм попечительлек органнарының опекадагы балалар хокукларын үтәү буенча вазыйфаларын тиешенчә үтәүләрен тәэмин итү буенча конкрет чаралар күрү зарурлыгына карата тиешле күрсәтмәләр бирелгән иде.

2018 елда опека һәм попечительлек органнарының эшчәнлеге Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең махсус контоль һәм күзәтчелек предметы булды.

Шуннан чыгып, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алага таба – Министрлык) аша районнардагы һәм шәһәрләрләрдәге опека һәм попечительлек органнары белән конструктив хезмәттәшлек, үзара мөнәсәбәтләр, үзара аңлашу урнаштыруга ирешеп булды. Республика законнары белән Министрлыкка районнардагы һәм шәһәрләрләрдәге опека һәм попечительлек органнары тарафынна ата-аналарны алыштыручы опекуннарның үз вазыйфаларын тиешенчә үтәүләренә котрольне көчәйтү йөкләнде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил таләпләре нигезендә 2017 елдан мондый ведомство контроле ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр кысаларында гамәлгә ашырыла башлады.

Шул ук вакытта, 2018 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил республиканың 25 районында опека һәм попечительлек органнарының тәрбиягә алынган балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлү эшчәнлегенә тикшерү уздырды.

Тәрбиягә алынган балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәүне тәэмин итүдә җитди хокук бозулар ачыкланды, шул исәптән:

опекага алынган балаларның акчалары сакланышын тәэмин итү (инвалидлык буенча пенсия, караучысын югалту буенча пенсия акчаларын контрольсез алу һәм тоту);

опекага алынган балаларның мөлкәте сакланышын тәэмин итү;

тәрбиягә алынган гаиләләрдә балигъ булмаганнарның тормыш һәм тәрбия шартлары тиешенчә булмау;

торалары булмаган опекадагы балаларны махсус торак фондыннан торак белән тәэмин итү өчен яңа ата-аналары тарафыннан исәпкә кую буенча системалы эшнең башкарылмавы;

каникул вакытларында тәрбиягә алынган балаларның ялын һәм сәламәтлеген оештыру мәсьәләләренә тиешле контроль һәм игътибар булмау;

дәрестән тыш вакытта өстәмә белем бирү системасында балаларның мәшгульлеген тәэмин итүгә тиешел контроль булмау;

опекадагы балигъ булмаган баланың мөлкәтен саклау, куллану һәм андый мөлкәт белән эш итү турында тиешле (дөрес) хисап булмау.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визитлары кысаларында ачыкланган хокук бозылу фактлары буенча бу проблеманы муниципаль берәмлек башлыгы (башкарма комитеты җитәкчесе) белән фикер алышу оештырылды, бу мәсьәлә балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең киңәйтелгән утырышында каралды, хокук бозуларны кылган муниципаль районнар башлыклары адресына балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре ләре бозылу турында сбәяләмәләр җибәрелде, бу хакта республика (район) прокуратурасына хәбәр ителде.

Моннан тыш, ел дәвамында, районнарда эшләүдән тыш, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил берничә мәртәбә республиканың опека һәм попечительлек органнары алдында (Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе утырышында, 19 сентябрьдә), мәгариф хезмәткәрләренең август киңәшмәсенең опека һәм попечительлек өлкәсендә эшләүче белгечләр өчен секция утырышында (29 июньдә), опека һәм попечительлек органнары хезмәткәрләре өчен квалификация күтәрү курсларында (30 октябрьдә) чыгыш ясады.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил опека һәм попечительлек органнары эшчәнлегендә ятим балалар хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең системалы бозылуын булдырмауны тәэмин итү буенча өстәмә чаралар комплексын кабул итү буенча уртак эшне дәвам итәргә кирәк дип саный.

Шул ук вакытта, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне эшләргә кирәк дип саный:

муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә үтәүне тәэмин итәргә, шул исәптән балалар хокукларын яклау буенча белгечләрне муниципаль хезмәткәрләр итеп билгеләүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына өстәмә чаралар кабул итәргә:

Бала алган ата-аналар мәктәбендә укулар узу кысаларында ата-ана булу өчен кандидатлар әзерләү дәрәҗәсен күтәрү буенча;

опека һәм попечительлек органнарының ата-ана булу өчен кандидатлар әзерләүдә нәтиҗәле һәм профессиональ эшли торган система булдыру һәм ятим баланы тәрбиягә алган гаиләне күзәтеп тору эшчәнлеген камилләштерү буенча;

ата-ана булу өчен кандидатлар булып узу өчен ата-аналарның алынган балаларны тәрбияләү буенча үзенә җаваплылык алу әзерлегенә һәм сәләтенә ата-аналар компетенцияләренә алдан психологик тест уздыру, аның нәтиҗәләрен гражданның опекун булу мөмкинлегенә бәяләмә биргәндә исәпкә алырга;

урыннарда опека һәм попечительлек органнары белгечләренең, шул исәптән опека һәм попечительлек органнарының яңа билгеләнеп куелган хезмәткәрләренең (алар вазыйфага билгеләнеп куелган көннән өч айдан да соңга калмыйча) һөнәри компетенцияләре дәрәҗәсен күтәрү эшчәнлегенә методик ярдәм итү буенча (шул исәптән квалификация күтәрү курсларын (уку семинарларын) уздырырга);

республиканың тәрбиягә балалар алынган гаиләдә яшәүче ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга аларга карата көч куллану һәм мәрхәмәтсез булу фактларын ачыклау өчен бәйсез психологик тест уздыру буенча (балалар йортларында һәм социаль приютларда тәрбияләнүчеләргә карата уздырыла торган тест кебек);

муниципаль опека һәм попечительлек органнарының эшчәлегенә контроль буенча (системалы хокук бозулар барлыкка килүгә бәйле барлык опека һәм попечительлек органнарына тикшерү уздырырга, алга таба моны план тәрибендә эшләргә);

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләренә:

гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларны укыту, өстәмә һәм һөнәри белем бирүне дә кертеп, аларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру, аларга медицина һәм социаль хезмәт күрсәтү буенча ведомствоара эшчәнлекне тәэмин итәргә;

комиссия утырышларында муниципаль районның опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеге мәсьәләләрен даими рәвештә карарга.


### *3.4.3. Баланың гаиләгә хокукын гамәлгә ашыру проблемалары һәм, гаиләдә каршылыклар булганда, гаилә эчендәге бәйләнешләр*

Гражданнарның мөрәҗәгатьләре буенча ел саен уздырыла торган анализ балаларны тәрбияләү буенча бурычларны һәм хокукларны бүлү уңаеннан ата-аналар бәхәсләре килеп чыкканда балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауның актуаль булуын күрсәтә. Мондый хәлләр еш кына ата-аналар аерым яшәгәндә йә аерылышканда килеп чыга.

2015 елдан балаларның гаилә элемтәләренә хокукларын яклау буенча мөрәҗәгатьләр саны артуы күзәтелә. 2018 ел йомгаклары буенча гомуми шикаятьләр арасында мондый мөрәҗәгатьләр 21% тәшкил итә. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 2018 елда гражданнар мөрәҗәгать иткән актуаль мәсьәләләр рейтингында әлеге тематика икенче урында тора.

80 нче диаграмма

***2014 – 2018 елларда балаларның гаиләгә һәм гаилә эчендәге бәйләнешләргә булган мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре динамикасы***



Узган ел баланың гаиләгә һәм гаилә бәйләнешләренә хокукларын яклау мәсьәләләре буенча 440 мөрәҗәгатьтән 182 (41%) балаларның ата-аналары аерылышу йә аерым яшәүләре аркасында барлыкка килә торган бәхәсле хәлләрне хәл итүгә ярдәм итүне үтенеп бирелгән:

баланың яшәү урынын билгеләү буенча;

балаларны ата-аналарның тоту тәртибен билгеләү;

баланың аерым яши торган ата-анасы белән аралашу тәртибен билгеләү;

баланың башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү;


бала белән аралашуга тоткарлыкларны бетерү.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең саны 2017 елга караганда 22%ка артты.

Соңгы елларда аерылышулар статистикасыннан күренгәнчә, өйләнешкән парларның яртысы диярлек аерылыша. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе белешмәләре буенча 2018 елда 1000 өйләнешүченең 540ы аерылышкан (2017 елда – 503 аерылышу).

*81 нче диаграмма*

***2014–2018 елларда Татарстан Республикасында теркәлгән язылышулар һәм аерылышулар динамикасы***




2018 елда аерылышу вәзгыятен ата-аналары бергә 10 596 бала кичерде 2017 елда – 10 709 бала, 2016 елда – 9 511 бала). Мондый балаларга үз вакытында психологик ярдәм күрсәтү һәм тормышларына үзгәрешләр кертү таләп ителә. Кызганычка каршы, ата-аналар балаларына нинди көчле психик зарар китүләрен, кагыйдә буларак, тиешенчә аңлап бетермиләр һәм профессионал психологлар ярдәмен сорап мөрәҗәгать итүне кирәксенмиләр.

Бүгенге гаилә законнары гаиләнең үз эчке тормышындагы хәлләрне мөстәкыйль хәл итү, ата-ана хокукларын намуслы һәм ихтыярый гамәлгә ашыру презумциясенә, һәр гаиләнең баланы тәрбияләү, укыту һәм үстерү, аның сәламәтлеген саклау өчен җаваплы булу принципларына нигезләнә.

Кызганычка каршы, барлык гаиләләр дә тәрбияләүдәге бәхәсле мәсьәләләрне хәл итәргә сәләтле түгел, еш кына бу судка кадәр барып җитә

Мәсәлән, Татарстан Республикасы Югары суды белешмәләренә караганда, 2018 елда гомуми юрисдикциядәге судларда баланың яшәү урынын билгеләү буенча 298 балигъ булмаган балага карата 221 эш каралган (2017 елда – 240 эш, 303 балигъ булмаган балага карата).

Моннан тыш, Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе белешмәләре буенча, 2018 елда яшәү урынын билгеләү буенча суд карарларын мәҗбүри үтәтү буенча суд приставлары үтәтүендә 11 эш булган.

Татарстан Республикасы Югары суды белешмәләре буенча, 2018 елда гомуми юрисдикция судларында баланың аерым яшәүче ата-аналары һәм башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләүдә бәхәсле мәсьәләләр буенча 493 балигъ булмаган балага кагылышлы әлеге категориягә кергән 397 эш каралган. (2017 елда – 373, 457 балага карата). Әмма баланың ата-аналары белән суд тәртибендә билгеләнгән аралашу тәртибе тормышта еш кына үтәлми.

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе белешмәләре буенча, 2018 елда баланың аерым яшәүче ата-аналары һәм башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү буенча суд карарларын мәҗбүри үтәтү буенча суд приставлары үтәтүендә 225 эш булган.

Күренеп тора, һәр шундый суд процессы артында балаларның чын фаҗигасен күрәбез.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, ата-аналар аерылышканда яисә аерылышу куркынычы булганда, гаиләләргә консультация рәвешендә психологик һәм хокукый ярдәм күрсәтү максатларында, республикада дәүләт (муниципаль) гаилә гаилә консультацияләре челтәрен булдыру мәсьәләсен карарга кирәк.

Моннан тыш, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил күрсәтмәләренә дә карамастан, ата-аналарның берсе яисә башка туганнары белән аралашуга баланың хокукын бозучы ата-аналарга өстәмә тәэсир итү күзлегеннән чыгып, мондый ата-аналарны административ җаваплылыкка тарту буенча балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең эш практикасы җитәрлек түгел. Баланы ата-аналары белән һәм якын туганнары белән аралашудан мәхрүм иткән өчен каралган административ җаваплылыкка тарту буенча өстәмә чаралар карала, ул әлеге норманың гамәлдә булуы шулай ук балаларны, аларның ирегенә каршы килеп, тору урынын махсус яшерү, балаларның яшәү урыннарын билгеләү турында суд карарын үтәмәү очракларына, шул исәптән суд карары закон көченә кергәнче балаларның яшәү урынынын билгеләү турындагы карарга һәм башка очракларга кагыла. Баларның тәрбиягә һәм белем алуга, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга хокукларын ата-аналары тарафыннан суд карары закон көченә кергәнче гамәлгә ашыру тәртибен бозган өчен яисә аны үтәүгә тоткарлык тудырган өчен җаваплылык карала. (Бу җаваплылык Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларында каралган).

2018 елда балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе белешмәләре буенча, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы буенча 10 923 ата-ана (законлы вәкилләр) җаваплылыкка тартылган (2017 елда – 15 190), шулардан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясындагы 2 өлеше нигезендә – 33 кеше (2017 елда – 14 кеше) (Түбән Кам а районында – 15 кеше, Казан шәһәрендә – 14 кеше, Чаллы, Баулы, Зеленодольск, Лаеш районнарында берәр кеше). Калган районнарда баланың ата-ана һәм башка якын туганнар белән аралашу хокукын бозган ата-аналарга карата әлеге административ җәза чарасы кулланылмаган.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне **тәкъдим итә:**

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә Россия Федерациясендә Административ хокук бозулар Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясындагы 2 пункты нигезендә баланы ата-аналары белән һәм якын

туганнары белән аралашудан мәхрүм иткән өчен каралган административ җаваплылыкка тарту практикасын киңәйтергә һәм активлаштырырга кирәк дигән мәсьәләне карарга;


опека һәм попечительлек органнарына бала белән аралашу тәртибен билгеләү турындагы мәсьәләләрне эшләгәндә бу юнәлештәге эшләрне балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә җибәрүне карарга.

***Чит ил гражданнары белән аерылышканда*** яисә аерым яшәгәндә балаларның яшәү урыннарын билгеләү һәм ата-ана хокукларын, бурычларын үтәү тәртибе бозылу турындагы бәхәсле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибар үзәгендә булды. Төрле дәүләтләрнең гражданнары – ир белән хатын аерылышу (аерым яшәү) вәзгыятендә балигъ булмаган балаларны опекалауга карата мәсьәләләрне хокукый җайга салу шактый катлаулы һәм ул үз эченә халыкара законнар нормаларын һәм төрле илләрнең милли хокукларын үз эченә ала. Әмма һәр конкрет очракта илнең милли законнары хокукый нормаларының һәм халыкара хокук нормаларының нисбәте индивидуаль карала. Бәхәсләр килеп чыкканда хокукый җайга салуның катлаулылыгы ир белән хатынны да, аларның уртак балаларын да авыр хәлгә куя.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе белешмәләре буенча, 2016 елдан башлап республикада Татарстан Республикасы территориясендә чит ил гражданнары белән өйләнешүне теркәгән актлар саны кимүшгә таба бара. Мәс., 2016 елда Татарстан Республикасында чит ил гражданы белән өйләнешү өйләнешү турында 1 350 акт теркәлгән, 2017 елда – 1138, 2018 елда – 1116. Шулай булса да, чит ил гражданнары белән өйләнешү республикада популяр булып кала.

*82 диаграмма*

***2014 – 2018 елларда чит ил гражданнары белән өйләнешүләр саны***




Чит ил гражданы белән аерылышканда яисә алар аерым яшәгән очракта баланың яшәү урынын билгеләү буенча юридик консультация һәм бәхәсле мәсьәләне хәл итүдә ярдәм итүне сорап, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 2018 елда Төркия, АКШ, Греция, Италия, Эквадор гражданнары белән өйләнешкән гражданнар яисә аларның якын туганнары мөрәҗәгать итте.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, өйләнешүчеләрнең берсе чит ил гражданы булган яшьләргә, шулай ук аларның ата-аналарына шул илләрнең гаилә мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу үзенчәлекләрен аңлату мәсьәләсе буенча республиканың ЗАГС органнары каршында ***консультация ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы тәкъдимнәр бүген дә актуаль***, дип саный

## 3.5. Баланың белем алу өлкәсендә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү

### *3.5.1. Мәктәпкәчә белем*

2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү системасында 2 008 мәгариф оешмасы эшли, аларда 224 300 бала тәрбияләнә, шул исәптән:

1 762 муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасы (аларда 214 682 бала);

34 дәүләтнеке булмаган мәгариф оешмасы (аларда 3 507 бала).

2011 елдан башлап республикада мәктәпкәчә өстәмә урыннар булдыру буенча Президент программасы гамәлгә ашырыла, ул мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә чиратны бетерү һәм балалар бакчаларында урыннарга кытлык проблемасын хәл итү өчен кертелде.

2012 елдан алып 2018 елга кадәрге чорда гына да Татарстанда балалар бакчаларында 48 мең яңа урын булдырылды, 211 яңа балалар бакчасы төзелде. 2018 елда гына да әлеге программаны гамәлгә ашыру кысаларында 805 урынлы 8 яңа мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төзелде. Моннан тыш, 2012 елдан алып 2018 елга кадәрге чорда 267 балалар бакчасы төзекләндерелде, шуның 94е – 2018 елда.

Күрелә торган чаралар 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларны мшктәпкәчә оешмаларга урнаштыру мәсьәләсен хәл итәргә ярдәм итте диярлек. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, 2018 елда өч яшьтән зуррак булган балалар чираты 884 кешегә тиң булды. Шуны искәртергә кирәк, бу балаларга мәктәпкәчә оешмаларда урын җитми дигән сүз түгел, башка бакчада урын тәкъдим ителеп, аның белән ата-аналары ризалашмаган балалар саны бу. Шундый проблема түбәндәгечә саклана:

Казан шәһәрендә (758 бала, ягъни 86%),
Әлмәт муниципаль районында (38 бала),
Чаллы шәһәрендә (30 бала),
Биектау муниципаль районында (14 бала),
Лаеш муниципаль районында (12 бала),
Арча муниципаль районында (8 бала),
Түбән Кама муниципаль районында (7 бала),
Питрәч, Минзәлә, Кукмара Зеленодольск муниципаль районнарында (4әр бала),
Алабуга муниципаль районында (1 бала).

Республиканың калган районнарында 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларның балалар бакчасына чираты юк.

***1,5 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге балалары булган гаиләләр өчен балалар бакчаларында урыннарның җитмәве аеруча актуаль проблема*** булып тора. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, 2019 елның 1 гыйнварына – бу категория яшьтәге балалар чираты 14 329 кеше, ягъни барлык чираттан 94% тәшкил иҗә. 1,5 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге балаларга урын бирү буенча киеренелек түбәндәгечә чагыла:

Казан шәһәрендә (8 637 бала);
Чаллы шәһәрендә (2 892 бала);
Әлмәт муниципаль районында (1 126 бала);
Түбән Кама муниципаль районында (414 бала);
Зеленодольск муниципаль районында (331 бала);
Биектау муниципаль районында (193 бала);
Лаеш муниципаль районында (188 бала);

Арча муниципаль районында (164 бала);

Питрәч муниципаль районында (124 бала);

18 районда чиратлылык 50 кешедән кимрәк.

Республиканың калган районнарында чират юк.

2018 елда балалар бакчасында урын алуда ярдәм итүне сорап, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 96 мөрәҗәгать керде. 2017 ел белән чагыштырганда мондый шикаятьләр 21%ка кимрәк (2017 елда – 122). Шулардан 46 мөрәҗәгатьтә (48%) өч яшькә кадәрге балаларны бакчага урнаштыруда ярдәм итүне сорап язылган иде. Тикшерүләр барышында, шул исәптән күчмә рәвештә, «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләренә (балалар бакчаларына) гаризалар алу, исәпкә кую һәм балаларны урнаштыру» муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентын «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы электрон базасында балалар бакчаларын комплектлаганда чират өлешендә хокук бозу очраклары табылмады.

Татарстан Республикасында балалар бакчаларында өстәмә урыннар булдыру программасын гамәлгә ашыру дәвам итә, төп игътибар 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балаларны урнаштыруга юнәлтелә.

Игътибар ителә торган тагын бер мәсьәлә – районнарда балалар төркемнәрен, аларның яшьләренә карап, ***комплеклау тәртибенең үтәлеше.***

«Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләренә (балалар бакчаларына) гаризалар алу, исәпкә кую һәм балаларны урнаштыру» муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентын раслау турында муниципаль районнарның башкарма комитетлары карарлары нигезендә (алга таба – карарлар) балаларны чираттагы уку елына комплектлау агымдагы елның 1 апреленнән 30 июненә кадәр бушаган урыннан саны буенча башкарыла. «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасының электрон базасында балалар яше, гадәттәгечә, агымдагы елның 1 сентябренә исәпләнә.

Шулай итеп, агымдагы елның сентябреннән декабренә кадәр 3 яше тула торган балаларның бер өлеше аларга 3 яшь тулган елда балалар бакчасына алынмый һәм алар соңрак, 3 яшь тулып узганнан соң гына балалар бакчасына бара алалар. Шуны әйтергә кирәк, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләрнең күпчелегендә мондый тәртип белән килешмәү бәян ителә. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил моны нигезле дип саный.

Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү максатларында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы муниципаль районнары башлыкларына югарыда күрсәтелгән карарларга үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карарга һәм балалар бакчаларына балаларны комплектлаганда аларның яшен 31 декабрьгә кадәр алырга кирәк, дип саный.

Хәл итүне таләп итә торган тагын проблеманың тагын берсе – балалар бакчаларында аерым шартлар тудыруны таләп итә торган ***авыру балаларның мәктәпкәчә белем алу хокукын*** гамәлгә ашыру.

Мондый балалары булган гаиләләр бүген җитди проблемалар кичерәләр. Болар мәктәпкәчә балалар оешмаларында имин һәм уңайлы шартлар булдыруга кагылышлы проблемалар. Эш шунда, бер типтагы мәктәпкәчә балалар учреждениеләре, аларның хезмәткәрләре, мәс., шикәр диабеты, фенилкетонурия, балалар гомере куркыныч булган башка ферментлы авырулары булган балаларны бакчага алуга һәм алар белән эшләүгә әзер түгел (диетик (махсус) туклану оештырылмаган, хезмәткәрләр бу авыруларның

бала өчен ни дәрәҗәдә куркыныч булуыннан хәбәрдар түгел, көн дәвамында баланың үзтотышын күзәтеп торырга кирәклегенә өйрәтелмәгәннәр һ.б.лар). шул ук вакытта, бу балалар башка балалар белән беррәттән мәктәпкәчә белем алырга хокуклы.

2018 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә шикәр диабеты, фенилкетонурия белән авыручы балаларның мәктәпкәчә белем алу хокукларын гамәлгә ашыру вәзгыятьләре белән очрашырга туры килде. Бу хакта гражданнардан мөрәҗәгатьләр керде. Аларны карау барышында, махсус тукландыруны оештыру мөмкинлеге булмауга бәйле, балалары «фенилкетонурия» белән аврый торган ата-аналарга балаларын тулы булмаган көн шартларында йөртергә тәкъдим ителгәнлеге ачыкланды. Бу проблеманы балалар мәнфәгатьләрендә хәл итү 2018 елның 17 маенда һәм 12 июлендә узган Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Координация комитеты һәм түбәндәгеләрнең ведомствоара нәтиҗәле хезмәттәшлек итүе мисалында күренә: Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе, казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе һәм «Казан шәһәренең Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» МУП. Барлыкка килгән проблеманы бергәләп карау нәтиҗәсендә «Казан шәһәре Совет районының 135 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» МАБМУ (МАДОУ) базасында фенилкетонурмя белән авыручы балалар өчен махсус дәвалау-савыктыру чаралары буларак аерым балалар төркемен оештыру турында карар кабул ителде.

Барлык очракларда да мәсьәләләр балалар бакчасына йөри башлаган балалар мәнфәгатьләрендә хәл ителде.

Республикада шикәр диабеты белән авыручы балалар белән эшләү буенча Казан һәм Чаллы шәһәрләре балалар бакчаларында уңай тәҗрибәсе тупланган. Мәсәлән, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Баланы үстерү үзәге – 16 нчы балалар бакчасы» МАБМУендә уңай практика урнашкан. Шул ук вакытта, шикәр диабеты белән авыручы балалар вәзгыятен истә тотып, мәктәпкәчә белем ошмаларында аларның сәламәтлеге өчен имин һәм уңай белем алуга хокукларын тиешенчә тәэмин итү максатларында, бүген республиканың һәр муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә ферментлы авырулар белән авыручы балалар өчен махсуслаштырылган төркемнәр оештыру ихтяҗы бар. Авыруның үзенчәлеген исәпкә алып, бу чара медицина персоналыннан, тәрбиячеләрдән (кече тәрбиячеләрдән) һәм кухня хезмәткәрләреннән өстәм штат туплауны таләп итә.

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» ДБУ белән берлектә әлеге мәсьәләне карарга һәм махсуслаштырылган мәктәпкәчә төркемнәр төзү турындагы тиешле тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә кирәк, дип саныйбыз.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил игътибарына тагын бер четерекле мәсьәлә алынды, бу – ***мәктәпкәчә гаилә төркемнәренең эшчәнлеге***.

Мәктәпкәчә гаилә төркемнәренең эшчәнлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен оештыру турында» 2017 елның 20 июнендәге 399 номерлы карары белән расланган Үрнәк нигезләмә белән регламентлаштырылган. Мәктәпкәчә гаилә төркемнәре мәктәпкәчә белем бирүнең әлеге вариатив рәвешен үстерү, иң күп урыннар соралган 3 яшькәчә һәм сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларга мәктәпкәчә белем бирүне тәэмин итү вазыйфасын үз өстенә алып, балалар бакчаларында урыннар җитмәү мәсьәләсен хәл итү өчен төзелергә

тиеш. Моннан тыш, мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен үстерү күпбалалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең нәтиҗәле чарасы буларак һәм күпбалалы тәрбияче аналарны эш белән тәэмин итүнең үзенчәлекле төре буларак каралырга тиеш. Гаиләнең яшәү урыны буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашырга очракта, гаилә төркеме структур бүлекчәсе булып тора торган белем бирү оешмасының лицензиясенә шул адресларны кертергә кирәк булачак. Мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен финанслау муниципаль белем бирү оешмаларын тотуга каралган бюджет акчалары кысаларында гамәлгә ашырыла.

Мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен оештыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең позициясе түбәндәгечә чагыла, мәктәпкәчә гаилә төркемнәре челтәрен төзү:

өч яшьтән зуррак булган һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны балалар бакчаларында урыннар белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итәргә тиеш;

күпбалалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең нәтиҗәле чарасы буларак һәм күпбалалы ананы-тәрбиячене эш белән тәэмин итүнең үзенчәлекле рәвеше буларак каралырга тиеш;

Россия Федерациясендә демографик сәясәтне гамәлгә ашыруга ярдәм итәчәк.

Шул ук вакытта, ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Казанда мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен ачудагы һәм гамәлдәге гаилә төркемнәре ябудагы проблемалар буенча мөрәҗәгатьләр килде.

Чылап та, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы белешмләре буенча, 2016 елдан республикада мәктәпкәчә гаилә төркемнәренең кимүе күзәтелә: 2014 елда – 48 булса, 2018 елда елда 23кә калган. Казан шәһәрендә бу мәсьәлә бик кискен тора.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мәктәпкәчә гаилә төркемнәре эшчәлегенең мәсьәләсен карарга һәм аларның эшчәнлеген гамәлдәге законнар нигезендә тәртипкә салу буенча чаралар күрергә кирәк, дип саный.

### *3.5.2. Гомуми белем бирү*

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча Татарстан Республикасында 2018/2019 нчы уку елында 1 402 гомуми белем бирү оешмасы бар, шул исәптән:

республикада 1 387 дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү мәктәпләре һәм интернат мәктәпләр бар (414 821 кеше), шулардан 241ендә (17%) югары дәрәҗәдә белем бирү программалары гамәлгә ашырыла (183 979 кеше);

дәүләткә карамаган 15 мәктәп бар (2 069 кеше).

*21 нче таблица*

***2018 елда Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары челтәре***


| Белем бирү оешмаларының төрләре | Мәктәпләр саны, бер. | Аларда укучы балалар саны, кеше |
|---|---|---|
| **Дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү мәктәпләре һәм интернат мәктәпләр** | **1 387** | **414 821** |
| башлангыч мәктәпләр | 102 | 4 893 |
| төп мәктәпләр | 352 | 17 323 |
| урта мәктәпләр | 865 | 382 269 |
| **Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү оешмалары** | 52 | 7 964 |

| | | |
|---|---|---|
| шифаханә тибындагы интернат мәктәпләр | 2 | 220 |
| башка министрлыкларга караган мәктәпләр | 2 | 166 |
| кечке мәктәпләр | 11 | 1 935 |
| девиант холыклы балалар өчен махсус мәктәп | 1 | 51 |
| **Дәүләткә карамаган мәктәпләр** | **15** | **2 069** |

Статистика хисабы белешмәләре буенча, 2018/2019 нчы уку елында 2013-2017 еллардагы демографик үсеш нәтиҗәсендә дәүләт (муниципаль) көндезге гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның саны 3,4%ка артты, укучылар саны 412 886га җитте.


*83 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда Татарстан Республикасының көндезге дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмаларында укучылар санының үзгәрү динамикасы (кеше)***




*84 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда Татарстан Республикасында шәһәр һәм авыл мәктәпләре нисбәте***




Шәһәр гомуми белем бирү оешмалары – 535 мәктәп, авылныкы – 864.

*85 нче диаграмма*

***2014 – 2018 елларда Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмалары челтәре***




2018-2019 елларда гомуми белем бирү оешмалары челтәренең үсүе урта мәктәпләрне арттыру исәбенә төп һәм башлангыч мәктәпләр санының кимүе белән аңлатыла.

2018 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан гомуми белем алуны гамәлгә ашыру өлкәсендә түбәндәге проблемалы мәсьәләләр ачыкланды.

***Беренчедән,*** Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне ***мәктәпләрдә белем бирү процессында катнашучылар арасындагы каршылыклы вәзгыятьләр мәсьәләләре*** буенча ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) кергән мөрәҗәгатьләр аеруча борчый. 2018 елда 123 мөрәҗәгать керде, бу балаларның белемгә хокукларын яклау темасы буенча кергән барлык мөрәҗәгатьләрнең һәр бишенчесен тәшкил итте. Әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгатьләр саны 2017 ел белән чагыштырганда 17%ка артты.

2018 елда гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча үткәрелгән тикшерү йомгакларыннан күренгәнчә, белем бирү процессын тиешенчә оештырмау, тәрбияләүнең педагогик булмаган алымнарын куллану, балигъ булмаган баланы сәламәтлегенә зыян салырлык психик халәткә китерү кебек хокук бозулар түбәндәге 17 белем бирү оешмасында ачыкланды:

***мәктәпкәчә белем бирү оешмалары:***

Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авылында «Солнышко» муниципаль бюджет дәүләт мәгариф учреждениесе (МБДМУ);

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «89 нчы сабыйбалаларны үстерү үзәге» муниципаль бюджет дәүләт мәгариф учреждениесе (МБДМУ);

Казан шәһәре Мәскәү районының «207 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автоном дәүләт мәгариф учреждениесе (МАДМУ);

***гомуми белем бирү оешмалары:***

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен «4 нче Казан интернат мәктәбе» ДБМУ;

Казан шәһәре Яңа Савин районының «177 нче лицее» МБМУ

Казан шәһәре Киров районының «57 нче рус-татар гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Совет районының «181 нче күппрофильле мәктәбе» МБМУ

Казан шәһәре Совет районының «157 нче гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Киров районының «32 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәренең 6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Баулы муниципаль районының «7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Түбән Кама муниципаль районының «29 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Чаллы шәһәренең «56 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль районы автоном мәгариф учреждениесе (МАМУ);

***балаларга өстәмә белем бирү оешмалары:***

Чистай шәһәренең «Боз спорт сарае» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү буенча муниципаль бюджет учреждениесе;

Чаллы шәһәренең «13 нче балалар сәнгать мәктәбе (татар)» балаларга өстәмә белем бирү буенча муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәре Идел буенч районының «8 нче балалар музыка мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү буенча муниципаль бюджет учреждениесе;

***һөнәри белем бирү оешмалары:***

Татарстан Республикасында «Муса Җәлил ис. Минзәлә педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан мөрәҗәгатьләрне карау йомгаклары буенча белем бирү оешмалары директорларына һәм гамәлгә куючыларына баланың хокуклары һәм законды мәнфәгатьләре бозылу турында 18 бәяләмә җибәрелде.


Белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликтлар булуга бәйле мөрәҗәгатьләр саны шактый күп булуны истә тотып, мәктәпләрдә квалификацияле психологик ярдәм хезмәтләрен оештыру аерым әһәмияткә ия.

Шул ук вакытта, 2018/2019нчы уку елында республикада психологик-педагогик ярдәм инфраструктурасында үзгәрешләр күзәтелми. 2018/2019 нчы уку елында белем бирү оешмаларында 6 психологик-педагогик медик-социаль үзәге һәм 19 муниципаль психологик-педагогик хезмәт эшли, белем бирү системасында 492 педагог-психолог эшли.

Кызганычка каршы, бүген республиканың 1402 гомуми белем бирү оешмасының 390ында гына (27%) педагог-психологлар эшли.

*86 нчы диаграмма*

***2014 – 2018 елларда гомуми белем бирү оешмаларында психологик ярдәмнең торышы***




Педагог-психологлар хезмәтләреннән файдалану мәсьәләсе бигрәк тә авыл җирлегендә кискен тора.

2018 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Тәтеш муниципаль районыннан сәламәтлеге чикле балалары булган ата-аналардан килгән күмәк мөрәҗәгатьне тикшерде. Анда Тәтеш шәһәрендәге «Радуга» педагог-психолог хезмәтен бүлдыру кирәклеге турында язылган иде. Тәтеш муниципаль районында педагог-психолог хезмәте Урюм авылында урнашкан, аның Тәтеш районыннан ерак булуы мондый хезмәтләргә ихтыяҗы булган кешеләрне файдаланудан чикли. Бу мәсьәләне Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Тәтеш муниципаль районы башлыгы белән бергә карап, бу үзәкне Тәтеш шәһәрендә урнаштыру турында карар кабул ителде. Бүгенге көндә «Радуга» педагог-психолог хезмәте Тәтеш муниципаль районының «Советлар Союзы Герое Ханжин Павел Семенович ис. 1 нче Тәтеш урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ базасында эшли. Бу тиешле хезмәтләрдән файдалануны шактый яхшыртты. Шулай итеп, бу мәсьәлә балалар мәнфәгатьләрендә уңай хәл ителде.

Мәктәп конфликтларының сакланып калуы, гражданнар мөрәҗәгатьләренең артуы, кызганычка каршы, бер яктан, барлыкка килә торган мәсьәләләрне хәл итүдә белем бирү оешмалары администрациясенә ышанычны югалтуны күрсәтә, икенче яктан – мәктәп (балалар бакчасы) дәрәҗәсендә күрелә ителә торган чаралар канәгатьләндермәгәнне аңлата йә учреждение администрациясе (сыйныф җитәкчесе) тарафыннан мондый вәзгыятьнең игътибар сыз калуын һәм тиешле чаралар күрелмәвен күрсәтә.

Шуңа бәйле рәвештә, республика мәктәпләрендә психиканы җәрәхәтли торган конфликтлар барлыкка килүне профилактикалау максатларында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, тирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк, дип саный:

белем бирү оешмаларында төрле конфликт вәзгыятьләрне булдырмас өчен педагогларның, педагог-психологларның, мәктәп директорларының һөнәри компетенцияләре дәрәҗәләрен күтәрү буенча чаралар күрергә;

белем бирү оешмаларының, белем бирү өлкәсендә муниципаль оешмаларның эшчәнлеген бәяләү кысаларында, белем бирү оешмалары эшчәнлегенә карата ата-аналарның дәлилле шикаятьләренең, шул исәптән прокуратура, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, башка контроль-күзәтчелек органнары адресына җибәрелгән шикаятьләрнең торышын анализларга һәм тиешле идарәчел карарлар кабул итәргә;

мәгариф оешмалары җитәкчеләре катнашында муниципаль районнар башлыклары (муниципаль районнарның башкарма комитетлары җитәкчеләре)уздыра торган киңәшмәләрдә хокук бозулар турындагы бәяләмәләрне карау практикасын кертергә;

муниципаль берәмлекләрдә (шәһәр округларында) һәм белем бирү оешмаларында педагог-психолог хезмәтләрен үстерү буенча, аларның эшчәнлеген арттыру буенча системалы эшне дәвам итәргә;

штатта педагог-психологлар булмаган гомуми белем бирү оешмаларында, һөнәри белем бирү оешмаларында балигъ булмаганнарга психолог ярдәме күрсәтүне оештыру буенча чаралар күрергә;

белем бирү оешмалары каршында белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасындагы бәхәсләрне җайга салу һәм аларның формаль булмаган режимда эшләүләрен оештыру буенча комиссияләр төзүгә юнәлдерелгән нәтиҗәле чаралар комплексын кабул итәргә;

педагоглар һәм балалар арасында низаглар булдырмау буенча эшне дәвам итәргә.

***Икенчедән,*** гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлаудан чыгып караганда, ***укучыларны белем бирү оешмаларына илтеп җиткерүне оештыру мәсьәләләре*** дә актуаль булып кала.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон нормалары нигезендә төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүче муниципаль белем бирү оешмаларында укучыларны җирлкләр арасында транспорт белән тәэмин итү (укучыларны белем бирү оешмаларына илтеп җиткерүне һәм аннан кайтаруны оештыру) тиешле оешмаларның гамәлгә куючылары, ягъни муниципаль хакимият органнары тарафынан башкарыла.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатьтә балаларны мәктәпкә транспортта йөртү турында куелган мәсьәләне ахырына кадәр хәл итә. мәс., 2016 елдан бирле Актаныш муниципаль районының Иске Бикчәнтәй авылы кешеләренең күмәк мөрәҗәгате Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым контролендә тора. Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәгълүматы буенча, авылда башлангыч мәктәп юк, балаларны башка авылга илтү оештырылмаган, чөнки иминлек таләпләренә җавап бирә торган юллар юк. 2018 елда әлеге мәсьәлә, ниһаять, уңай хәл ителде, юл төзекләндерелде, балалар мәктәпкә йөртелә.

Шулай ук Зеленодольск муниципаль районында «Советлар Союзы Герое Н.Соболев ис. 2 нче Васильево урта мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә укучыларны һәм Казан шәһәренең «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балалар өчен 76 нчы мәктәп» шәһәр бюджет белем бирү учреждениеләрендә укучыларын китерү-кайтаруны оештыру мәсьәләләрен хәл итү өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар адресына мөрәҗәгатьләр юлланды (2017 ел мөрәҗәгатьләре буенча), алар да Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил контролендә тора. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматы буенча, Казан шәһәренең «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балалар өчен 76 нчы мәктәп» шәһәр бюджет белем бирү учреждениеләре укучыларын китерү-кайтару өчен 2019 елда автобус җибәреләчәк.

2018 елда Әгерҗе, Тәтеш, Биектау муниципаль районнарында, Казан шәһәренең Мәскәү районында укучыларны, шулай ук Түбән Кама муниципаль районы укучыларын гомуми белем бирү оешмаларына, дәрестән тыш төрле чараларга транспортта йөртү мәсьәләсе дә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил игътибарына эләкте.

Түбән Кама муниципаль районы укучыларын дәрестән тыш чараларга йөртү, Казан шәһәре Мәскәү районының «130 нчы урта гомуми белем бирүмәктәбе» МБМУ укучыларын, Әгерҗе муниципаль районының Үтәгән авылында балалар бакчасы-мәктәбенә йөрүчеләрне, Биектау муниципаль районының «Алат төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ укучыларын транспортта йөртү мәсьәләләре балалар ягына уңай хәл ителде.

Тәтеш муниципаль районының Ямбухтино авылындагы мкенче сыйныф укучылары ата-аналарының балаларын 2,5 км ераклыкта урнашкан «Алабирде урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУенә кадәр йөртү өчен транспорт булмау турындагы мөрәҗәгате дә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил контроленә алынды.

Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының 2010 елның 29 декабрендәге 189 номерлы карары белән расланган «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә уку шартларына һәм аны оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре» СанПиН 2.4.2.2821-10 һәм «Төзелеш климатологиясе» СНиП 23-01-99 нормалары нигезендә шәһәр гомуми белем бирү оешмаларына җәяүле юл башлангыч сыйныф укучылары өчен – 0,5 км.-дан артык булмаска тиеш, авыл гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен – 2,0 км.-дан артык түгел.

САНПиН тапләрен истә тотып, мәктәп балаларының иминлеген һәм сәламәтлеген кайгыртып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаганнарның хокуклары бозылган дип саный, шуңа бәйле рәвештә Тәтеш муниципаль районы башлыгы адресына бала хокукы бозылу турында һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү турында, баланың яшәү урыны буенча укыту өчен шартлар булдыруны тәкъдим итеп, бәяләмә җибәрде.

***Өченчедән,*** контроль-күзәтчелек эшчәнлеге кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ел саен балаларны гомуми белем бирү оешмаларына алудан баш тартуга карата ата-аналардан кергән шикаятьләрне карый.

Балаларның белемгә хокукларын гамәлгә ашыру һәм гражданнарга балалары 1 сыйныфка укырга керү мәсьәләләре буенча консультация ярәме күрсәтү өлкәсендәге системалы проблемаларны ачыклау һәм анализлау максатында, 2018 елның 19 февралендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында «кайнар линия» эше оештырылды.

«Кайнар линия» телефонына республиканың 7 муниципаль районыннан һәм ике шәһәр округыннан 105 мөрәҗәгать керде. Иң күр мөрәҗәгать Әлмәт шәһәре гражданнарыннан (65 мөрәҗәгать, барлык санна 62%) керде, аларда Әлмәт шәһәренең «25 нче урта белем бирү мәктәбе» МБМУенә бу мәктәптә буш урыннанр булмау сәбәпле 1 сыйныфка балаларны алудан баш тарту турында мәгълүмат иде.

Әлмәт шәһәреннән ата-аналар мөрәҗәгате Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравына алынды. Мөрәҗәгатьләрне Әлмәт муниципаль районы башлыгы белән бергә карау йомгаклары буенча мәсьәлә балалар мәнфәгатьләрендә уңай хәл ителде.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны 1 сыйныфка алу буенча «кайнар линия» аша кергән мөрәҗәгатьләр дә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравына алынып, уңай чишелеш тапты.

2018 елда ата-аналардан балаларын түбәндәге белем бирү оешмаларына 1 сыйныфка алудан баш тарту очракларына карата шикаятьләр керде:

Әлмәт шәһәренең «Татарстан нефтенең 70 еллыгы ис. 25 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Әлмәт шәһәренең «10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МАМУ;

«Сәламәтлеге чикле балалар өчен 142 нче Казан мәктәбе» ШБМУ;

Казан шәһәре Киров районының «182 нче политехника лицее» МБМУ;

Чаллы шәһәренең «25 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ.

Шуны әйтергә кирәк, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына балаларны мәктәпкә алу мәсьәләләре буенча кергән граждан мөрәҗәгатьләренең 96%ы уңа хәл ителде.

Шул ук вакытта, мөрәҗәгатьләрне карау кысаларында башлангыч, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча гражданнарны укырга алу тәртибен тупас бозу очраклары ачыкланмады. Моны Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы тарафыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең тиешле күрсәтмәләрен, шул исәптән «2017 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм баланың хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлеше турында» Вәкаләтле вәкил доклады йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 28 мартындагы ПР-110 номерлы Йөкләмәләр исемлегендә балаларны 1 сыйныфка алгандагы хокук бозуларны профилактикалау өлешендә билгеләнгән күрсәтмәләрне үтәү нәтиҗәсе дип карарга мөмкин. Бу юнәлештә Министрлык тарафыннан күрелгән чаралар нәтиҗәле булды.

9 нчы сыйныфны (гимназияләрне) тәмамлаучыларны ***10 нчы сыйныфка алу*** мәсьәләсе буенча гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр саны кимеде. 2018 елда ике мәгариф оешмасында бу өлкәдә хокук бозуга карата нибары 2 шикаять керде:

«Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов ис. Казан кадет интернат мәктәбе» ДБМУ;

Әлмәт шәһәренең «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МАМУ.

Бу мөрәҗәгатьләр буенча уздырылган тикшерү чараларыннан мәгариф оешмалары җирле актларының законнар таләпләренә туры килмәве ачыкланды.

***Мисал:*** *10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең «Укучыларны кабул итү, күчерү, аннан чыгару һәм кабат алу кагыйдәләре»н (алга таба – Кабул итү кагыйдәләре) җирле актын анализлау түбәндәгеләрне ачыклады.*

*«Укучыларны профильле сыйныфларга (төркемнәргә) кабул итү, алардан чыгару тәртибе»нең 2 бүлеге нигезендә профильле сыйныфларга (төркемнәргә) керүчеләрнең, аларда укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) уку процессын регламентлаучы документлар белән танышырга тиеш иде. Профильле сыйныфларны (төркемнәрне комплектлау, дәүләт (йомгаклау) аттестациясе нәтиҗәләрен профильле фәннәр буенча өлгерешне, аерым фәннәр буенча укытучыларның педагогика советы карарын, дәресләргә әзерлекнең психологик әзерлеге дәрәҗәсен, Портфолиода тупланган бәяләү нәтиҗәсен исәпкә алып, төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлап чыгучыларның, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) язма гаризасы нигезендә башкарыла.*

*Имтихан нәтиҗәләре төп мәктәпне тәмамлап чыгучыларның дәүләт (йомгаклау) аттестациясе өчен һәм профильле сыйныфлар булдыру өчен кулланыла. Укучыларны сайлап алу өчен профильле фәннәр буенча тәкъдим ителүче минималь балл: математика -20 балл, физика – 20 балл, химия -20 балл, биология -25 балл, табигать белеме -25 балл.*

*Шул ук вакытта аерым фәннәр укытучыларының күрсәтмәләрен барлыкка китерә торган «рейтинг бәясе», «тотрыклы өлгереш» критерийлары юк; дәресләргә психологик әзерлек дәрәҗәсе, Портфолиода тупланган бәяләү билгеләнмәгән.*

*Укучыларны индивидуаль сайлап алу критерийлары белем бирү оешмасын гамәлгә куючы буларак Әлмәт муниципаль районының башкарма комитеты белән килештерелмәгән.*

Ачыкланган хокук бозулар буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тиешле чаралар күрелде, нәтиҗәдә мәсьәләләр балигъ булмаганнар мәнфәгатьләрендә уңай хәл ителде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына, җирле үзидарә органнары белән берлектә, укучыларны профильле сыйныфларга алу турында гомуми белем бирү оешмаларының җирле актларын законнар таләпләренә яраклаштыру эшен дәвам итәргә, профильле сыйныфларга индивидуаль сайлап алу критерийларын тиешенчә эшләргә һәм аларны шушы гомуми белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар белән килештерергә тиеш.

***Дүртенчедән***, контрольно-күзәтчелек эшчәнлеге кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балаларны аларның гомеренә, сәламәтлегенә һәм (яисә) физик, психик, рухи, әүлакый үсешенә зыян китерә торган ***мәгълүматтан яклау өлкәсендә*** хокук бозулар ачыкланды. Әлеге вәзгыять турында тулырак мәгълүмат Докладның 3.2.3 «Тискәре мәгълүмат агымыннан яклау хокукын тәэмин итү» бүлегендә бәян ителде.

***Бишенчедән,*** 2018 елда республиканың муниципаль районнарына эш визитлары кысаларында гомуми белем бирү оешмаларын тикшергәндә, аларның матди-техник базасын анализлау барышында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аерым мәктәпләрдә ***физика һәм химия кабинетларының эше,*** аларның җиһазланышы, мәктәпләр администрациясе ягыннан контроль һәм гомумән уку кабинетларының һәм лабораторияләренең торышы белән танышты. Әлеге чаралар йомгаклары буенча кабинетларда тиешле җайланмаларның, махсус мәктәп җаһазының, тәҗрибәләр уздыру өчен реактивларның ачыкланды (гадәттә, тәҗрибәләр виртуаль үткәрелә).

***Мисал:*** *Әгерҗе муниципаль районының «Красноборский урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУендә физика һәм химия кабинетларының лаборатор эшләр һәм күргәзмә тәҗрибәләр үткәрү өчен кирәкле уку-лаборатор әйберләре белән җиһазланган булуы тикшерелде. Биредә химия кабинетының лаборант бүлмәсендә озак вакыт җыештырылмаган. Булган приборлар һәм препаратлар тузанланып беткән. Кайбер реактивларның сроклары чыккан. Химия кабинетындагы реактивларның саны уку барышында аларның кулланылмавын күрсәтә. Физика кабинетында да шундый ук хәл күренә.*

*Ачыкланган хокук бозулар «Красноборский урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ җитәкчеләре ягыннан үз оешмалары эшчәнлегенә контроль булмавын күрсәтә.*

*Зәй муниципаль районының «Югары Шәпке гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУендә биология кабинетында бары тик эшкә яраклы өч микроскоп бар, күргәзмә әсбаплар барысы да иске. Химия кабинетында да шөундый ук хәл, биредә бер штатив бар, реактивлары, пробиркалар минималь санда.*

*Югары Ослан муниципаль районының «Яр буе Морквашы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУендә физика кабинетында парталарга сузылган розеткалар эшләми диярлек, парталарның берсендә чыбыклар розеткадан читкә киткән, аларда эчке чыбыклар күренеп тора. Химии кабинеты химия тәҗрибәләре уздыру өчен уку-лаборатор әйберләре белән җиһазландырылмаган, лаборатор эшләр өчен реактивлар юк. Укытучы әйтүенчә, лаборатор эшләр бөтенләй үткәрелми. Химия кабинетында шулай ук ясалма яктыртуга карата СанПиН 2.4.2.2821-10 таләпләре үтәлми: лампаларның барысы да эшләми, берсендә янган эзләр күренә.*

Республика күләмендә тулы мәгълүмат-аналитик белешмәне әзерләү максатларында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы белән берлектә, бу мәсьәләләр буенча Вәкаләтле вәкилнең Җәмәгать ярдәмчеләрен җәлеп итеп, мониторинг уздырылды. Аның йомгаклары буенча түбәндәгеләр билгеләнде:

Актаныш, Кайбыч муниципаль районнары мәктәпләрендә химия кабинетларында реактивлар (лаборатор җайланмалар) юк;

Баулы, Зәй муниципаль районнары мәктәпләрендә химия кабинетларында реактивлар (лаборатор җайланмалар) белән тәэмин ителеш бик түбән (Баулы – 26,6%/26,6%), (Зәй – 40%);

химия кабинетларында махсус җиһазлар белән тәэмин ителеш түбән: Саба (19%), Зәй (25%), Кайбыч (27%), Сарман (32%), Баулы (33%), Балтач (38%) муниципаль районнары мәктәпләрендә;

Актаныш, Арча, Кайбыч, Кукмара муниципаль районнары мәктәпләрендә физика кабинетларында махсус җиһазлар юк; түбән тәэмин ителеш – Зәй (16%), Әтнә (18%), Алексеевск (26%), Кама Тамагы (30%) муниципаль районнары мәктәпләрендә;

Арча, Кайбыч муниципаль районнары мәктәпләренең фихика кабинетларында лаборатор җайланмалар юк; түбән тәэмин ителеш – Әтнә (6%), Зәй (6%) муниципаль районнары мәктәпләрендә, Чаллыда (14%), Сарман (22%), Спас (30%) муниципаль районнарында.

Кайбер мәктәпләрнең җайланмалар белән тәэмин ителешен анализлау гаҗәпләндерде, мәсәлән:

Баулы муниципаль районында «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУендә мәктәпкә яңа җиһазлар 1984 елда алынган (парталар кайтарылган), физика кабинетына 1977 елдан бирлее җайланмалар алынмаган, «Кырым – Сарай гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУенә җайланмалар 1982 елда гына алынган, «6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУенә – 1986-1988 елларда;

Питрәч муниципаль районының «Кощаково урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУенең химия кабинетлары 1975 елда мәктәп ачылганда җиһазландырылган була, «Кулаево урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУенә – шулай ук 1978 елда мәктәп ачылганда.

Бөгелмә муниципаль районында «11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУенең химия һәм физика кабинетларына җиһазлар 1956 елда һәм соңгысы 1987 елда кайтарылган.

*22 нче таблица*

***Мәктәпләрнең җиһазлар белән тәэмин ителешенә мисаллар***

| Учреждение исеме, төзелгән елы, укучылар саны | Химия кабинеты | | | Физика кабинеты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | реактивлар белән тәэмин ителеш һәм алар кайтарылган соңгы ел | махсус мәктәп җиһазлары белән тәэмин ителеш һәм алар кайтарылган соңгы ел | лаборатория җиһазлары белән тәэмин ителеш һәм алар кайтарыл-ган соңгы ел | махсус мәктәп җиһазлары белән тәэмин ителеш һәм алар кайтарыл-ган соңгы ел | лаборатория җиһазлары белән тәэмин ителеш һәм алар кайтарылган соңгы ел |
| «Городищенский урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ Чүпрәле МР, 1841 ел, 105 кеше | 20%, 1991 | 10%, 1984 | 25% | 0% кайтарылмаган | 30%, 1979 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| МБОУ «Азнакай шәһәре нең «2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ, 1954 ел, 544 кеше | 0% кайтарылмаган | 12%, 1986 | 10% 1986 | 12%, 1986 | 10%, 1986 |
| «Азнакай шәһәренең 8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ, 1961 ел, 471 кеше | 0% кайтарылмаган | 30% парты, стулья 1997 | 0% поставки не было | 5% парталар, урындыклар, 1997 | 0% кайтарылмаган |
| «Актүбә ш.т.п.ының 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ, Азнакай МР, 1967 ел, 508 кеше | 0% кайтарылмаган | 50%, 2001 | 0% кайтарылмаган | 0% кайтарылмаган | 25% 1980 |
| Зеленодольск муниципаль районының «Обсерватория урта гомуми белем мәктәбе» МБМУ, 1939 ел, 223 кеше | 30%, 1985 | 10%, 1998 | 70%, 2006 | 100%, 2010 | 20% 1980 |
| Зеленодольск муниципаль районының «16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ, 1996 ел, 274 кеше | 10%, 1997 | 10%, 1997 | 10%, 1997 | 10%, 1997 | 10%, 2008 |

Уздырылган мониторинг йомгаклары буенча балаларның белемгә хокукларын тәэмин итүне яхшырту максатларында, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына мәктәпләрне тиешле җайланмалар белән тәэмин итү чараларын күрергә тәкъдим итә.

***Алтынчыдан,*** белем бирү учреждениеләрендә укучыларның тукלануын оештыру һәм аның сыйфаты турындагы мәсьәлә мәктәп җитәкчеләренең, гамәлгә куючыларның, контроль-күзәтчелек органарының даими игътибарында кала. Кызганычка каршы, бу өлештә хокук бозулар шактый. Хокук бозуларны профилактикалау һәм мәктәптә балаларның туклануын тиешле дәрәҗәдә оештыру оештыру масатларында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дәүбәндәгеләрне эшләргә кирәк дип саный:

укучыларны туклaндыруны оештыру өчен мәктәп директорларын шәхси җаваплы итеп билгеләргә;

муниципаль мәгариф идарәләре тарафыннан даими тикшерүләр уздыруны тәэмин итәргә;

Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе территориаль бүлекләренә даими нигездә аш-су хезмәткәрләре һәм учреждениеләр җитәкчеләре өчен санитария-гигиена укуларын уздырырга тәкъдим итәргә.

***Җиденчедән,*** Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге һәм оешмаларны тикшерү барышында хезмәт зконнарының бозылуы ачыкланды.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының (алга таба – Россия Федерациясе ХК) 65 статьясы нигезендә эшкә алына торган зат хезмәт шартнамәсен төзегәндә эш бирүчегә хөкем ителмәгәнлеге турында һәм (яисә) җинаять эзәрлекләве булмау факты йә реабилитация аркасында җинаять эше туктатылу турында дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм эчке эшләр өлкәсен норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган формада һәм тәртиптә белешмә бирә (хөкем ителүе булган, җинаять эзәрлекләвенә дучар ителгән затларны Россия Федерациясе ХК, башка федераль законнар нигезендә эшкә алу рөхсәт ителми торган очракларда).

Шул ук вакытта, Россия Федерациясе ХКының 65 статьясын бозып, мәгариф оешмаларының кайбер хезмәткәрләре эшкә алынганда билгеләнгән үрнәктәге белешмәләрне (Россия Федерациясе ХКының 331, 351.1 стаьялары таләпләре нигезендә каралган аерым җинаятьләр өчен хөкем ителүе булган яисә ул алынган, йә җинаять эше туктатылгын булу турында) тапшырмаганнар йә бу белешмәләр алар учреждениегә алынганнан соң гына тапшырылган.

Әлеге хокук бозулар Спас, Менделеевск муниципаль районнарындаАлабуга балалар йортында ачыкланды

***Мисал:*** *Алабуга балалар йортын тикшергәндә, хезмәткәр В.ны эшкә алу турында 01.03.2017 боерыгын чыгару вакытына хөкем ителү барлыгы (юклыгы) турында белешмә тапшырылмаганлыгы ачыкланды; ә шәхси эшнамәсенә мондый белешмә 21.03.2018 датасы белән куелганхезмәткәр Л. – эшкә алу турында 01.12.2017 датасы белән боерык чыгарылган, ә югарыда күрсәтелгән белешмә шулай ук юк.*

Моннан тыш, белем бирү әлеге учреждениеләр эшчәнлегендә шундый хокук бозулар Татарстан Республикасы Прокуратурасы тарафыннан да ачыкланган.


Шуңа бәйле рәвештә, балигъ булмаганнар булмаганнарның хокукларын һәм законды мәнфәгатьләрен яклау максатларында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, җирле үзидарә органнары белән бергәләп, балалар оешмаларын алардагы барлык хезмәткәрләрнең тиешле үрнәктәге белешмәләре булуына планнан тыш тикшерү оештырырга тәкъдим итәю.

***Сигезенчедән,*** Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең даими игътибарында – белем бирү оешмаларында ***укымый торган (дәресләргә йөрми торган)*** 7 – 18 яшьтәге балалар һәм яшүсмерләр проблемасы.

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы белешмәләре буенча, республикада белем оешмаларында төрле сәбәпләр буенча укымый торган балалар саны елдан-ел кими бара. Узган ел белән чагыштырганда бу сан 249 кешегә (43%ка) кимегән һәм хәзер андыйлар 330 кеше исәпләнә.

*87 нче диаграмма*


***2014 – 2018 елларда мәктәпкә йөрмәүче мәктәп яшендәге балалар саны***




Әлеге статистик хисапны анализлаудан күренгәнчә, 330 баладан 199ы – 14 – 17 яшьтәге яшүсмерләр, 131 бала – 13 яшькә кадәрге балалар.

*88 нче диаграмма*

***2018/2019 уку елында мәктәпкә йөрмәүче мәктәп яшендәге балалар саны***




330 баладан бары тик 253е генә (77%) сәламәтлеге начар булу сәбәпле укымый, шул исәптән 137 баланың сәламәтлек мөмкинлекләре чикле.

Калган 77 баладан берсе бөтенләй укымаган, калган балалар эшкә урнашу сәбәпле мәктәптән киткәннәр.

77 баладан 24 бала мәҗбүри төп гомуми белем алмыйча мәктәптән киткән, шул исәптән:

1 баланың гомуми башлангыч белеме юк;

23 баланың төп гомуми белеме юк.

Ә бит Россия Федерациясе Конституциясе һәр гражданга төп гоуми белем алуны мәҗбүри итеп йөкли, ә аларның ата-аналарына яисә аларны алыштыручы затларга – балаларына шул белемне алуны тәэмин итү бурычын куя (43 статьяның 4 өлеше).

Төп белемне алмыйча, мәктәптән киткән балаларның саны шактый булуын исәпкә алып, балигъ булмаганнарның белемгә хокукларын яклау максатларында, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең түбәндәге тәкъдимнәре актуаль булып кала:

укучыларның дәресләргә җитди сәбәпләрсез озак вакыт дәвамында йөрмәүләренә сәбәп булган шартларны ачыклауга, аларны алдан профилактикалауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән чаралар системасын, шул исәптән индивидуаль профилактикалау чараларын да кертеп, гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә һәм муниципаль комиссияләргә, нинди ведомствога каравына

бәйсез рәвештә, барлык типтагы һәм төрдәге мәгариф оешмаларына дәресләргә җитди сәбәпләрсез озак вакыт дәвамында (системалы рәвештә) йөрми торган балигъ булмаганнарны ачыклау һәм исәпкә кую буенча эшнең оештырылуы өлешендә мәгариф оешмаларында, мәгарифкә идарә итү органнарында тикшерүләр оештырырга.

***Тугызынчыдан,*** 2018 елда тагын бер мәсьәлә – ***гаиләдә белем алучы балаларны укытуны оештыру*** да Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибарыннан читтә калмады.

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы белешмәләре буенча, 2018/2019 уку елында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу программалары буенча гаиләдә укыту рәвешендә 898 кеше белем ала, бу узган елга караганда 48%ка күбрәк (2017/2018 уку елында – 606 кеше, 2016/2017 уку елында – 510 кеше).

Гаиәдә белем бирү иң күбе Әлмәттә, Алабугада оештырылган (шул исәптән арадаш һәм йомгаклау аттестациясен узу өчен Халыкара мәктәптән укучыларны беркетү аркасында), шулай ук Түбән Кама һәм Зеленодольск муниципаль районнарында, Чаллы һәм Казан шәһәрләрендә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр бирү хокукыннан файдаланып, 2018 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов адресына Татарстан Республикасы мәгариф системасында гаиләдә белем бирү рәвеше мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр кертелде.

«2017 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында» Доклад йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президентының 28.03.2018 № ПР-110 йөкләмәләрен үтәү буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан уздырылган мониторинг күрсәткәнчә, гаиләдә белем бирү өлешендәге йөкләмәләр Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы тарафыннан барысы да үтәлгән дип әйтергә була. Җирле үзидарә органнары белән бергә, гаиләдә укытыла торган балигъ булмаганнарны да исәпкә алып, укырга тиешле балаларны исәпкә алу системасын будыру эше башкарылды. Шул ук вакытта, республиканың өсч районында – Азнакай, Яңа Чишмә һәм Сарман муниципаль районнарында – укырга тиешле балаларны исәпкә алуны регламентлый торган тиешле муниципаль норматив актлар кабул ителмәгән.

«Россия Федерациясендә белем бирү турында» Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлеше нигезендә укырга тиешле затларга белем бирүне оештыруны муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының белем бирү өлкәсендәге органнары башкара.

Шул ук вакытта, 2018 елда гаиләдә гомуми белем бирү программаларын үзләштерү вәзгыятенә анализдан түбәндәге проблемалы мизгелләр ачыкланды:

1. Элек тә билгеләп үтелгәнчә, 2018/2019 уку елында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу программалары буенча гаиләдә белем алу рәвешендә укучылар саны узган елга караганда 48%ка арткан.

2. Ата-аналары гаризасы буенча гаиләдә белем алуга күчерелгән, әмма аттестация чоры башланганчы беркая да беркетелмәгән укучылар саны артты:

| Ел | Барысы | Беркетү | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ТР | РФ | ачыкланмаган |
| 05.10.2017 | 606 | 444 | 103 | 59 |
| 05.10.2018 | 898 | 581 | 127 | 190 |

3. Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы белешмәләре буенча, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу программалары буенча гаиләдә белем алучыларның экстерн дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре сыйфаты көндез мәктәпкә йөреп укый торган укучыларныкыннан түбәнрәк.

4. Укучыларның барысы да дәүләт йомгаклау аттестациясе өчен арадаш аттестациягә кертүгә яраклы булмый. Мондый вәзгыять Әлмәт, Биектау, Зеленодольск, Түбән Кама, Сарман, Спас муниципаль районнарында, Чаллы һәм Казан шәһәрләрендә күзәтелә. Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) һәм экстерннарның унберенче сыйныфлар өчен инша йомгаклары буенча һәм дәүләт йомгаклау аттестациясе (ГИА) белешмәләренең төбәк мәгълүмат системасы базасына кертү өен үзләре сайлаган имтиханнар турында турында белешмәләр бирү сроклары өлешендә кагыйдәләрне бозу очраклары бар, ә мәгариф идарәсе бу вәзгыятьне вакытында ачыкламаган. Моннан чыгып, шуны әйтергә була, гаиләдә укытыла торган балаларны исәпкә алу системасына тиешле төзәтмәләр кертергә кирәк.

Шулай ук 2018 елда Санкт-Петербург шәһәренең «ЦОДИВ» хосусый мәктәбе»ндә гаиләдә белем алу рәвешендә укый торган балигъ булмаганнар К., Г., П. ата-аналарының балаларының белемгә хокукларын яклау буенча мөрәҗәгатьләрен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил җентекләп анализлады. Мөрәҗәгать итүчеләр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф һәм яшьләр эшләре буенча идарәсе тарафыннан Санкт-Петербург шәһәренең «ЦОДИВ» хосусый мәктәбе»ндә гаиләдә белем алу рәвешендә укыган балаларның арадаш аттестациясен исәпкә алынмавы турында язганнар иде, янәсе әлеге белем бирү оешмасының гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт аккредитациясе юк, нәтиҗәдә, П. Һәм К. йомгаклау аттестациясенә кертелми калалар.

Бу мәсьәләне өйрәнү йомгаклары буенча түбәндәгеләр билгеләнде.

Урта гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру тәртибе «Урта гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру тәртибен раслау турында» (алга таба – ГИА уздыру тәртибе) 2013 елның 26 декабрендәге 1400 номерлы Россия Мәгариф министрлыгы боерыгы белән регламентлаштырыла. ГИА уздыру тәртибенең 9 пункты нигезендә дәүләт йомгаклау аттестациясенә академик бурычы булмаган укучылар, шул исәптән йомгаклау иншасы (изложениесе) буенча, шулай ук уку планын яисә индивидуаль уку планын тулысынча үтәгән укучылар (урта гомуми белем бирү программасы буенча һәр елда барлык уку фәннәре буенча канәгатьләнерлек билгесеннән түбәнрәк булмаган билгеләр алган укучылар) кертелә

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 273-ФЗ) 58 статьясындагы 1 пункты нигезендә аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча төп гомуми һәм урта гомуми дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны алганда йә күчергәндә индивидуаль сайлап алуны оештыру Россия Федерациясе субъекты законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә башкарыла.

273-ФЗның 34 статьясы нигезендә үзлегеннән яисә өй шартларында белем алучы затлар яисә дәүләт аккредитациясе булмаган белем бирү программасы буенча укучылар экстерн рәвештә тиешле дәүләт аккредитациясе булган белем бирү программасы буенча белем бирә торган оешмаларда арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен үтәргә хаклы. Шул ук вакытта 273-ФЗның 33 статьясы нигезендә экстерныйлар булып дәүләт аккредитациясе булган белем бирү программасы буенча белем бирә торган оешмаларда арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен узуга кертелгән затлар санала.

273-ФЗның 59 статьясында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү, төп һөнәри белем бирү программаларын үзләштерүне тәмамлый торган аттестациясенең мәҗбүри булуы һәм каралган һәм ул белем бирү оешмаларында билгеләнгән яисә Федераль законда билгеләнгән башка тәртиптә һәм рәвештә уздырыла.

Шулай итеп, үзлегеннән яисә гаиләдә белем алучыларның арадаш аттестациясе дәүләт аккредитациясе булган мәгариф оешмаларында үтәргә тиеш, ә дәүләт йомгаклау аттестациясенә академик бурычлары булмаган укучылар кертелә.

Балигъ булмаганнар К., Г., П. арадаш аттестацияне гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт аккредитациясе булмаган «ЦОДИВ» хосусый мәктәбе» мәгариф учреждениесендә узалар.

П. Һәм К.ның гаризалары һәм шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалык бирүләре нигезендә алар йомгаклау иншасын язуга кертеләләр. Бу балигъ булмаганнар «28 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУенә арадаш аттестациягә килмәгәнгә күрә алар дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертелмиләр.

Балигъ булмаган Г. Чаллы шәһәренең «58 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУендә арадаш аттестацияне уза һәм дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертелә һәм аны уңышлы уза.

Югарыдагыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына:

укырга тиешле булып та, белем бирү оешмаларында укымый торган, шул исәптән гаиләдә белем алу һәм үзлегеннән уку рәвешен сайлаган балаларның реестрын, шулай ук бу категория укучыларны исәпкә алуны, арадаш аттестацияне узмаган балаларны мәктәпкә алуның исәбен җирле үзидарә органнары тарафыннан алып баруның үтәлешенә контрольне тәэмин итәргә;

үз балалары өчен гаиләдә белем алу рәвешен сайлаган ата-аналарга, шул исәптән аккредитациясе булмаган оешмаларда укыганда килеп чыга торган проблемалар буенча тиешле күрсәтмәләр (памяткалар) эшләргә; мондый күрсәтмәләрне белем бирү оешмаларының сайтында урнаштыру максатка ярашлы дип саныйм;

җирле үзидарә органнары белән берлектә:

экстерныйлар арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен узганда муниципаль белем бирү оешмалары тарафыннан законнар таләпләренең үтәлешенә контрольне көчәйтергә;

бу төр белем алуны сайлау һәм аңа күчү сәбәпләрен белем бирү оешмалары җитәкчеләре (укыту һәм тәрбияләү эшләре буенча урынбасарлар) катнашында уздырыла торган киңәшмәләрдә көндезге уку программаларына карата тискәре йогынтыны профилактикалау максатларында анализларга;

экстерныйларның арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясенә килмәү мәсьәләләрен балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль (шәһәр) комиссияләре утырышларында карауларын тәэмин итәргә.

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика һәм муниципаль комиссияләргә үз утырышларында балаларның өйдә уку рәвешендә белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру вәзгыяте мониторингы мәсьәләсен карарга, балигъ булмаганнарның белем алуга хокукларын яклау буенча тиешле карарлар кабул итәргә һәм чаралар күрергә.

Игътибар үзәгендә булган ***Унынчы*** мәсьәлә – Татарстан Республикасында, шул исәптән Казан шәһәрендә ***балалар техника иҗатының*** торышы турындагы мәсьәлә.

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы белешмәләре буенча, Татарстан Республикасында 2 910 техника иҗат берләшмәсе эшли, аларда 47 667 кеше шөгыльләнә, бу республика мәктәп балаларының 11%ын тәшкил итә.

2016 елдан республикада балалар һәм яшьләр өчен яңа форматта өстәмә белем бирүнең заманча учреждениеләре эшли башлады. Балаларны фәнни-техник иҗатка җәлеп итәргә сәләтле Кванториумнар, яңа технологияләр мәктәп балаларының идеяләрен тормышка ашырырга ярдәм итә. Шундый балалар технопарклары Чаллы шәһәрендә (2016 елда «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк һәм КамАЗ ГАҖ катнашында коммерциягә карамаган автоном оешма ачылды), Түбән Камада (2017 елдан КНИТУ нефть-химия мәйданчыгында), Әлмәттә (2017 елдан) эшли.

Казанда 1971 елдан башлап В.П.Чкалов ис. бердәнбер балалар техника иҗаты үзәге эшли, анда меңнән артык бала шөгыльләнә. Бу үзәк республикада балалар техника иҗатының база мәйданчыгы булып тора. Шул ук вакытта, Үзәк 1937 елда төзелгән бинага 1974 елда төзелгән янкормада урнашкан. Үзәктә ул гамәлгә куелганнан бирле капиталь ремонт ясалмаган, ә 20120 елда бары тик фасадка, түбәсенә генә ремонт ясалган, тәрәзәләре алыштырылган

Шәһәр мәктәпләрендә эшли торган техника иҗаты түгәрәкләре булуга карамастан, башкалада гамәлдәге техника иҗаты базасы модернизацияләүне таләп итә. Бүгенге көндә Казан шәһәрендә иң заманча ысулларга һәм алымнарга нигезләнгән инновацион проект буларак балалар технопаркын булдыру ихтыяҗы бар. Мондый учреждениене ачу кечкенә яшьтән балаларны күпбаскычлы системалы, конкуренциягә сәләтле итеп үстерү, шул исәптән «Кванториум» базасында олимпиадаларда, шул исәптән WordSkillsta җиңүчеләрне әзерләргә мөмкинлеген бирәчәк

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасының Инвестицияне үстерү агнтлыгы белән берлектә, дәүләт-хосусый партнерлык шартларында, башка инвестиция ресурсларын җәлеп итеп, балалар технопаркын төзү турындагы мәсьәләне карарга һәм тиешле тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә тиеш, дип саный.


### *3.5.3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларга белем бирү*

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучылар – физик һәм (яисә) психик кимчелеге булган физик зат, әгәр болар психологиук-медик-педагогик комиссия тарафыннан расланган булса һәм махсус шартларсыз белем алуга тоткарлык ясый торган булса, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы нигезендә белем алырга хокуклылар.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, республикада ***сәламәтлек мөмкинлекләре чикле*** балаларның (алга таба – СМЧ) гомуми саны 2018 елда 18 394 кеше булды, ягъни республиканың гомуми балалар санынннан 2,3% тәшкил итә.

*89 нчы диаграмма*

***2014 -2018 елларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (СМЧ) балалар саны (кеше)***




Алар арасында мәктәпкәчә яшьтәге балалар – 6 470 кеше, мәктәп яшендәге балалар – 12094 кеше. Узган ел белән чагыштырганда аларның саны 2,1%ка, ягъни 387 балага кимегән. Шул ук вакытта, мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны арткан, 2017 елда 4 305 кеше булса, 2018 елда 6 470 кешегә җиткән (50%ка арткан).

*90 нчы диаграмма*

***2018/2019 уку елында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган укучылар саны (кеше)***




Белем бирүгә идарә итү органнарында исәптә торучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле ***мәктәпкәчә яшьтәге*** 6 407 баланың күпчелеген сөйләмнәре бозылган (50,3%), начар күрә торган (20,7%) һәм терәк-хәрәкәт системасы сәламәт булмаган (16,4%) балалар тәшкил итә. Узган ел белән чагыштырганда, сөйләмнәре бозылган балалар саны 2 мәртәбәдән күбрәк арткан, күрү сәләте бозылганнар 54,4%ка күбрәк, ишетү сәләт начарланган балалар саны 24,5%ка күбрәк, терәк-хәрәкәт системасы начарланган балалар саны 7,5% ка күбрәк һәм акылга зәгыйфь балалар саны 31,1% ка арткан.

*91 нче диаграмма*


***2014 – 2018 елларда авыру төрләре буенча сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны***




2018/2019 уку елында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган мәктәпкәчә яшьтәге балалар белем бирүгә идарә итү органнарында исәптә торучы балаларның гомуми санын-нан 90% тәшкил итте (2017 елда – 86,7%).

*92 нче диаграмма*


***2018 елда авыру төрләре буенча сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү***



Шулай итеп, 2018/2019 уку елында мәктәпкәчә яшьтәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар, мәктәпәчә махсус учреждениеләргә яисә төркемнәргә йөрүче балалар саны 3%ка арткан.

*93 нче диаграмма*


***2014 – 2018 елларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган (СМЧ) балаларның мәктәпкәчә белем белән тәэмин ителеше (кеше)***




Балаларның мәктәпкәчә белем алу белән тәэмин ителешен анализлаудан күренгәнчә, СМЧ белән авыручы балаларның күпчелеге гомуми типтагы мәктәпкәчә оешмаларга йөри башлаган. Шул ук вакытта бүген республикада сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балалар тәрбияләнә ала торган учреждениеләр челтәре булдырылган. Бүген республиканың мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында дефектология буенча белеме булган 113 педагог һәм 921 логопед эшли.

*94 нче диаграмма*

***2015 – 2018 елларда мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында эшләүче профильле белгечләр саны***




Балалар бакчасына йөри алмый торган сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның шактый булганын исәпкә алып (2018 елда – 696), булдырылган челтәр Татарстан гаиләләренең ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә дип әйтеп булмый.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына җирле үзидарә органнары белән берлектә түбәндәгеләрне төзү буенча эш барырга кирәк, дип саный:

кече яшьтәге балаларга психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтүче үзәкләр (хезмәтләр) төзү;

мәктәпкәчә белем бирү оешмалары каршында сәламәтлегендә һәм үсешендә кимчелекләр булган балалар тәрбияләүче ата-аналарга психологик һәм махсус педагогик ярдәм күрсәтә торган лекотек-хезмәтләр булдыру.

Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән ***мәктәп яшендәге*** балаларның белемгә хокукын гамәлгә ашыру өлешенә караган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгълүматларына ясалган анализдан күренгәнчә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 11 957 баладан бала 99% бала (2017 елда – 98,2%) мәктәптә белем ала.

Татарстан Республикасында уку барышында җитәкләп йөрүгә мохтаҗ булган балалар өчен махсус (коррекцияле) белем бирүне тәэмин итүдә әлеге этапта республиканың гамәлдәге коррекцияле белем системасын саклап калу аерым әһәмияткә ия. Бүгенге көндә эшли торган махсус (коррекцияле) учреждениеләр базасында инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы мәктәпләргә методик ярдәм күрсәтү өчен укыту-методика ресурс үзәкләре төзелә.

Бүгенге көндә махсус белем алуга мохтаҗ балаларны укытуда өч алым кулланыла:

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү учреждениеләре, аларда ишетү, күрү сәләте, сөйләме, терәк-хәрәкәт аппараты һәм интеллекты бозылган балаларны дифференцияле укыталар;

гомуми белем бирү оешмаларында махсус сыйныфларда (төркемнәрдә) балаларны берләштереп укыталар;

инклюзив укыту, махсус белем алу ихтыяҗлары булган балалар сыйныфта гадәти балалар белән бергә укыйлар.

Бүгенге көндә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәгариф киңлеге үз эченә түбәндәгеләрне ала:

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен 52 гомуми белем бирү учреждениесе, аларда ишетү, күрү сәләте, сөйләме, терәк-хәрәкәт аппараты һәм интеллекты бозылган 7 551 бала укый;

инклюзив укытуны гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында 1 994 сыйныф булдырылган, аларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 3 326 бала башка балалар белән бергә укый;

525 гомуми белем бирү оешмасыннан 183е инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмасы (яисә гомуми мәктәпләр), алар сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучыларга башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф системасын (ФГОС) һәм акылга зәгыйфь (интеллектлары бозылган) белем алучыларга белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф системасын кертүне тәэмин итүче нигези гомуми белем бирү оешмалары булып саналалар, аларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 798 бала укый;

15 муниципаль район (Аксубай, Әлмәт, Апас, Балтач, Буа, Биектау, Зәй, Минзәлә, Түбән Кама, Нурлат, Балык Бистәсе, Сарман, Тәтеш, Теләче, Чирмешән муниципаль районнары) һәм Казан шәһәрендә, Чаллы шәһәрендә мәктәпләрендә гомуми белем бирү оешмалары базасында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле – ишетү сәләте, сөйләме, акыл үсеше һәм психик үсеше бозылган балалар өчен 105 сыйныф, аларга 728 бала йөри.

2018/2019 уку елында «Ресурслы сыйныф» пилот моделен гамәлгә кертү буларак, аутизм белән авыручылар өчен гомуми белем бирү мәктәпләре эшли башлады, болар: Казан шәһәре Мәскәү районының «65 нче УБМ» МБМУ, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «(168 нче ГБМ)» МБМУ, Казан шәһәре Идел буе районының «97 нче УБМ» МБМУ, Казан шәһәре Совет районының «156 нчы УБМ» МБМУ, Әлмәт шәһәренең «21 нче УБМ» МБМУ. Бу уку елында әлеге 5 мәктәптә аутизм белән авыручы 40 бала төп гомуми белем программасы буенча башлангыч гомуми белемне үзләштерә.


2018/2019 уку елында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 11 957 баладан 4 191 бала гомуми мәктәпләрдә укый, бу шул категориядәзге балаларның 35 %ын тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 28 сентябрендәге 716 номерлы карары белән расланган 2015 – 2030 елларга Татарстан Республикасында объектлар һәм хезмәт күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алу күрсәткечләрен арттыру буенча чаралар планын («юл картасын») үтәү мониторингыннан күренгәнчә, 2018 елда «Гомуми белем бирү оешмаларында төп инвалид балалар, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар саныннан гомуми белем бирүнең җайлаштырылган программалары буенча белем алучы инвалид балалар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өлеше» 97,8% тәшкил итә.

Төрле авыру төрләре буенча сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәп яшендәге балаларны мәктәптә укытуны тәэмин итү түбәндәге диаграммада күрсәтелә.

*95 нче диаграмма*

***Төрле авыру төрләре буенча сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (СМЧ) балаларның мәктәптә белем алулары (2018 елда) (кеше)***




Шулай итеп, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы белешмәләре буенча, агымдагы уку елында ишетү, күрү сәләте, сөйләме бозылган барлык балалар (100%ы да) укырга йөри.

Югарыда күрсәтелеп киткәнчә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 137 бала укымый.

*96 нчы диаграмма*

***2014 – 2018 елларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (СМЧ) балаларның мәктәптә белем алу белән тәэмин ителеше (кеше)***





2012 елдан республикада ел саен гомуми белем бирү оешмаларында уңай мохит булдыру буенча тиешле чаралар күрелә. «Уңайлы мохит» программасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә узган чорда 326 гомуми белем бирү оешмасы инвалидларның һәм үсешләрендә тайпылышлар булмаган затларның бергә укуын тәэмин итү өчен җайлаштырылды, алар

гомуми белем бирү мәктәпләренең гомуми санынннан 23,3% тәшкил итә. Әлеге күрсәткеч 2015 – 2030 елларга Татарстан Республикасында объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алу күрсәткечләрен арттыру буенча чаралар планының («юл картасы»ның) 2018 елда индикатив күрсәткеченең иң чик зурлыгына тиң.

*97 нче диаграмма*

***2012-2018 елларда уңай мохит булдырылган гомуми белем бирү мәктәпләре саны***




2018 ел йомгаклары буенча, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру вәзгыятен анализлау түбәндәге проблемалы мәсьәләләрне хәлитәргә мөмкинлек бирде.

***Беренчедән,*** сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның белемгә хокукларын тәэмин итүдәге төп каршылыкларның берсе – сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны турында төгәл мәгълүматның булмавы. Хәзергә кадәр мондый балаларны исәпкә алуның бердәм системасы булдырылмаган, югыйсә, бу проблема Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан бер генә мәртәбә күтәрелмәде инде. Тиешле хезмәтләрдә Татарстан Республикасында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны турында төгәл мәгълүмат юк.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил соратуы буенча муниципаль районнар башлыклары тапшырган мәгълүмат-аналитика материалларны анализлаудан күренгәнчә, күпчелек муниципаль районнарның мәгарифкә идарә органнарында районда (шәһәрдә) сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре төрлечә чикле булган балаларның исәбе турындагы дөрес мәгълүматлар бөтенләй булмауны күрсәтте. Моннан тыш, муниципалитетларда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның исәбе, яшьләре, белемгә ихтыяҗлары турында хак мәгълүматның булмавы республика районнарында һәм шәһәрләрендә әлеге балаларга белем бирүне оештыруга системалы якын килүнең гамәлгә ашырылуын зур шик астына куя. Мәгарифкә идарә органнары муниципалитеттагы сәламәтлек ягыннан мөмкинлеге чикле һәр бала турында тулысынча хәбәрдар булырга һәм һәркайсына белем алу маршрутын ачык төзергә тиеш. Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы дәрәҗәсендә статистик белешмәләрдә аерым кыенлыклар барлыкка килә.


Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына, муниципаль мәгариф идарәсе органнарына әлеге категориядәге балалар буенча дөрес мәгълүмат булдыру мәсьәләсен һәм, шуннан чыгып, әлеге балаларга белем бирү мәсьәләсен махсус контрольгә алырга кирәк, дигән күрсәтмәсе актуаль булып кала.

***Икенчедән,*** соңгы елларда ***өй шартларында укучы*** балалар саны ел саен арта бару да игътибарга лаек. Соңгы алты елда бу уку елында 26 кеше беренче мәртәбә өйдә укудан

көндез йөреп укуга күчүгә дә карамастан, индивидуаль программалар буенча өйдә укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны артты. 2017/2018 уку елында өй шартларында 1233 кеше укыды (10,2%).

*98 нче диаграмма*

***2014/2015 – 2018/2019 уку елларында өй шартларында укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны (кеше)***




***Өченчедән,*** шуны да билгеләп үтәргә кирәк, республикада инклюзив белем бирүне гамәлгә кертү буенча, шул исәптән инвалид балалар өчен «гомуми» мәктәптән файдалануны тәэмин итү буенча да, чаралар күрелүгә дә карамастан, барлык төрдәге махсус (коррекцияле) гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны кимеми, ә киресенчә, арта бара (2013 елда – 5 929 кеше, 2014 елда – 6 016 кеше, 2015 елда – 6 297 кеше, 2016 елда – 6 631 кеше, 2017 елда – 7 245 кеше, 2018 елда – 7 766 кеше).

Аерым алганда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, махсус (коррекцияле) мәктәпләрдә укучылар саны түбәндәгечә артты:

күрү сәләте бозылганнар – 2017 елда – 608, 2018 елда – 614булды;


таяну-хәрәкәтләнү аппараты бозылганнар – 2013 елда – 383 булса, 2017 елда – 466 булды;

акылга зәгыйфьләр – 2017 елда – 5 470, 2018 елда – 5 767 булды.

Яшәү урыны буенча гомуми мәктәпләрдә белем бирү буенча коррекциячел белем бирү юнәлешендәге хезмәт күрсәтүләрдән акылга зәгыйфь балаларның һәм ишетү сәләте бозылган балаларның файдалана алмавы аеруча проблемалы мәсьәлә булып кала.

*99 нчы диаграмма*

***2018 елда авыру төрләре буенча сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәп яшендәге балаларны укытуның тәэмин ителеше (кеше)***



Әлеге вәзгыять шуны күрсәтә, республикада шактый чаралар күрелүгә дә карамастан, балаларның яшәү урыны буенча мәктәпләрдә сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен инклюзив белем бирү буенча күрелә торган чараларның җитәрлек булмавын аңлата.

Шул ук вакытта, коррекцияле белем бирелүгә мохтаҗ һәм махсус шартлар үтәлүне таләп иткән ата-аналарның кайберләре, элеккечә, балаларының традицион коррекциячел белем алуларын хуплыйлар.

***Дүртенчедән,*** сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар укый торган гомуми белем бирү оешмаларындагы кыенлыкларның шактый өлеше кадрларга ихтыяҗ булуга бәйле. 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан күтәрелгән гомуми белем бирү оешмаларында тьюторларны финанслау мәсьәләсе беркадәр хәл ителде дип әйтергә була. 2018/2019 уку елында гомуми белем бирү оешмаларында 93 тьютор эшләде, әмма бу белгечләргә мәктәпләрнең ихтыяҗы моннан зуррак.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучыларны мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәм гомуми белем бирү оешмаларында башка балалар белән бергә тьюторларсыз һәм ассистентларсыз укыту укытучы яисә тәрбияче тарафыннан укыту барышында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга башка укучыларга караганда күбрәк өстенлек бирүгә китерергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитетында «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законын карау барышында инклюзив белем бирүдә тьюторлар һәм ассистентлар эшен финанслау мәсьәләсе Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан кабат күтәрелде.

Укучыларга кирәкле техник ярдәм күрсәтүче ассистент (ярдәмче) хезмәтләрен күрсәтү «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясында, шулай ук «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясында каралган.

Инклюзив белем бирүнең социаль әһәмиятле булуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил билгеләгән проблема хупланды һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәге тәкъдим кертелде: сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучыларга кирәкле техник ярдәм күрсәтүче ассистент (ярдәмче) хезмәтләрен күрсәтү мөмкинлеген Татарстан Республикасы законнары белән ел саен раслана торган түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу, шулай ук өстәм белем алу хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларына кертү мөмкинлеген карарга, алар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының тиешле карарлары нигезендә исәпләнә. Әлеге мәсьәлә хәзер Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә эшләнү стадиясендә.

***Бишенчедән,*** системалы рәвештә хәл ителергә тиешле тагын бер мөһим мәсьәләнең берсе – инвалид балаларга өстәмә белем бирү һәм аларның физкультур һәм спорт белән шөгыльләнү мәсьәләсе. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2011 – 2020 елларга «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2015 елның 1 декабрендәге 1297 номерлы карары белән еллык максатчан индикаторлар билгеләнде. 2020 елга 5 яшьтән 18 яшькә кадәрге инвалид балаларның 50%ына өстәмә белем бирелергә тиеш. Шул ук вакытта, кайбер районнарда бу күрсәткеч шактый түбән:

Актаныш, Минзәлә, Баулы муниципаль районнарында 10% кына, ә Әгерҗе муниципаль районында бу күрсәткеч 3%. Инвалид балаларның системалы рәвештә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүнең федераль күрсәткече 2020 елга 69% тәшкил итәчәк. Әмма республикада бу юнәлештәге күрсәткеч тә 10%ка да җитми (Югары Ослан, Биектау муниципаль районнары).

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, республиканың муниципаль районнары белән бергәләп, инвалид балаларга өстәмә белем бирүне һәм аларның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүен тиешенчә тәэмин итү буенча чаралар күрергә.

## 3.6. Баланың торак һәм башка мөлкәти хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү

Әлеге бүлектә социаль зәгыйфь категорияләргә керүче гаиләләрдәге балаларның торак хокукларын һәм башка мөлкәти хокукларын тәэмин итү вәзгыяте анализланды, шул исәптән:

ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торакка хокукларын үтәү;

күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын үтәү;

инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокукларын үтәү;

балигъ булмаган балаларга карата алимент йөкләмәләрен гамәлгә ашыру.

### *3.6.1. Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын үтәү*

Гамәлдәге законнар нигезендә торакка мохтаҗ дип танылган ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга (алга таба – ятим балалар) Татарстан Республикасының махсус орак фондыннан яллау шартнамәләре буенча уңайлы торак урыны бирү рәвешендә бер мәртәбә дәүләт ярдәме күрсәтелә. 2018 елда әлеге чыгым вәкаләтен гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының « 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннары белән тәэмин итү» ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырылды.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, 2011 елдан башлап ятим балаларны торак белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны ***финанслауның*** Татарстан Республикасы бюджетына акчалары өлешендәге ***күләме*** ел саен арта бара. Шул ук вакытта, ятим балаларга торак төзүне федераль финанслау күләме 2016 елдан елдан кими башлады һәм 2018 елда ул 40 328,4 сум тәшкил итте.

*23 нче таблица*

***2008 – 2018 елларда ятим балаларны торак урыннар тәэмин итү***

| Ел | ТР бюджеты акчалары күләме (мең сумнарда) | РФ бюджеты акчалары күләме (мең сумнарда) | Акчаларның гомуми күләме (мең сумнарда) | Торак урыннары алган ятим балалар саны (кеше) |
|---|---|---|---|---|
| **2009** | 50 000,0 | 11 170,1 | 61 170,1 | 70 |
| **2010** | 50 000,0 | 10 697,9 | 60 697,9 | 72 |
| **2011** | 106 600,0 | 51 795,2 | 158 395,2 | 182 |
| **2012** | 112 996,0 | 50 529,3 | 163 525,3 | 179 |
| **2013** | 173 942,2 | 72 086,4 | 246 028,6 | 265 |
| **2014** | 233 730,0 | 83 410,0 | 317 140,0 | 309 |
| **2015** | 269 811,0 | 86 610,4 | 356 421,4 | 331 |
| **2016** | 288 697,8 | 50 485,0 | 339 182,8 | 311 |
| **2017** | 302 840,0 | 43 880,0 | 346 720,0 | 305 |
| **2018** | 314 957,8 | 40 328,4 | 355 286,2 | 297 |
| **Итого** | **1 992 574,8** | **512 553,0** | **2 505 130,8** | **2 433** |

2018 елда ятим балалар өчен торак төзүгә бүлеп бирелгән финанс күләме 355 286,2 мең сум тәшкил итте, шуннан 314 957,8 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, 40 328,4 мең сумы – федераль бюджет акчалары исәбеннән булды. Күрсәтелгән акчалар чикләрендә 2018 елда 297 бала торак белән тәэмин ителде, шуларның 18 яшьтән 23 яшькә кадәргеләре – 198 кеше һәм 23 яшьтән өлкәнрәкләр – 99 кеше.

Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләреннән күренгәнчә, 2018 елга махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары алучы ятим балалар реестрына 1 240 кеше кертелгән, шулардан бары тик 297 кеше генә үзләренең торак хокукларын тормышка ашырган. Шулай итеп, узган елда реестрда торучы, ягъни 2018 елда махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин ителү хокукына ия барлык затларның бары тик 24% ы гына үз хокукларын гамәлгә ашыра алганнар. Шулай итеп, ел саен ятим балалар өчен торак төзелешенә региональ финанслау күләмен арттыру буенча чаралар күрелсә дә, ятим балаларның закон белән гарантияләнгән торак белән тәэмин ителүгә хокукын финанслау дәрәҗәсе, элеккечә үк, җитәрлек түгел. Торак тәэминаты буенча бурычларның ел саен арта баруы ятим балаларның торак көтү чорын озайта бара. 2018 ел йомгаклары буенча ул 5 ел тәшкил итте. 2019 елда Татарстан Республикасында ятим балаларны торак белән тәэмин итүгә бүленгән акчаларның гомуми күләме 372,3 млн. тәшкил итәчәк, бу 2019 елда торак алу хокукы гамәлгә ашырылырга тиешле 1 222 кешедән 309 ятим баланы торак белән тәэмин итәргә җитә, ягъни ятим балаларның 25,3% торак белән тәэмин ителәчәк.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә республиканың ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслауны арттыру мәсьәләсен хәл итәргә кирәк, дип уйлыйбыз.

Ятим балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыруның 2018 елдагы иң актуаль проблемаларыннан берсе – ***аларның яшәү урыны буенча торак алу*** хокукларын гамәлгә ашыру булды. Гомуми кагыйдә буенча, 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы таләпләре нигезендә ятим балалар торак белән яшәү урыннары буенча тәэмин ителергә тиеш. Ятим балаларга торак урыны бирелгән вакытта махсуслаштырылган торак фондыннан тиешле торак урыны чикләрендә яшәү урыны буенча торак урыны булмаган очракта, күрсәтелгән затларга аларның теләге

буенча Татарстан Республикасы чикләрендә башка торак пунктта махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны бирелә.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: 2018 елда торак урыннарның күпчелек өлеше республиканың эре шәһәрләрендә бирелгән. Мәс., Казанда 75 фатир бирелде, Түбән Камада – 55 фатир, Чистайда – 39 фатир, Алабугада – 14 фатир, Бөгелмәдә – 13 фатир. Республика районнарында торак бары тик Лаеш районында (20 фатир), Питрәч районында (10 фатир), шулай ук Әлки районында 7 индивидуаль торак йорт буларак бирелгән.

Республиканың икътисадый алга киткән шәһәрләрендә торак урыннар алу ятим балаларның күпчелеген кызыктыра. Шул ук вакытта, яшәү урыны, эш, уку урыны буенча республика муниципаль районнарында торак алырга теләүчеләр дә бар. Мәс., Казанга күчеп килү аларның планнарына һәм мәнфәгатьләренә берничек тә туры килми. Шулай итеп, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы белешмәләреннән күренгәнчә, 2018 елда торак алудан шул сәбәпле 50дән артык кеше баш тарткан.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ятим балаларны торак белән тәэмин итү һәм алар белән эшләү буенча вәкаләтле органы буларак, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә, ятим балалар арасыннан булган затларны яшәү һәм эшләү урыны буенча торак белән тәэмин итү тәҗрибәсен ятим балаларның мәнфәгатьләрен дә, дәүләт мәнфәгатьләрен дә канәгатьләндерә торган тәҗрибә буларак дәвам итү буенча чаралар күрергә кирәк

2018 елда ачыкланган тагын бер проблемаларның берсе – ***ятим балаларның законлы вәкилләре (тәрбиягә алган ата-аналары, опекуннары) тарафыннан баланы торак белән тәэмин итүгә мохтаҗ дип тану турындагы длкументларны вакытында тапшырмау.*** Законнарда билгеләнгән тәртиптә аны шундый дип тану бала 14 яшькә җиткәч гамәлгә ашырыла.

Бу проблемалар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә кергән федераль законнардагы үзгәрешләр белән хәл ителә, алар нигезендә опека һәм попечительлек органнары ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләре тарафыннан бу балаларны тиешле исемлеккә кертү турындагы гаризаларның вакытында бирелүен тикшереп торалар, ә мондый гаризалар бирелмәгәндә, аларны исемлеккә кертү чараларын күрәләр.

2018 елда шулай ук Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тагын бер проблема – ***махсус торак урынын яллау шартнамәсе буенча бирелгән торакның сыйфат мәсьәләсе*** ачыкланды. Торак йорт төзегәндә төзүче тарафыннан җибәрелгән хокук бозулар гарантияле йөкләмәләр кысаларында бетерелде.

Суд процессында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында ике ятим баланың махсус торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителү хокуклары торгызылды. Опека билгеләнгәнче яшәгән фатирда бу балаларның бик кечкенә күләмдә өлешләре була, ә бу торак урыны яшәү өчен яраклы хәлдә түгел, бу хакта тиешле акт бар. Фатирда шулай ук балаларның ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән анасы да теркәлгән. Ятим балаларның өлеше булу һәм бу фатирда яшәүче затларның булмавы, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы каршындагы Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның элек биләгән торак урыннарында яшәү мөмкинлеге булмау шартларын билгеләү буенча ведомствоара комиссиясе (алага таба – Ведомствоара комиссия) фикере буенча, абыйлы-сеңелле балаларны махсус торак фондыннан торак белән тәэмин ителергә тиешле Ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан

чыккан балалар исемлегенә кертүдән баш тарту өчен нигез булган. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил фикерен исәпкә алып кабул ителгән апелляция инстанциясе суды карары белән ведомствоара комиссиянең шикаять белдерелгән акты юкка чыгарылды, ятим балаларга билгеләнгән тәртиптә торак урыннар белән тәэмин итү мөмкинлеге бирелде.

### *3.6.2. Күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын тәэмин итү*

Балаларның һәрьяклап үсүе һәм тәрбияләнүе өчен кирәкле уңай мохит тудыруда дәүләт ярдәменә аеруча мохтаҗ гаиләләргә күпбалалы гаиләләр дә керә.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Президентының «Күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча өстәмә чаралар турында» 2001 елның 17 мартындагы ПУ-216 номерлы Указы нигезендә ата-анасы белән торучы, үз гаиләсен кормаган биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү аларга ***торак урын сатып алу өчен*** Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән ***субсидияләр бирү*** юлы белән башкарыла. Торак урын сатып алу өчен субсидияләр алу хокукы сертификат белән таныклана, сертификатлар бирү һәм алардан файдалану «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү һәм алардан файдалану тәртибендә гамәлгә ашырыла.

2018 елда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2017 елның 30 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 149 535,9 мең сум акча каралган иде. Бүлеп бирелгән акчалар чикләрендә узган елда 46 сертификат бирелде.

*24 нче таблица*

***2013–2018 елларда биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак сертификаты хисабына торак белән тәэмин итү***

| Ел | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбендә торучы гаиләләрнең гомуми саны | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләме (мең сумнарда) | Торак сертификатын алуга җыелма исемлектәге гаиләләр саны | Балаларның үз гаиләләре булу сәбәпле сертификат алу хокукын югалткан гаиләләр саны |
|---|---|---|---|---|
| **2013** | 116 191, 4 | 822 | 8 | 44 |
| **2014** | 122 001,0 | 824 | 2 | 37 |
| **2015** | 128 101, 0 | 801 | | 45 |
| **2016** | 137 068,2 | 793 | 3 | 42 |
| **2017** | 143 784,5 | 723 | 19 | 50 |
| **2018** | 149 380,8 | 597 | 1 | 46 |

«2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә биш һәм аннан да күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә 2019 елга 155 965,9 мең сум акча каралган, 2019 һәм 2020 елларга тиешенчә 161 892,6 мең сум һәм 168 368,3мең сум планлаштырылган.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2018 елда биш һәм аннан да күбрәк баласы булган 597 күпбалалы гаилә Торак сертификатын алуга җыелма исемлектә торды. Югарыда китерелгән күрсәткечләргә ясалган анализ бүлеп бирелгән финанслау күләменең торак сертификатлары белән бер елга Җыелма исемлектә торучы күп дигәндә 8,2% гаиләне тәэмин итәргә мөмкинлек бирүен күрсәтте, әлеге күрсәткеч 2016 ел белән чагыштырганда (5,3%) 30,2% ка югарырак. Мондый шартларда торак сертификаты алуны көтүнең уртача чоры 9 – 10 ел тәшкил итәчәк.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә биш һәм аннан күбрәк күпбалалы гаиләләрне торак сертификатлары белән тәэмин итүне финанслау күләмен арттыру мәсьәләсен кабат карарга кирәк, дип саныйбыз.

Күпбалалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең, шул исәптән торак шартларын яхшырту өчен каралган дәүләт ярдәменең тагын бер чарасы – ***түләүсез җир кишәрлекләре бирү.***

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәгълүматы буенча, 2018 елның декабренә җир кишәрлекләрен түләүсез алучылар исемлегенә кертү турында 49 284 карар кабул ителде. Гомуми өлешле милеккә бирелгән 32 372 җир кишәрлеге, тулаем алганда, республикада исемлекләргә кертү турында кабул ителгән карарлар саныннан 65,7% тәшкил итә.

*25 нче таблица*

***2018 елда түләүсез җир кишәрлекләре алган күпбалалы гаиләләр саны*** *(районнар һәм шәһәрләр чикләрендә)*

| Т/с № | Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) исеме | Җир кишәрлекләре алу өчен исәптә торучы күпбалалы гаиләләр саны | Җир кишәрлеге алу хокукы гамәлгә ашырылган күпбалалы гаиләләр саны | Җир кишәрлеге алу хокукы гамәлгә ашырылмаган күпбалалы гаиләләр саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Казан шәһәре | 11 957 | 4 891 | 7 066 |
| 2 | Чаллы шәһәре | 6 527 | 2 606 | 3 921 |
| 3 | Әгерҗе | 500 | 455 | 45 |
| 4 | Азнакай | 763 | 746 | 17 |
| 5 | Аксубай | 295 | 280 | 15 |
| 6 | Актаныш | 404 | 386 | 18 |
| 7 | Алексеевск | 465 | 418 | 47 |
| 8 | Әлки | 168 | 159 | 9 |
| 9 | Әлмәт | 3 296 | 2 058 | 1 238 |
| 10 | Апас | 226 | 201 | 25 |
| 11 | Арча | 1 196 | 929 | 267 |
| 12 | Әтнә | 196 | 168 | 28 |
| 13 | Баулы | 600 | 320 | 280 |
| 14 | Балтач | 671 | 577 | 94 |
| 15 | Бөгелмә | 823 | 523 | 300 |
| 16 | Буа | 577 | 478 | 99 |
| 17 | Югары Ослан | 337 | 325 | 12 |
| 18 | Биектау | 678 | 659 | 19 |
| 19 | Чүпрәле | 298 | 279 | 19 |
| 20 | Алабуга | 1 495 | 1 231 | 264 |
| 21 | Зәй | 713 | 686 | 27 |
| 22 | Зеленодольск | 1 790 | 1 219 | 571 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 23 | Кайбыч | 255 | 248 | 7 |
| 24 | Кама Тамагы | 215 | 201 | 14 |
| 25 | Кукмара | 1 248 | 938 | 310 |
| 26 | Лаеш | 791 | 615 | 176 |
| 27 | Лениногорск | 854 | 584 | 270 |
| 28 | Мамадыш | 608 | 604 | 4 |
| 29 | Менделеевск | 426 | 424 | 2 |
| 30 | Минзәлә | 625 | 620 | 5 |
| 31 | Мөслим | 454 | 404 | 50 |
| 32 | Түбән Кама | 3 066 | 1788 | 1278 |
| 33 | Яңа Чишмә | 223 | 218 | 5 |
| 34 | Нурлат | 870 | 832 | 38 |
| 35 | Питрәч | 698 | 578 | 120 |
| 36 | Балык Бистәсе | 310 | 302 | 8 |
| 37 | Саба | 772 | 730 | 42 |
| 38 | Сарман | 749 | 721 | 28 |
| 39 | Спас | 299 | 299 | 0 |
| 40 | Тәтеш | 258 | 240 | 18 |
| 41 | Тукай | 741 | 693 | 48 |
| 42 | Теләче | 310 | 298 | 12 |
| 43 | Чирмешән | 133 | 133 | 0 |
| 44 | Чистай | 1 143 | 1 061 | 82 |
| 45 | Ютазы | 261 | 247 | 14 |
| **Барысы** | | **49 284** | **32 372** | **16 912** |

Югарыда китерелгән күрсәткечләргә ясалган анализ республикада буш җир кишәрлекләре җитмәү проблемасының сакланып калуы турында нәтиҗә чыгарырга нигез бирә. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белешмәләреннән күренгәнчә, бу проблема элеккечә үк Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә кискен тора.

Шулай итеп, күпбалалы гаиләләрне җир кишәрлекләре белән тәэмин итү мәсьәләсендәге иң мөһим проблемалар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

буш җир кишәрлекләре җитмәү, торак пунктларның чикләрен киңәйтү өчен кирәкле шартлар булмау;

җир кишәрлекләре тәкъдим ителә торган территорияләрдә инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктура булмау.

### *3.6.3. Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокукларын үтәү*

Гаиләләрнең торак проблемаларын хәл итүдә дәүләт ярдәменә аеруча мохтаҗ гаиләләрнең тагын бер категориясе – инвалид балалары булган гаиләләр.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль Законның 17 статьясы нигезендә Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган тәртиптә исәпкә куелалар һәм торак белән тәэмин ителәләр.

2005 елның 1 гыйнварына кадәр исәпкә куелган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү федераль

бюджет акчалары исәбеннән Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасында әлеге тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган һәм югарыда күрсәтелгән гражданнарга Федераль компенсацияләр фондыннан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак сатып алуга субсидияләр бирүне күздә тота.

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2018 елда Федераль бюджет акчалары исәбеннән торак шартларын яхшыртуга субсидияләр алучыларның (инвалидларның) җыелма исемлегенә инвалид балалары булган 167 гаилә кертелгән. 2018 елда шушы категориядәге бер гаилә дә субсидия алу хокукын гамәлгә ашырмаган.

2013 елдан башлап бүгенгә кадәрге чорда аларның гомуми саны 26 булды. Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына еллык субвенцияләр күләме инвалид балалары булган гаиләләрнең Россия Федерациясе законнары белән гарантияләнгән дәүләт ярдәмен нәтиҗәле тәэмин итәргә мөмкинлек бирми.

*26 нчы таблица*

***2013 – 2018 елларда инвалид балалары булган гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга бирелгән субсидияләр***

| **Еллар** | **Россия Федерациясе бюджетыннан субсидияләрнең гомуми күләме* (мең сумнарда)** | **Субсидияләр алган инвалид балалы гаиләләр саны (гаилә)** |
|---|---|---|
| **2013** | 122 202,21 | 1 |
| **2014** | 108 451,2 | 4 |
| **2015** | 115 317,0 | 6 |
| **2016** | 110 367,9 | 10 |
| **2017** | 114 596,0 | 5 |
| **2018** | 55 956,9 | 0 |
| **Барысы** | **626 891,21** | **26** |

*2013 – 2017 елларда инвалид балалары булган гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга бирелгән субсидияләр күләме хәрби хәрәкәтләрдәге ветераннарга бүленгән акчаларны да исәпкә алып бирелгән. 2018 елда бары тик инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә генә бирелде.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Торак кодексының 57 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 29.11.2012 № 987н боерыгы белән расланган Исемлектә күрсәтелгән, башка гражданнар белән бергә яшәргә ярамый торган хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләр ***социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын чираттан тыш алырга хокуклы***.

Республикада муниципаль торак фонды проблемаларын исәпкә алып, инвалид балалары булган ата-аналарның муниципалитетлардан чираттан тыш торак белән тәэмин итүне дәгъва кылып, судка мөрәҗәгать итү практикасы бар.

*Мисал**.** Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә инвалид бала С.ның әнисе Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан С. гаиләсенә социаль яллау шартнамәсе буенча чираттан тыш торак урыны бирүне тәэмин итү хакында суд карарын тиешенчә үтәү мәсьәләсен хәл итүдә ярдәм сорап мөрәҗәгать итте. буш муниципаль торак урыны булмау аркасында суд карары озак вакыт үтәлми тора, шуның белән инвалид баланың торак хокуклары бозыла. Әлеге факт буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил муниципаль район*

*башлыгына балигъ булмаган баланың хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында һәм суд карары нигезендә С.ның гаиләсен торак урын белән тәэмин итү чараларын күрү таләбе белән бәяләмә җибәрде.*

Шул ук вакытта, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 29.11.2012 № 987н боерыгы белән расланган Исемлектә күрсәтелгән гражданнарның бер фатирда бергә яшәвенә каршы килә торган авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган һәм 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә куелган гаиләләргә торак урыны сатып алу өчен 2014 елдан Татарстан Республикасында ***төбәк торак субсидиясен бирү*** (бер мәрәбә акчалата түләү) номасы кертелде (Татарстан Республикасында халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясы).

«2018 елга, 2029 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2017 елның 30 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасында халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясында билгеләнгән аерым категроия категория гражданнарны торак белән тәэмин итүгә 50 000 мең сум күләмендә акча бүленде. 2019 һәм 2020 елларда да шундый ук сумма бирү күздә тотыла.

2018 ел дәвамында торак субсидияләре инвалид балалары булган ике гаиләгә 2 395,9 мең сум акча бирелде.

### *3.6.4. Балигъ булмаганнарның башка мөлкәти хокукларын яклау*

Ел саен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә балигъ булмаган балаларын карап тоту буенча ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү турында шактый санда мөрәҗәгатьләр керә. Болар, бигрәк тә, алимент йөкләмләре буенча шикаятьләр.


2018 елда шундый мөрәҗәгатьләр саны 204 булды. Бу барлык мөрәҗәгатьләрдән 10% тәшкил итә. Болар – алимент түләүдән качучы элеккеге ирләренә йә хатыннарына карата бирелгән шикаятьләр, суд приставлары-үтәтүчеләрнең гамәлләренә (битарафлыгына) карата шикаятьләр.

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе биргән белешмәләрдән күренгәнчә, 2018 елның 6 ай йогаклары буенча балигъ булмаган балаларына түләнмәгән алимент бурычы 3 267,382 млн. сум булган. 2018 ел ахырына бу сумма 3 119,444 млн. сум иде.

2018 елда балигъ булмаган балаларына алимент түләтү турындагы суд карарларының үтәлмәвенә бәйле рәвештә 17 875 суд эше кузгатылды. Гомумән алганда, республика суд приставларының территориаль бүлекләрендә ел дәвамында 39 121 үтәтү эше буенча мәҗбүри үтәтү эшләре алып барылган. Бу 40 меңләп баланың матди тәэмин ителеш тиешле матди дәрәҗәдә булмагана дигән сүз, кагыйдә буларак, бала белән ата-аналар арасындагы конфликтлы мөнәсәбәт аларның тормышында чагыла.

*100 нче диаграмма*


***2013 – 2018 елларда балигъ булмаган балаларны тотуга мәҗбүри рәвештә алиментлар түләтү буенча суд карарларын үтәүнең торышы***




Балаларны тәэмин итү өчен алиментлар түләтү турындагы суд карарлары үтәлмәвенең төп сәбәпләреннән берсе, барыннан да элек, аларның ата-аналар тарафыннан үтәлмәвенә бәйле. Күп кенә «алиментчылар» балаларын тәэмин итүгә акча түләп тору гына түгел, хәтта яшәү һәм эшләү урыннарын да яшерәләр. Алимент йөкләмәләре буенча эзләү игълан ителгән бурычлылар саны 2018 елда 1 859 кешене тәшкил итте.

*101 нче диаграмма*

***2013 – 2018 елларда алимент йөкләмәләре буенча эзләү игълан ителгән бурычлылар саны (кеше)***





Үтәтү эше турындагы законнарны бозган өчен 2018 елда 2 978 кеше административ җаваплылыкка тартылган, бу алимент түләүмәүчеләр буенча үтәтү эшләренең гомуми саныннан 49,2% тәшкил итә.

2018 елда Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тикшерүчеләре 988 җинаять эше ачкан, шулардан 629 эш буенча – гаепләү хөкеме, 7 эш буенча җинаять эшен туктату турында суд карарлары чыгарылган.

*102 нче диаграмма*

***2013 – 2018 елларда алиментлар түләтү буенча җинаять эшләре ачу***





2018 елда ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның мөлкәти хокуклары бозылу, аерым алганда, ата-аналардан алиментлар алуга кагылышлы өлешендәге мәсьәлә дә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым игътибарында булды.

Республиканың 25 муниципаль районында шушы категориядәге балаларның шәхси эшләрен тикшерү барышында тәрбиягә алган ата-аналар тарафыннан балаларның алимент алуга хокуклары тиешенчә үтәлмәү фактлары ачыкланды: алимент түләтү турында суд карарлары буенча үтәтү кәгазьләренең суд приставларына үтәүгә җибәрелмәгән йә тапшырылган кәгазьләр буенча үтәтү эшләренең барышы тикшереп торылмаган. Үз чиратында, мондый очраклар опека һәм попечительлек органнары ягыннан тиешле контроль булмауны күрсәтә. Аерым тәнкыйть зонасына Аксубай, Алексеевск, Әгерҗе, Чүпрәле, Менделеевск, Яңа Чишмә, Спас, Балык Бистәсе, Питрәч районнары керде, шуңа бәйле рзвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тиешле тәэсир итү чаралары күрелде.

*103 нче диаграмма*

***2013 – 2018 елларда ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның алимент алуга хокукларын үтәүне тәэмин итүнең торышы***




Югарыда китерелгән белешмәләрне анализлаудан күренгәнчә, 2018 елда ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга алиментлар түләтү турындагы 1 639 үтәтү эшенең таләпләре үтәлүгә бәйле рәвештә 340 эше генә, ягъни 20% тәгәлләнде. Шуны да әйтергә кирәк, агымдагы елда мондый кузгатылган эшләр саны беркадәр кимегән. Әлеге мәгълүмат шуны күрсәтә, алимент буенча бурычлыларның бары тик дүрттән бер

өлеше генә балигъ булмаган балаларын тәэмин итеп тору буенча үз йөкләмәләрен үти. Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил опека һәм попечительлек органнарына ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләре эшчәнлеген контрольдә тоту, ата-аналардан алимент алу хокукларын яклау һәм тәэмин итү буенча эшне көчәйтү (активлаштыру) зарурлыгы турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итү максатка ярашлы булыр дип саный.

Шунысы мөһим, 2018 елда балаларга карата мәҗбүри рәвештә алиметлар алу эшчәнлеген активлаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы 2135-р номерлы күрсәтмәсе белән Татарстан Республикасында алимент бурычларын алуны тәэмин итү буенча Ведомствоара эшче төркем булдырылды. Эшче төркем эшчәнлеге алиментлар түләтү процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында республикада өстәмә чаралар эшләүгә һәм куллануга юнәлтелде.

# ЙОМГАКЛАУ

***«Безнең алда зур бурычлар тора. Без аларны хәл итүгә, кеше бу тормышта үз урынын тапсын өчен иң яхшы шартларны тәэмин итә торган социаль, икътисадый үсеш моделен булдырып, системалы һәм эзлекле рәвештә барабыз. Без кискен үзгәрүчән вәзгыятьләргә тиешенчә җавап бирергә, Россияне, үз тәңгәллегенә, күпгасырлы традицияләргә, үзебезнең халыкларның мәдәниятына, кыйммәтләренә нигезләнгән цивилизацияле дәүләт буларак саклап калырга тиеш. Әлбәттә, куелган бурычларны без, көчләрне бары тик бергә туплаганлда, бары тик без барыбыз да бергә булганда, җәмгыять берләшкәндә генә, Россиянең барлык гражданнары конкрет эшләрдә уңышка ирешүгә әзер булганда гына үти алабыз».***

Россия Федерациясе
Президенты
В.В.Путинның
Россия Федерациясе
Федераль Собраниесенә
юлламасыннан, 2019
елның 20 феврале

1959 елда Бала хокуклары декларациясе, «кешелек үзендә булганның иң яхшысын бирергә тиеш» дип игълан итте. Һәм 2018 елда республикада яшь татарстанлыларның һәм балалы гаиләләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга корылган, нигезенә бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тулысынча тәэмин итү принцибы салынган максатчан дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру дәвам итте. Әлеге сәясәтне гамәлгә ашыруда дәүләт структуралары, җирле үзидарә органнары, дәүләткә карамаган оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары, балаларны һәм аларның мәнфәгатьләрен кайгыртучы барлык белгечләр, ата-аналар һәм киң җәмәгатьчелек көчләре бергә тупланды.

Бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылуның аерым очраклары булуга карамастан, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2018 елда Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешен тәэмин итүне канәгатьләнерлек дип бәяли. Бала хокукларын гамәлгә ашыруның әлеге докладта күрсәтелгән аерым мәсьәләләре үтәлешен тәэмин итү өчен чаралар күрү таләп ителә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дәүләт хакимияте оганнарына һәм җирле үзидарә органнарына үзенең еллык докладын балалар мәнфәгатьләрендә төбәк сәясәтен гамәлгә ашыруны бәйсез бәяләү һәм тикшереп тору механизмы итеп карарга тәкъдим итә. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, докладта күрсәтелгән йомгакларны Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан яклауны тәэмин итү максатларында камилләштергәндә, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, кызыксынучы ведомстволарның һәм оешмаларның вазыйфаи затлары тарафыннан еллык докладтагы

төп тәкъдимнәрне һәм күрсәтмәләрне гамәлгә ашыру буенча мөстәкыйль һәм ихтыярый эшләр башкарылганда кулланылыр, дип көтеп кала.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, министрлыкларга һәм ведомстволарга, федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы Прокуратурасына, хокук саклау органнарына, республиканың җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, җәмәгать оешмаларына һәм республиканың битараф булмаган гражданнарына, массакүләм мәгълүмат чараларына бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру барышындагы хезмәттәшлек, үзара мөнәсәбәт һәм ярдәм өчен рәхмәт белдерә.

Татарстан Республикасында
Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил — Г. Л. Удачина

*2019 ел, март*